МАТБУГАТ КӨЧЕ
«Татмедиа» агентлыгының йомгаклау коллегиясе утырышында узган елга нәтиҗә ясадылар
> 2

«ВТ» КУНАКЛАРЫ
«Минем герой» бәйгесе җиңүчеләрен редакциягә чакырып котладык
> 3

УКУЧЫ СҮЗЕ
Хатларда – укучыларыбыз уй-фикерләре
> 7

РӘХӘТ ЧАК
Студентлар көне уңаеннан яшьлек хатирәләрен барладык
> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 11 (28978) | Чәршәмбе | 25 гыйнвар | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ҖИДЕ КАТ УЙЛАП ТӨЗЕРГӘ

Төзүчеләрдән – яңа рекорд! Былтыр республикада 3 миллион 93 мең квадрат метр торак кулланышка тапшырылган. Башкалада гына да бер кешегә 29 квадрат метрга якын торак туры килә. Тик бер яктан артса, икенче яктан кимегән. Узган ел республикада ипотека алучылар саны өчтән бер өлешкә азрак теркәлгән. Төзелеш тармагын быел ни көтә? Бу хакта яңа IT паркта сөйләштеләр.

kzn.ru

Башкалада Татарстан Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгының еллык коллегиясе узды. Утырышта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Россия төзелеш һәм ТКХ министры урынбасары Никита Стасишин да катнашты. Тармак министры Марат Айзатуллин сөйләшүне сөенечле саннардан башлады. Республика төзүчеләре елдан-ел тырышыбрак эшли. Татарстанда 3 миллионнан артык квадрат метр торак кулланышка тапшырылган. 9 мәктәп, 3 балалар бакчасы төзелгән, 1 мең 200дән артык ишегалды төзекләндерелгән. Узган ел дәвамында төзелеш тармагына 513 миллиард сум акча тотылган. Алдагы ел белән чагыштырганда, күрсәткеч 100 миллиард сумга диярлек арткан. Татарстан файдалануга тапшырылган торак күрсәткече буенча, Идел буе федераль округы төбәкләре арасында – беренче, ә ил күләмендә – алтынчы урында. Бүген республикада 213 күпкатлы йорт төзелешендә эш гөрли.

Төзегәнне алучылар булсын берүк. Министр әнә шуңа игътибар итте. Былтыр республикада ипотека рәсмиләштерүчеләр саны 34 процентка кимегән. Марат Айзатуллин фикеренчә, халыкның сатып алу мөмкинлеге саеккан. Хәер, узган ел халыкта өй туе үткәрерлек кәеф тә юк иде. Булган акчаны да саграк тота башлаганнардыр, бәлки. Торак базарына ташламалы ипотека программалары ярдәм итәргә тиеш, дигән ышаныч белдерде министр.

– Ташламалы ипотека программасы 2024 елның 1 июленә кадәр озайтылды. Гаилә ипотекасының шартлары да гадиләштерелде. Моңарчы әлеге программадан 2018 елда һәм аннан соңрак икенче баласы туган гаиләләр генә файдалана алса, бүген 18 яше тулмаган ике баласы булганнар да әлеге хокукка ия, – диде Марат Айзатуллин.

Коллегиядә катнашкан Никита Стасишин киләчәктә ипотекага фатир биргәндә, аны җиһазлап тапшыру мөмкинлеге турында да әйтте. «Һич югы аш бүлмәсендә кирәкле җиһазлар булса, яшәп китәргә җайлырак булачак», – диде министр урынбасары алдагы эшләр турында сөйләгәндә.

Төзелеш тармагына аяк чалырдай тагын бер нәрсә – коммуналь хуҗалык корылмаларының торышы. «Алардан башка төзеп тә булмый», – диде министр. Аның сүзләренә караганда, бүген су белән тәэмин итү һәм су үткәрү челтәрләренең – 32 проценты, ә җылылык челтәренең 35 проценты тузган. Бер бездә генә түгел, ил күләмендә шул хәл. Шуңа күрә дә тармакта 2023–2024 елларга исәпләнгән коммуналь инфраструктураны яңарту федераль программасына зур өметләр баглыйлар. Аның кысасында ил төбәкләренә 130 миллиард сум акча бүлеп бирелер дип фаразлана.

Казанны алга таба Лаеш һәм Яшел Үзән якларына таба «үстерәчәкләр». Тик хәзерге кебек тегендә-монда төзеп түгел, ә барысын да алдан уйлап эшләячәкләр. Моннан ике ай чамасы элек кенә оешкан «Киңлекләрне планлаштыру институты» директоры Олег Григорьев әнә шул хакта сөйләде.

– Бу – яңа башланган эш, – диде Рөстәм Миңнеханов, мәсьәләгә басым ясап. – Алга таба күп кенә эшләрне башкача алып барачакбыз. Югыйсә кеше йорт сатып ала да, тирәюньдә ни юлы, ни шифаханәсе юклыгы ачыклана. Төзелеш фирмасы акчасын ала да китә ул, җирле хакимият исә бөтен проблемалар белән берүзе утырып кала. Питрәч, Биектауга гына карагыз. Мәсьәләне кичекмәстән хәл итәргә кирәк. Юкса бернинди юллар да җитмәячәк. Шәһәр яны кызыктыра, әлбәттә. Тик мизгел эчендә балалар бакчасы, мәктәп төзеп куеп булмый. Халыкны яшәгән җирендә юл, балалар бакчасы, мәктәп, шифаханә, эш белән тәэмин итәргә кирәк.

Президент әйтүенчә, без бу эшкә соңга да калган инде. Соң булса да, уң булсын, дигән фикер белдерде Рөстәм Миңнеханов. Яңа оешкан «Киңлекләрне планлаштыру институты» күзәтүче орган булмаячак, дип тә әйтте Президент. Бу эшне бергәләп башкарачакбыз.

Рөстәм Миңнеханов республика төзүчеләренә ирешкән уңышлары өчен рәхмәт белдерде.

– Димәк, тармакта алып барылган эш һәм федераль ярдәм чаралары уңай нәтиҗә бирә, – диде Президент.

Алда торган бурычлар турында да әйтте ул. Аерым алганда, төзелешнең сыйфатына, техник мөмкинлекләренә, биналарны карап торуга игътибарны арттырырга кушты. «Мәсәлән, авылда зур мәдәният йорты төзеп куялар да, эшләргә кеше юк дип, бикләп тоталар. Моннан ни файда?» – диде Рөстәм Миңнеханов.

Никита Стасишин да Татарстан төзүчеләренә уяурак булырга киңәш итте. Ни өченме? Эш шунда ки, быел тармакта ким дигәндә 2 миллион 830 мең квадрат метр торак тапшыру күздә тотыла. «Мин Татарстанда бу күрсәткеч быел да 3 миллион квадрат метрдан артып китәр дип уйлыйм, чөнки күрше Башкортстанда 3 миллион квадрат метр чамасы торак төзергә ниятлиләр», – диде Мәскәү кунагы, уенын-чыны бергә кушып. Мәскәүдән Татарстанга карап торучы элеккеге төзелеш министрлары Марат Хөснуллин һәм Ирек Фәйзуллин алдында сынатырга хакыбыз юк икәненә ишарәләпме: «Сез – тармакта иң яхшылары», – дип тә өстәде.

Коллегиягә кадәр Рөстәм Миңнеханов Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында да булды. Биредә ул «Нигезләр» фәнни-белем бирү киңлеге белән танышты.

Эльвира ВӘЛИЕВА

САН

Казанда соңгы биш елда **4,8 миллион квадрат метр** торак кулланышка тапшырылган. Башкалада торак белән тәэмин итү күрсәткече җан башына **28,7 квадрат метр** туры килә. Кеше саен кечкенә генә булса да, бер бүлмәле фатир дигән сүз бу!

Яңа төшенчә тәкъдим иткәннәр

ЛДПР Дәүләт Думасына «махсус хәрби операция балалары» статусын билгеләү турында проект кертергә ниятли. Думаның Халыкара эшләр комитеты рәисе, ЛДПР лидеры Леонид Слуцкий шулай дип белдергән. Аның фикеренчә, проект мондый балаларга ташламалар кертүгә ярдәм итәчәк, дип яза «РИА Новости».

Махсус хәрби операция балалары турында закон проекты шушы араларда эшләп бетереләчәк икән. Слуцкий сүзләренә караганда, Хөкүмәткә һәм төбәкләрнең хакимият органнарына әтиләре махсус хәрби операциядә катнашкан балалар өчен ташламалар, түләүләр кертү турында норматив актлар кабул итү мөмкинлеге бирәчәк ул.

Исегезгә төшерәбез: узган елның декабрендә Дәүләт Думасына мобилизацияләнүчеләрнең балаларына түләүле укудан түләүсезгә күчү хокукы бирүне күздә тоткан закон проекты кертелгән иде. Ул кабул ителгән очракта мондый студентларга дәүләт социаль стипендиясе дә биреләчәк.

Чит илнекеннән калышмый

Узган елда илдә яшәү өчен мөһим дарулар 1,9 процентка кыйммәтләнгән. Инфляция күрсәткеченнән күпкә кимрәк бу. Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко әйтүенчә, мөһим дарулар исемлегенә кермәгән препаратлар бәясе дә инфляциядән 10 процентка кимрәк дәрәҗәдә генә арткан. «Безгә үз җитештерүчеләребез товарының күбрәк сатылуына этәргеч бирергә, безнең дарулар сыйфатының чит илнекеннән калышмавын халыкка аңлатырга кирәк», – дигән ул.

Министр билгеләп үткәнчә, өстенлекле рәвештә җитештерелергә тиешле дарулар исемлеге булдырылган. Россия җитештерүчеләре хезмәте хисабына даруларга клиник тикшеренүләр саны да арткан.

Татар телен өйрәтәләр

Казанда яшәүчеләр татар телен бушлай өйрәнә алачак. 1 февральдән Россия ислам институтында «Без – татарлар» курсы башлана. Диния нәзарәте матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, дәресләр татар телен яңа өйрәнә башлаучылар өчен төзелгән программа буенча үткәреләчәк. Программаны институтның татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы белгечләре төзегән.

Дәресләр өч ай дәвамында алып барылачак. Аларда, татар теленнән тыш, ислам нигезләрен, татарлар тарихын, тәҗвидне өйрәнергә мөмкин булачак. Курсларны уңышлы тәмамлаучыларга сертификатлар тапшыру күздә тотыла.

Укулар атнага өч тапкыр: дүшәмбе, чәршәмбе һәм җомга көннәрендә кичке 6дан 9га кадәр булачак. Дәресләргә «Без – татарлар» онлайн платформасы аша кушылу мөмкинлеге дә карала. Анда теркәлгәннән соң 49 дәрескә бушлай кереп булачак.

Таможня хәлләре

Чиктән узу

Узган ел Татарстанда гражданнар тарафыннан законсыз төстә товарлар күчерү, 2021 ел белән чагыштырганда, 1,8 тапкыр арткан. Шулай итеп, мондый очраклар 760ка җиткән. Бу хакта журналистларга Татарстан таможнясы җитәкчесе Марат Гәрәев хәбәр итте.

Әлеге закон бозуларның күпчелеге – 266 очрак – акча күчерүгә бәйле. Аларның артуын җитәкче акчаны алып чыгу тәртипләренә үзгәрешләр керүгә бәйләп аңлатты.

– 2022 елның 2 мартыннан чит ил валютасын, шулай ук җәмгысы 10 мең доллардан артып киткән акча инструментларын (кәгазь һәм кәгазь булмаган акчалар, банк карталары, акцияләр һәм облигацияләр) Россиядән алып чыгу вакытлыча тыела, – дип аңлатты Марат Гәрәев.

Аның сүзләренчә, пассажирлар доллар белән евроны гына түгел, ә төрле валюталар алып чыгарга омтыла.

– Кайвакыт гражданнар таможня инспекторының дөньядагы барлык акча берәмлекләрен дә валютага тиңләвенә аптырый. Алар фикеренчә, валюта ул – доллар һәм евро гына, – диде ул.

Моннан тыш, коммерциячел партияләрне шәхси максатларда куллану өчен булган товарлар рәвешендә алып керүгә бәйле закон бозу очраклары – өч, алкоголь алып керү – ике, тәмәке алып керү тәртипләрен бозулар 1,5 тапкыр арткан. Болардан тыш, гражданнарның үзләре белән көчле тәэсир итүче матдәләр, корал, тыелган һәм чикләнгән ризыклар алып керергә теләүләре ачыкланган. Әйтик, таможня хезмәткәрләре маркировка узмаган 22 тонна азык-төлекне тоткарлаган. Болар – чикләвекләр, җиләк-җимеш, яшелчә, ярмалар, сырлар һәм киптерелгән җиләк-җимешләр. Мондый төр товар гадәттә юкка чыгарыла.

Татарстан таможнясы җитәкчесе әйтүенчә, җитештерүчесенең ризалыгыннан башка гына кертелгән товарлар исемлегендә җиһазлар һәм аларның кайбер частьлары иң популярлары булып тора. Ул параллель импорт вакытында бары тик оригиналь товарларга гына рөхсәт ителүен әйтте. Мондый товарларның гадәттә өченче илләр аша кайтарылуына басым ясады.

– Әлеге вакытта мондый тәртип – гадәти күренеш. Бу беренче чиратта безнең предприятиеләр өчен кирәкле җиһазлар һәм запас частьларга кагыла. Барысы да рөхсәт ителә. Иң төп шарт – бу товарларның оригиналь булулары, – диде җитәкче.

Шул ук вакытта ул параллель импорт кысасында кертелә торган товарлар арасында ялганнары да очравын әйтте.

– Без контрафакт белән бик кискен көрәш алып барабыз. Алар базарда булырга тиеш түгел. Параллель импорт ул – бары тик оригиналь товар гына, – диде Марат Гәрәев.

Узган ел чик аша күпләп кертелгән товарлар исемлегендә кулланылган чит ил машиналары да бар. 2022 елда Татарстанга шундый 2055 машина кертелгән. Бу – 2021 ел белән чагыштырганда, 15 тапкыр күбрәк дигән сүз. Таможня хезмәткәрләре мондый күрсәткечләрне, санкцияләр кертелү сәбәпле, Россиядә машиналарга бәя артуга бәйләп аңлатты. Алып керелгән автомобильләрнең яртысы өч ел йөргән булуы белән кызыклы. Ә иң популяр маркалар – Hyundai, KIA һәм Toyota. Машиналарның күпчелеген Казахстаннан алып кергәннәр. Моннан тыш, Марат Гәрәев Абхазиядән законсыз машиналар алып керү очраклары артуын да билгеләп узды.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Сүзгә-сүз

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:

Сатуда ыгы-зыгы тудырмас өчен, башка товарлар кебек үк, даруларның запасын булдырырга кирәк. Грипп вакытында температураны төшерә торган дарулар, антибиотикларга ихтыяҗ артачагын барыбыз да беләбез. Билгеле бер запасны вакытында булдырырга бернәрсә дә комачауламый бит.

(Хөкүмәт утырышыннан)

РОССИЯДӘ – ҮЗМӘШГУЛЬЛӘР

«Меркатор» компаниясе Россиядәге үзмәшгульләр санын ачыклаган.

Гыйнвар >> **4 миллион**
Октябрь >> **6 миллион**

Керем күләме – **1,5 триллион сум**нан артык

**Россия салым хезмәтенең 2022 елгы мәгълүматлары нигезендә*

Авыручылар арта

Россиядә коронавирус йоктыручыларның ишәюе күзәтелә. Роспотребнадзор хәбәренә караганда, чирләүчеләр саны алдагы атнадагы белән чагыштырганда 22 процентка диярлек арткан. Инфекция иярткүнең 38 меңләп яңа очрагы теркәлгән. Соңгы ике атнада чирләүчеләрнең һәммәсенең дә «омикрон» штаммын йоктыруы ачыкланган.

Шул ук вакытта узган атнада грипп һәм ОРВИ белән авыручылар саны, киресенчә, алдагы атнадагыга караганда 4,1 процентка кимегән. Барлыгы 856 мең кеше чир йоктырган. Шуңа да карамастан, Роспотребнадзор башлыгы Анна Попова эпидемиягә каршы чараларны дәвам итәргә кушкан.

Сулыш органнары вируслары (ОРВИ) арасында, элеккечә үк, грипп вируслары өстенлек итә. А гриппы (H1N1 – дуңгыз гриппы) белән беррәттән, В гриппы вирусы да көчәя. Барлык вирусларның 33 проценты чамасы шуңа туры килә. 2023 елның икенче атнасы мәгълүматларына караганда, Россиянең 64 төбәгендә В гриппы вирусы ачыкланган. Илдә бер атна эчендә ОРВИ һәм грипп йоктыручылар саны 1,5 тапкырдан күбрәккә арткан.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ДАВОС – 2023: ТӨШЕНКЕЛЕК ОЗАККАМЫ?

Үткән атнада Швейцария шәһәре Давоста Бөтендөнья икътисад форумы үтте. Пандемияле елларда форум онлайн режимда гына үткәрелгән иде, быел, ниһаять, миллиардерлар җыены тере очрашулар форматын алды. Форумның тагын бер үзенчәлеге: Россия бизнесы һәм сәясәтчеләре анда катнашмады. 2021 елгы форумда Владимир Путин чыгыш ясап: «Эпоха, когда пытались выстроить однополярный мир, завершилась», – дип игълан иткән, «Дөньякүләм каршылыклар «бөтерелә», шуңа күрә вазгыять алдан әйтеп булмый һәм идарә ителми торган юнәлештә бар кеше бар кешегә каршы көрәше рәвешендә үзгәрергә ихтимал», – дип белдергән иде. Путин фаразы тормышка ашты диярлек, әмма дәүләтләр әлегә Россиягә каршы көрәш сукмагына басты. Давоста быел Зеленский чыгыш ясады, Россиягә каршы көрәштә финанс һәм корал ярдәме сорады. «Российская газета» форумны «стал подтанцовкой к повестке НАТО» дип бәяләде.

Давос атмосферасында бу юлы төшенкелек хөкем сөрде. Халыкара валюта фонды рәисе Кристалина Георгиева ел уртасында дөньякүләм рецессия башланачагын фаразлады, керемнәрнең һәм табышларның кимеячәген, моның кредит базарына йогынты ясаячагын әйтте. Путин 2021 елда әйткән бер полюслы дөнья, чынлап та, җимерелеп бара. АКШ федераль резервының процент ставкаларын күтәрүе дә ярдәм итми: доллар дөньякүләм валюта статусын югалтып килә. Дәүләтләр арасында доллардан баш тартып, милли валюталар белән исәп-хисап ясау киң тарала. Бу соңгы бер ел эчендә генә шулай гадәткә керә башлады. Малайзиянең Россиядәге илчелегенең сәүдә киңәшчесе Хайфил Җәмил, ике илнең милли валюталарда сәүдә итешә башлавы мөмкин, дигән фикер әйтте. Согуд Гарәбстаны доллардан башка валюталарда исәп-хисап ясарга әзер торуын белдерде. Россия һәм Иран алтын белән тәэмин ителгән стейблкоин (криптовалюта) булдырырга ниятлиләр. Financial Times: «Бразилия белән Аргентина уртак валюта булдыру юнәлешендә эшлиләр һәм Латин Америкасы илләрен кушылырга чакыралар», – дип язды. Дөрес, яңа валюта тусын өчен, еллар кирәк булчак, диләр. Кәгазь валюталарның мондый чуарлыгы дөнья икътисады өчен яхшыга түгел. Күз алдына китерегез: сез баскан валютага товар сата башласалар, акчаны күбрәк басу теләге уяначак. Хәтта алтын белән тәэмин ителгән кәгазь валюта чыгарылса да, кәгазьне алтыннан күбрәк басу теләге җиңәчәк. Доллар халыкара валюта статусын яулаганда алтын стандартка ия (ягъни алтын белән тәэмин ителгән) иде. Хәзер ул кәгазь кисәгенә әйләнү стадиясен кичерә. Дөнья икътисадында проблемалар аннан башка да җитәрлек. Давос ул проблемаларны чишә аламы? Юк, әлбәттә. Ул проблемаларны тудыра гына. 2020 елда форумда коронавируска каршы көрәш стратегиясе игълан ителгән иде. Быелгы форумда журналистлар Pfizer генераль директоры Альберт Бурланы: «Ни өчен сыналмаган вакцинаны мәҗбүри кадатып, кешеләрне алдадыгыз?» – дигән сорау белән аздан гына стенага терәмәделәр...

Россиядә

ЯГУЛЫК ДЕМПФЕРЫ: КАЛАМЫ, БЕТӘМЕ?

Төркиягә барган бер россияле күптән түгел генә «Телеграм»да ачу белән тулы бер видеоролик таратты: нефть бәясе төшкәч, төрекләрдә бензин бәясе дә төшә башлаган. Нефть күтәрелсә, бензин дә күтәрелә. Дөньяның күп илләрендә хәл шундый. Әмма Россиядә түгел. Мәскәүдә моннан берничә ел элек кызыклы тәртип керттеләр: төньяк-көнбатыш Европада бензинга бәя күтәрелгәндә, бездәге бензин да кыйммәтләнмәсен өчен, нефть эшкәртүчеләргә акча түләнә башлады. Көнбатыштагы базарда бензин арзанайса, бездәге нефтьчеләр бәя төшерми, табыштан бюджетка түлиләр иде. Бу Европада ягулык кыйммәтләнгәндә, нефтьчеләр бензинны шунда күпләп сатмасын өчен шулай эшләнде. Эчке базарда дефицит туып, бездә дә бәяләр күккә ашачак иде. 2019 елда шулай була язды да. Мотор ягулыгы кыйммәтләнү социаль протест китереп чыгарачак, бу шиксез. Федераль хөкүмәт ягулыкның кискен кыйммәтләнүен булдырмас өчен уйлап чыгарды ул механизмны һәм аңа «ягулык демпферы» дип исем бирде. Бензин кыйммәтләнде кыйммәтләнүен, ләкин акрын гына, «баканы акрын утта пешерәләр» дигән принцип белән. 2018 елның 22–28 гыйнвар атнасында Казанда АИ-92 маркалы бензин бәясе 37 сум 40 тиен торган. 2022 ел ахырында – 46 сум 03 тиен. Аерма бармы? Сизелерлек, әмма акрын гына күтәрелгәнлектән, без аны сизмәдек. Доллар курсы уйнаса да, нефть бәясе чайкалса да, Россиядә бензин бәясе вак адымнар белән гел күтәрелеп торды, бер дә төшмәде. Әмма демпфер сәбәпле, инфляция котырганда, мотор ягулыгы чагыштырмача тотрыклы бәядә калды.

5 февральдән соң Россия ягулыгына Европа базарлары ябыла. Нефть продуктларына да чик бәяләр куеп маташалар. Андый шартларда безнең чимал дисконт белән, ягъни ярты бәясенә сатыла. Моны «Российская газета» әйтә: «В Азиатско-Тихоокеанский регион (АТР) или Африку поставки возможны только с дисконтом, к тому же транспортировка выходит сильно дороже», – ди. Тагын бер нәрсә бар: безнең нефть продуктларын ул базарларга тулысынча урнаштырып бетереп булмаячак. Белгечләр, өчтән берен урнаштырып булса яхшы, диләр. Арзанга һәм аз сатарга туры киләчәк. Күбрәк чи нефтьне сатарга туры килер, мөгаен. Бездәге нефть эшкәртү заводларының җитештерүне киметәчәге, эшчеләрне кыскартачагы рәсми рәвештә танылды. Нефть эшкәрткәндә, проблема туачак: бензинны куярга урын бар, мазутны – юк. Мазутка урын булмау сәбәпле, бензин эшкәртүне дә нык киметергә туры килү ихтималы зур. Хөкүмәт демпферны саклар саклавын, әмма бәяләр тотрыклы калган хәлдә, бензинга кытлык туу куркынычы зур. Ягулык дефициты булмасын өчен, бәяләрне кискен күтәрү ихтыяҗы туачак. Вазгыятьтән бензин импортлап чыгып була, совет чорындагы кебек талон кертеп була. Үзебезнең заводларны ябып, читтән безин ташу да эш түгел инде ул, бәя мәсьәләсе дә калкып чыгачак. Бу әлегә чишелмәгән мәсьәлә булып кала.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

УНБЕРЕНЧЕ ҖИҢҮ

tatarstan.ru

Рөстәм Миңнеханов «Зенит-Казан» командасын узган ел волейбол буенча Россия кубогында җиңүләре белән котлады. Спортчыларның мондый җиңү белән унберенче тапкыр сөендерүләре. «Сез команда рухы һәм югары осталык, җиңүгә омтылыш белән бик яхшы уен күрсәттегез. Сезнең чыгышны игътибар белән күзәтеп, уйнавыгызны ошаттык. Кубок өчен финал уены безнең команданың көчен күрсәтте, көндәшләргә берниндн шанс та калдырмады. Сезнең җиңүегез белән бөтен республика горурлана. Бик зур рәхмәт сезгә!» – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент команда җитәкчелегенә, уенчыларга, Алексей Вербов җитәкчелегендәге тренерлар составына, шулай ук республика Волейбол федерациясе җитәкчелегенә, клуб спонсорына рәхмәт белдерде. Рөстәм Миңнеханов узган ел ир-ат командалары арасында волейбол буенча Россия кубогында җиңгән өчен «Зенит-Казан» волейбол командасына Татарстан Президентының Рәхмәт хатын тапшырды. Спортчылар исә, Рөстәм Миңнехановка истәлекле медаль тапшырып, республикада спортка күрсәткән ярдәме өчен рәхмәт белдерде.

Үзебезнекен сайла

Үзебездә эшләп чыгарылганын сатып алу әйбәтрәк. Җитештерүчеләргә этәргеч бирү өчен кирәк бу. Федерация Советы Рәисенең беренче урынбасары, «Бердәм Россия» партиясе Генераль советы Секретаре Андрей Турчак партиянең «Үзебезнекен сайла» дигән проектын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча селектор киңәшмәсе уздырды. Анда Дәүләт Советы Рәисе, партиянең төбәк советы Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.

Импортны алыштыру буенча «Үзебезнекен сайла» проекты 2022 елның язында башланып киткән. Киңәшмәдә Андрей Турчак билгеләп үткәнчә, ул импортны алыштыруга ярдәм итүче эшмәкәрләр һәм җитештерүчеләрнең хокукларын яклауга, аларга булышуга юнәлдерелгән. Генераль совет Секретаре басым ясап әйткәнчә, бүгенге гаять катлаулы икътисадый шартларда әлеге проектны үстерергә кирәк. Аның әйтүенчә, җитештерүчеләр белән товар җибәрүчеләр һәм кулланучылар арасында мәгълүмат алышуны камилләштерү мөһим. Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы моның өчен махсус биржа булдырган. Шулай ук бюджет акчасы хисабына дәүләт ихтыяҗлары өчен товар (хезмәтләр) сатып алу аша да импортны алыштыруга этәргеч бирү мөһим.

Партиянең Татарстандагы бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин, республикада импортны алыштыру программалары кысасында җитештерүчеләр, товар җибәрүчеләргә ярдәм чараларына тукталып, республика хакимият органнарының сәнәгать предприятиеләре җитәкчеләре белән бер йодрыкка тупланып эшләүләрен искәртте. «Бу проект партиябезнең абруен күтәрде, күпчелек предприятиеләр җитәкчеләренең тырышлыгын берләштерүгә китерде, – дип басым ясап әйтте ул. – Икътисадны үстерү өчен проект мөмкинлекләре җитештерүчеләрнең һәммәсен кызыксындыра».

Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, проект Татарстанның күпкырлы икътисады өчен зур әһәмияткә ия. «Аның ярдәмендә икътисадның түбәнгә тәгәрәвен булдырмыйча калдык, киресенчә, берникадәр үсешкә дә ирештек әле, – диде ул. – Республикада проектны башкачарак – «Үзеңнекен булдыр» дип атап йөртәбез һәм аның мөмкинлекләренә ышанабыз».

Россия сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары Василий Осьмаков исә соңгы вакытларда норматив хокукый базаның нык гадиләштерелүен билгеләп үтте. Шулай ук дәүләт ихтыяҗлары өчен Россиядә җитештерелгән товар өлешен арттыру буенча эш дәвам иттерелә.

КАНАТЛАР КАЕРЫЛМАСЫН

Йомгак

Аерылышуга барып җитмәскә. Гаилә корганбыз икән, аны сакларга кирәк. Әлеге сүзләр Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең еллык коллегиясендә әйтелде. Шөкер, узган елгы саннар сөендерә. Идарә җитәкчесе Гөлшат Нигъмәтуллина сүзләренә караганда, 2022 елда Татарстанда 27 428 никах теркәлгән. 2021 ел белән чагыштырганда, гаилә коручылар саны 11,3 процентка арткан. Аерылышучылар саны 2,1 процентка кимегән.

– Татарстан бала туу күрсәткече буенча да Идел буе федераль округындагы төбәкләр арасында беренче урында тора. 2008 елдан республикада күпбалалы гаиләләр дә артып бара. Үлем очраклары кимү дә сөендерә. 2021 ел белән чагыштырганда, бездә үлем-китем 25,8 процентка кимегән, – ди Гөлшат Нигъмәтуллина.

Киңәйтелгән утырышта идарә җитәкчесе Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Дәүләт Советына Юлламасында: «Аерылышу өчен судка килеп җиткәнче, гаиләләрне саклап калу өчен ир белән хатын арасындагы бәхәсләрне чишәргә ярдәм итәргә кирәк», – дигән сүзләрен дә искә төшерде. Аның фикеренчә, гаиләгә кыен вакытта психологлар, суд һәм ЗАГС хезмәткәрләре бергәләп ярдәм итәргә тиеш.

– Безне аерылышуның читтән генә башкарылуы да борчый. Узган ел никахларын өзәргә теләүчеләрнең 79 процентының язмышын суд хәл иткән. Бу процесста ир белән хатын катнашып та тормаган. Аерылышуга барып җиткәнсең икән, бу эштә ике як та катнашырга тиеш, – ди ул. – Бу уңайдан районнарда да эшне көчәйтергә, гаиләләрне читтән торып аермаска кирәк. Безнең максат – никахны саклап калу.

Очрашуда ЗАГС эшчәнлегенә, ел буе башкарылган эшләргә дә тукталдылар. Бергә озак еллар яшәгән парларны хөрмәтләү чарасы турында әйткәндә, 70 ел иңне иңгә куеп атлап барган парларга «Ярату һәм тугрылык өчен» дигән медальләр тапшыру хакында да сүз булды. 2008 елдан бирле бирелүче бу медальгә 1 мең гаилә лаек булган. Ел саен Республика көне уңаеннан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов хатыны Гөлсинә ханым белән үрнәк гаиләләрне кабул итә. 8 ел дәвамында алар 400 парны кабул иткән. Инде 17 нче тапкыр үткәрелә торган «Нечкәбил» бәйгесе дә гаиләләрне саклауга өлеш кертә.

Утырышта катнашкан Актаныш районы башлыгы Ленар Зарипов та гаиләнең әһәмияте хакында сөйләде. Киров авылында яшәүче Сабитовларны бөтен республикага үрнәк итеп күрсәтте ул. Актаныште гаилә тотрыклылыгы юнәлешендә ниләр эшләнә соң? Баксаң, районда 10 елдан артык яшүсмерләргә гаилә кору, аны саклау буенча дәресләр укытыла икән.

– Бу юнәлештә милли традицияләр ярдәм итә ала. Элек бер йортта берничә буын яшәгән, яшьләр өлкәннәрдән тормыш итәргә өйрәнгән. Үзара аңлашу булганда, гаилә тотрыклы була, – диде ул. – Судка кадәр барып җитмәскә кирәк. Проблеманы үзара хәл итәргә дә мөмкин бит.

Быелдан аерылышуны катлауландырып, гаиләләргә аңлату эшләре алып бармакчылар.

Яңалыклар да шактый. Әйтик, хәзер баланың туу турындагы таныклыгын онлайн да алып була. Электрон таныклыкның беренчесен узган елның 19 сентябрендә Алабугада яшәүче бер гаилә алган да инде. Гөлшат Нигъмәтуллина аңлатуынча, аны алыр өчен, әнисенең Дәүләт хезмәтләре порталында теркәлгән булуы кирәк. Гариза биргәч, шәхси биткә электрон таныклык килеп тә җитә. Мондый хезмәттән Баулы, Нурлат, Менделеевск, Ютазы районнарында яшәүчеләр дә файдалана башлаган.

Утырышта Татарстанның Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева ЗАГС хезмәткәрләренә 2022 елда башкарган эшләре өчен рәхмәтен җиткерде.

– Эшегездә матур вакыйгалар күбрәк булсын, – диде ул. – Республикада кияүгә чыгучыларның һәм бәби табучыларның яше борчый. 29 яшьтә соң инде ул. Ничек тә кызыксындыру булырга тиеш. Дәүләт биргән ярдәм чараларын искә төшерегез. Авыл җирлекләрендә бала алып кайткан әниләргә акча бирелә бит. Бу өлкәдә дә эшләргә кирәк. Гаиләләр аерылышыр дәрәҗәгә җиткән икән, алар белән көчле психологлар эшләргә тиеш. Бездә аерылышучылар саны буенча күрсәткечләр начар булмаса да, гаиләләрне саклау юнәлешендә эшне даими алып барырга кирәк. Яшьләр сездән кулга-кул тотынып чыгып киткән кебек, безгә дә кулга-кул тотынып эшләмичә булмый.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ҮЗГӘРҮ

Шоу-бизнес белән генә шөгыльләнмик! «Татмедиа» агентлыгының 2022 ел нәтиҗәләренә багышланган коллегиясендә төп фикер әнә шул булгандыр. Журналистларга да, журналистикага да кагыла ул. Тармакның һәркемгә дә ошап бетмәвен искә төшерделәр, һөнәрнең язу-сөйләү белән генә чикләнмәвенә басым ясадылар, үзгәрешләр кичерүебезне әйттеләр. Татарстанның медиакыры узган елны ничек үткәргән, үз алдына нинди бурычлар куя?

Төп нәтиҗәләрне агентлык башлыгы Айдар Сәлимгәрәев барлады. Аз эшләнмәгән, билгеле. Елына күрә җитди эш башкарылган. 2022 елның нинди рухта узганын барыбыз да аңлыйдыр инде. Журналистикага да, журналистларга да үзгәрергә туры килде. «Йөрәк һәм акыл», «бурыч һәм хезмәт» дигән төшенчәләр бергә-бер йөрде. Аның каравы халыкның ышанычлы мәгълүматка ихтыяҗы үзгәрешсез калды. Шунысы да бар: элек тизлек алга чыкса, хәзер кешегә фикер кирәк.

– Пандемия чорында да, махсус хәрби операция башлангач та, ышанычлы мәгълүматка ихтыяҗ барлыкка килде. Бу этапларда күп ялган мәгълүмат белән дә очрашырга туры килде, – диде бу җәһәттән агентлык башлыгы. – Аналитика шуны күрсәтте: кризис кичергәндә, кискен вазгыятьтә дәүләт массакүләм мәгълүмат чараларыннан килгән мәгълүматка ихтыяҗ зур. Безгә уйлап эшләргә, вакыйгаларны тирәннән күрсәтергә һәм мәгълүматны аудиториягә тапшыру каналларын киңәйтергә кирәк.

Саннарны да барлыйк инде. Әйтик, матбугат чараларының сайт һәм социаль челтәрләрдәге язылучылар саны 7,5 миллионга арткан (узган елгы күрсәткечтән 25 процентка артыграк). Айдар Сәлимгәрәев сүзе белән әйтсәк, мондый саннар белән башка бер генә төбәк тә мактана алмый икән. Сүз уңаеннан, Татарстанстат мәгълүматлары буенча, ел эчендә чыккан газеталар – 69, ә бастырылган китаплар 23 процентка арткан.

Күңелгә тигән мәсьәләләр дә яңгырады. Бигрәк тә басма матбугатка кагыла ул. «Халыкның басма матбугатка карата кызыксынуы бар. Әмма аны тарату җәһәтеннән дә мәшәкатьләр кала бирә. Милли матбугат моннан аеруча зыян күрә. Шәхси матбугат чараларына да ярдәм юк», – диде агентлык җитәкчесе. Бу уңайдан, тиражны саклап калуда, агентлык башлыгы сүзләре белән әйтсәк, «чын батырлык» күрсәткән «Россия почтасы» хезмәткәрләренә рәхмәт тә әйтелде.

Җыелган шәпкә проблемаларны да барлау мәслихәт инде ул. Анысын Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Илшат Әминов башкарды.

Беренче чиратта журналистларның хезмәт хакын арттыру проблемасын күтәрде ул. Бу җәһәттән саннар да белешкән: журналистларның республикадагы уртача хезмәт хакы 30 мең сум тирәсе. Бу – эшенә күрә гадел бәя түгел, дигән фикердә берлек рәисе. Эшли башлаган чорда 230 сум алганын, моның шактый акча булуын да яшереп тормады. Хәзер хәлләр башкачарак шул.

Тагын бер проблема – исемле журналистларның аз булуы. Болар инде –медиа өлкәсенә яңа аяк басучылар өчен остазлар мәктәбе дә. «Мин журналистикага килгәндә, исемле профессионаллар күп иде. Без алардан үрнәк алдык. Хәзер без, журналистлар исемле булсын өчен, мөмкинлек тудырырга тиеш», – диде Илшат Әминов.

Бу җәһәттән һәрбер тармакның мәңгелек бәласе – кадрлар кытлыгы да калкып чыга. Илшат Әминов сүзләре белән әйтсәк, бүгенге журналист киңкырлы шәхес булырга тиеш. Фотога да төшерсен, видеосын да ясасын, белемле дә булсын, тәрҗемә эшен дә, монтаж серләрен дә белсен, кыскасы. Моңа өстәләсе күнекмәләр шактый һәм көннән-көн арта гына бара. Илшат Әминов бу таләпләрне барлап, булачак коллегаларны әзерли торган уку йортларына тапшырырга тәкъдим итте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Эшне яратып башкару өчен яхшы шартлар да кирәк. Илшат Әминов бу җәһәттән: «Журналистларның яхшы шартларда эшләвен телим. Матур эшләр башкаручы кеше матур шартларда эшләргә тиеш», – диде. Шоу-бизнес белән түгел, чын журналистика белән шөгыльләнергә дә чакырды. Анысы исә бөтен кешегә дә ошап бетми шул.

Журналистларга үгет-нәсыйхәтләрен Татарстан Президенты Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров та җиткерде. Мәгълүмат җиткерүдә сак һәм җаваплы булырга өндәде ул.

– Негатив күп чорда кеше үзенә таяныч эзли. Моңа иң яхшы җавап – авторларның профессиональлеге, оператив булуы. Республиканың мәгълүмат чараларына мәгълүмат җиткерүдә аеруча җаваплы булырга кирәк. Провокациягә китерә торган баш исемнәр, нидер әйтеп бетермәү, контексттан тартып алулар булмасын! – диде ул.

Мәгълүмат бирү генә түгел, җәмгыятьне ныгыту, ватанпәрвәрлек очкыны өстәү дә – матбугат чаралары җилкәсендә. Әсгать Сәфәров әйтүенчә, Бөек Ватан сугышы, махсус хәрби операциядә катнашучыларның батырлыгы, аларга ярдәм итүчеләрнең эшчәнлегенә бәйле темаларга да игътибар бирергә кирәк.

Моннан тыш, «рух» дигәнен дә кайгыртырга. Милләт, мирас, мәдәният турында да онытмаска. Татарстанда анысы да бихисап һәм төрле бит.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КҮРСЕННӘР ҺӘМ БЕЛСЕННӘР!

«МИНЕМ ГЕРОЙ» БӘЙГЕСЕНЕҢ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕН БҮЛӘКЛӘДЕК

Узган елның ноябрь аенда «Ватаным Татарстан» газетасы «Минем герой» бәйгесен игълан иткән иде. Кичә әлеге бәйгенең җиңүчеләрен редакциябезгә кунакка чакырып, бүләкләрен тапшырдык. Яшь укучыларыбыз белән бүгенге геройлар, батырлык турында фикер алышырга да җай чыкты.

«Минем герой» бәйгесен без төрле чордагы Татарстан геройларын данлау, балаларда һәм яшүсмерләрдә тарихи үзаң тәрбияләү, иҗади эшләр ярдәмендә Россия тарихында татар милләтенең урынын билгеләүне күздә тотып башлап җибәргән идек. Бәйгедә төрле яшьтәге бакча һәм мәктәп балалары катнашты.

Нинди генә эшләр кабул итмәдек без! Катнашучылар горурлык хисе тулы сүзләр белән Бөек Ватан сугышында катнашкан бабалары, махсус хәрби операциядә батырлык күрсәткән туганнары, янгыннан курыкмаучы дуслары һәм башкаларның рәсемнәрен, фотосурәтләрен җибәрде. Жюри яшь укучыларыбыздан килгән иҗади эшләр арасыннан иң яхшы унбишен сайлап алды. Ә бәйгенең өч җиңүчесе интернетта тавыш бирү юлы белән ачыкланды.

«Синең өчен герой – кем ул?» – дип сорагач, III урынны яулаган Дилия, ике дә уйламыйча: «Минем абыем!» – дип җавап кайтырды. Ул безгә Кукмарада янгын сүндерүче булып эшләүче абыйсы Марс Харисов турында сөйләде. «Бернидән дә курыкмыйча, кешеләрнең гомерләрен коткара ул. Мин аның белән бик горурланам!» – диде Дилия. «Алар фаҗига урынына вакытында килеп җитсә дә, көткән кешегә бик озак тоеладыр инде. Кызганыч, рәхмәт сүзләре урынына «Нигә соңга калдыгыз? Иртәрәк килгән булсагыз, мондый хәл булмас иде» кебек сүзләр ишетергә туры килә үзләренә. Кызым белән уйлаштык та «ВТ» укучыларына һәм сезгә абыебыз турында сөйләргә булдык», – дип сүзгә кушылды Дилиянең әнисе.

II урынны яулаган егетебез, кызганыч, бүләкләү тантанасына килә алмады. Әфган сугышы ветераны – әтисе Әхәт Дәүләтшин белән таныштырган иде ул безне.

Без шулай ук бәйгедә шактый тавыш җыйган Балтач егетен – Солтан Сөләйманов һәм аның батыр дусты Кәрим Йосыповны да чакырдык. Кәрим узган язда янгын вакытында кешеләргә ярдәм иткән, югалып калмаган, йортка кереп, мөһим әйберләрен алып чыгарга булышкан. «Кешеләргә ярдәм кирәк булгач, курку турында уйлап тормадым инде», – диде батыр егет. Киләчәктә Кәрим МЧС хезмәткәре булырга хыяллана. Солтан исә мондый дусты булуы белән бик горурлануын әйтте.

– «Минем герой» – без уздырган бәйгеләрнең иң мәгънәлеседер. Кызганыч, бүген, герой, дигәндә, мылтык аскан, танкка утырган һәм, гомумән, хәрби сыйфатларга ия кешеләрне атыйлар. Ләкин геройлар арабызда да бар бит. Кешелеклелек сыйфатларын өстен күрүчеләр күбрәк булса, мылтык тотарга, танкка утырырга мәҗбүр итә торган вакыйгалар азрак булыр иде, – диде газетабыз баш мөхәрриренең беренче урынбасары Илнар Хөснуллин.

Газетабызда батырлар турында һәрдаим язып торучы Фәния Әхмәтҗанова кунакларыбызга язмышларын күңеле һәм каләме аша уздырган геройлары турында сөйләде.

– Тирәнрәк уйлап карасаң, батырлар арабызда яши. Аларны күрә, эшләрен таный белергә һәм онытмаска кирәк. Менә шушы эшкә безнең бүгенге җиңүчеләребез дә беренче адымнарын ясады. Моны мин бик зур тәрбия эше дип саныйм, – диде ул.

Аның фикере белән җиңүчеләр үзләре дә, әти-әниләре һәм укытучылары да килеште. Әлеге җыелы очрашуны, бүгенге заман батырлары турында күбрәк сөйләшергә кирәк, дигән уртак фикергә килеп, тәмле чәйләр эчеп тәмамладык.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Җиңүчеләр исемлеге:

I урын – Ильяс Хәйруллин, Чаллыдагы 38 номерлы мәктәпнең 3 нче сыйныф укучысы;
II урын – Әмир Дәүләтшин, Арча районындагы 7 номерлы мәктәпнең 11 нче сыйныф укучысы;
III урын – Дилия Харисова, Кукмара районындагы Байлангар авылы мәктәбенең 3 нче сыйныф укучысы.

Бәйгедә I урын алган бала – «Алиса» колонкасы, II урын яулаганы – заманча колакчыннар һәм III урын иясе штативлы селфи-лампа белән бүләкләнде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

I урынны яулаган Ильяс Хәйруллин махсус хәрби операция барышында Лисичанск шәһәре өчен көрәштә батырларча һәлак булган абыйсы Инсаф Нуруллин турында язган иде. Бәйгедә катнашырга сыйныф җитәкчесе тәкъдим иткән аңа. Ике дә уйламыйча, әтисенең туган ягы – Мамадыш районының Урта Кирмән авылы егете Инсаф абыйсының фотосурәтен җибәрергә тәкъдим иткән Ильяс.

КӨЧ ЧЫКМЫЙЧА, КӨЧ КЕРӘМЕ

АДӘМ БАЛАСЫНА БИРЕЛГӘН КУӘТНЕҢ ЧИГЕ БАРМЫ?

Шушы көннәрдә авыл кибетенә барсам, авылның теге очында яшәүче, бездән ике ел гына соң укыган Рифат Сабиров килеп керде. Курткасыннан ук бер кулын күкрәгенә куеп бәйләгәне сизелеп тора. «Гипс салдырган, сындырган», – дип уйлаган идем. Баксаң, операция ясаткан икән.

– Өч җирдән сеңере өзелгән булган, – ди ул. – Гомуми наркоз белән ясадылар…

Егылгандыр, авариягә очрагандыр, дип уйлый күрмәгез. Ул аларның кайсы кайчан өзелгәнен дә белми! Инде аның: «Кулларым сызлый, иртән ике таблетка авырту баса торган дару эчмичә, кулларымны кыймылдата-күтәрә дә алмыйм», – дигәненә берничә ел. Хәер, авылда кырык яшьне узган күпләр шулай эшли. Аяк-кулы сызлап интегүчеләр байтак. Авыр физик хезмәт үзенекен итә. Рифат кебек, әллә ничә сеңере өзелгәннәр дә, өзелгәнен белмичә, белгәннәре дә түзеп булганча сабыр итеп, хастаханәгә бармаска тырыша.

Рифат – авылыбызның эшкә иң батыр ир-егетләренең берсе. Курку белмәс, тәвәккәл, бик тырыш та. Гомере буе тракторда, азык комбайнында эшләде. «Хан заманы»ндагы КСКда да, заманча «Ягуар»да да бердәй эшләп күрсәтә алды. Эшкә дигәндә үзе дә ягуардан ким булмады. Әллә кайчан «списать ителгән» комбайныннан чыккан яшел массаны да «КамАЗ»лар ташып өлгерә алмады. «Ягуар»га утыргач, өстәмә бортларын тагын да биегәйтеп кенә котылдылар шикелле. Аның кебекләр турында, ару белмәс кеше, диләр. Соңгы елларда тазалыгы беткәч кенә җиңелрәк эшкә күчте. Хәтерлим әле, моннан ун-унбиш еллап элек, колхозда эшләүче апама ындыр табагына ашлык тутырышырга чыккан идем. Ул елларда колхозчыларга хезмәт көненә ашлыкны авыллап бирәләр, һәркем үзенә тиешен капчыкларга тутырып ала. Аны башта үлчәү янына, аннан машинага, кайткач, машинадан келәтенә ташый иде. Шактый көч сорый торган авыр эш булса да, үзенә күрә күңелле дә була иде. Ул чакта әле Рифат ашлык тулы капчыкларны ике кулына икене күтәреп ташый иде. Бөтен ындыр табагында капчыкларны алай итеп ташучы башка кеше булмаганга, чират көтеп утыручы барыбыз да аңа гаҗәпләнә идек. Берничә елдан күрәм: Рифат капчыкларны берәрләп, җилкәсенә күтәреп ташый… Шунда апама: «Рифат та капчыкларны кеше төсле күтәрә башлаган икән», – дигән идем. Кибеттә күргәч тә, шул хәлләр искә төшеп, үзенә дә: «Бер кулга бер капчык күтәреп йөгергәннәр чыгамы, Рифат?» – дидем. Көлемсерәп куйды. Димәк, ризалашты.

Җырларда, кешегә гомерләр бер генә бирелә, дип җырлана. Миңа калса, гомер генә түгел, башкасы – сәламәтлеге, көч-куәте, энергиясе дә шул бер гомергә җитәрлек итеп, бер генә бирелә. Яши-яши, уйлана-уйлана, күзәтүләрдән, анализлардан чыгып, шундый нәтиҗәгә киләсең.

Күптән түгел бер газетадан шушыңа аваздаш бер фикер укыдым. «Икенче яшьлек беренчесен саклаганнарга гына килә», – диелгән иде анда. Рус телендә исә шундый эчтәлектәге җыр да бар икән. Димәк, болай уйлаучылар, шушындый нәтиҗәгә килүчеләр мин генә түгел. Болай булгач, адәм баласы әнә шул үз гомеренә җитәрлек итеп бирелгән, мәсәлән, сәламәтлеген, көч-куәтен үзе рациональ файдалана белергә тиеш булып чыга түгелме соң? Яшь чагында ук тотып бетерәме ул аны, әллә саклап, өлешләп бүлеп, бар гомеренә җитәрлек итеп тотарга өйрәнәме? Хикмәт, мөгаен, нәкъ менә шуңа өйрәнүдәдер дә инде.

Безне исә яшь чакта, көч чыкмыйча, көч керми, дип өйрәттеләр. Алга таба да җиде кат тирең чыккач кына шуңа бәрабәр күләмдә көч-куәт керәсен гел искәртеп тордылар. Әйтерсең аның чиге дә, кырые да юк, кимеми дә, киресенчә, тоткан саен арта гына бара. Ышанып үстек, чөнки өйдәге өлкәннәр үзләре дә шулай яшәде. Һәм… нәтиҗә нинди дип уйлыйсыз? Әби дә, әни дә сәламәтлекләрен бик иртә югалтты. Саный китсәң, алар гына да түгел. Авылда бит һәр кешенең яшәү рәвеше, эшкә мөнәсәбәте күз алдында. Үз-үзен саклап, көче кадәренчә генә эшләп, кирәк чакта ял итеп, кирәк чакта башкалар җилкәсенә салынып яшәгәннәр картлыкларына шыгырдап торган төз нараттай исән-имин килеп җитә. Һәм пенсиясенең чын мәгънәсендә рәхәтен татып, сызланмый-сыкранмый гомер итә. Күрәсең, һәр нәрсәдә, нәкъ җырдагыча, ипләп кирәк, әкрен кирәктер инде.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Безнең йолалар

Балачак хатирәсе

Баулы районында ел саен «Гореф-гадәт – изге мирас» бәйгесе уза. Анда һәр авыл сәхнәдә борынгы гореф-гадәтләр, йолаларны тәкъдим итә. Татар Томбарлысы авылының «Хатирә» фольклор ансамбле быел мунчала чыгару йоласын күрсәткән.

– Элек мунчала һәр өйдә бар, кечкенә чакта шуның белән юына идек. Хуш исе үзе генә ни тора! Татар гаиләсендә, әби-бабайлы йортта үскәннәр өчен балачак хатирәсе ул. Ләкин хәзер күпләр заманча мунчала куллана. Кызганыч, юкәнеке онытылып бара. Йола күрсәтергә эзли башлагач, кайберәүләр искереп беткәнен күтәреп килде. Тик аны сәхнәдән күрсәтеп булмый. Сатып алыйм дисәң дә юк әле ул. Аптырагач, Башкортстаннан алып кайттым, – ди авыл клубы мөдире, «Хатирә» ансамбле җитәкчесе Айгөл Нәүрүзбаева. – Кыш көне юкәнең кайрысын алып булмый. Шуңа күрә катыргыга мунчаланы берәмтекләп ябыштырырга туры килде.

Хәзер инде авылда кулдән мунчала чыгарган кеше дә сирәк, бу шөгыль турында белүче әби-бабайлар да картайган. Татар Томбарлысында да андыйлар бармак белән генә санарлык. Моңа кадәр Украинада яшәп, туган авылына кайткан Рамил Шәмсуллин тәртибен өйрәткән. Ул элек мунчаладан хәтта кәрзиннәр ясаган.

Рамил Шәмсуллин безгә кечкенә чагында юкәне ничек инешкә батырулары турында сөйләде. Ул вакытта аңа нибары 10 яшь кенә булган. Хәзер 30–40 ел авылда мондый гадәт юк инде.

– Мунчаланы теләсә ничек чыгармыйлар бит аны. Үз тәртибе бар. Яз беткәндә, юкәнең кайрысын алалар. Элек аны кышын ат арбасына, чаналарга утырып йөрер өчен салалар иде. Хәзер андый ихтыяҗ юк. Юкә агачының бер өлешен түгәрәкләп бәйләп, инеш төбенә батыра идек. Әзер булгач, тартып чыгарып, шуннан мунчала ясадык. Бер батырып куйсаң, биш-алты гаиләгә җитә, – дип сөйли 62 яшьлек Рамил Шәмсуллин.

Яшьлеген сагынып, берничә ел элек кибетләрдән мунчала эзләп тапкан ул. Әйтүенчә, мунчаланың вакыты үткән инде. «Олыгайган саен, арка ышкырга уңайлысы, ике тоткалысы кирәк. Шулай да мунчада хуш исен таратып, матурлык өчен эленеп торса, бик әйбәт. Без бит – юкә мунчаласы белән уынып үскән буын», – диде ул.

Мунчала чыгару йоласы өлкәннәрне яшьлегенә кайтарса, яшьләр исә юкә мунчаласы барлыгын белгән. Сәхнәдә генә калмасын иде инде ул.

Сәрия МИФТАХОВА

«ЭШ» 1918–1920 | «ТАТАРСТАН ХӘБӘРЛӘРЕ» 1920–1922 | «ТАТАРСТАН» 1922–1924 | «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» 1924–1951

«ВТ» – 105 12 март 2023

1951–1960 «СОВЕТ ТАТАРСТАНЫ» | 1960–1992 «СОЦИАЛИСТИК ТАТАРСТАН» | 1992– «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

Дәүләтьяров Әхмәтсафа Мостафа улы

1936–1937 ЕЛЛАРДА БАШ МӨХӘРРИР БУЛЫП ЭШЛИ

1937 ел аның өчен бик фаҗигале була. 16 сентябрьдә, «Кызыл Татарстан» газетасы редакторы булып эшләгән җиреннән аны кинәт кенә Халык Комиссарлары Советы рәисе итеп куялар. Шул ук вакытта СССР Югары Советына депутат итеп тә сайлыйлар. Әмма өч ай үтүгә, шул чорда гадәти булган гаепләүләр тагып, атарга хөкем итәләр.

Каргалыда

Әхмәтсафа Дәүләтьяров 1905 елның июлендә Оренбург губернасы Богырыслан өязенең Татар Каргалысы авылында туа. Әтисенең кечкенә генә җир пае булса да, гаиләне ашатырга җитми. Малай байларга ялланып көтү көтәргә, йорт тирәсендә эшләргә мәҗбүр була. Әнисе бик иртә дөнья куя. Әтисе дә вафат булгач, үги әнисе үзен «чын хуҗа» итеп тота башлый. Шуңа карамастан, Әхмәтсафа мәдрәсә тәмамларга мөмкинлек таба. Шунда яңа тормыш белән җенләнә башлый. 1919 елда беренчеләрдән булып комсомолга керә. Энесе Әхмәтханны да үз артыннан ияртә. Авылдашларын үгетләү җиңелрәк булсын өчен, дусты Саттар Иҗбулдин белән «Комсомол-яшьләр итек мастерское» уйлап табалар. Авылны атаман Дутов гаскәрләреннән саклар өчен, отрядка язылалар. Үги әнисе бу хәлләрне өнәп бетерми, җаен туры китереп, комсомол билетын яндыра. Шуннан соң Әхмәтсафа авылдан чыгып китә.

Оренбургта

Ул елларда Оренбургта яңача уку йортлары оештырыла башлый. Алар арасында «Хөсәения» мәдрәсәсе базасында төзелгән Татар халык мәгарифе институты да була. Бу уку йорты татар эшче һәм крестьян яшьләре өчен махсус оештырыла. 1921 елны Әхмәтсафа шунда керә. Муса Җәлил белән бергә укый. Аларны уку һәм җәмәгать эшләре генә түгел, дуслык җепләре дә берләштерә. Бервакыт, Каргалыга кайтып, Муса Җәлилнең балалар өчен язылган «Бал тәпәне» дип аталган спектаклен сәхнәгә куялар. Әмма бу гамәле белән Әхмәтсафа дошманнарын гына арттыра. Чөнки алар, спектакль куеп, яшьләрнең гает намазына җыелуын тыймакчы булалар, дингә каршы чыгыш ясыйлар. Тәэсире искиткеч көчле була: яшьләр хәтта клубка сыймый. Институт агитбригадасы авылларга еш чыга: лекция укыйлар, спектакльләр куялар. Дәүләтьяров көчле оратор һәм лектор була. Шул ук вакытта тыйнаклыгы да йөзенә чыга, бер эштән дә курыкмый, спорт белән шөгыльләнә, рәсем ясый, шигырь яза.

Үзбәкстанда

1924 елны, бөек юлбашчы үлгәч, ул, Ленин чакыруына җавап итеп, партиягә кандидат булып теркәлә һәм Күн заводы клубында татар агитбүлеге оештыра. Бер елдан соң Әхмәтсафаны тагын да зуррак сынаулар көтә: Совет властен урнаштыру өчен, Урта Азиягә җибәрәләр. Анда ул Үзбәкстанның Хәрәзм округы Коммунистлар партиясе комитетында мәгълүмат һәм статистика бүлеген җитәкли, аннан соң оештыру бүлегендә эшли, партия һәм совет кадрлары курсларында укыта, үзбәк, татар, казахлар арасында агитация эшләрен алып бара. Кышлакларда йөри, берничә тапкыр басмачылар һөҗүменнән чак кына котылып кала.

Бу командировкадан Дәүләтьяровны Казанга чакыралар һәм Татар коммунистлар университетына укырга юллыйлар. Университетны тәмамлагач, шул ук уку йортында белем алган Рабига Сарымсакова белән тыйнак кына туй ясыйлар.

Минзәләдә

1930 елның 20 мартында Минзәләдә кантонның партия конференциясе үткәрелә. Дәүләтьяровны пленум составына сайлыйлар. Ул кантонның мәдәният һәм мәгариф бүлеге мөдире булып тәгаенләнә. Конференция тәмамлануга, волостька чыгып китәргә туры килә, чөнки авылларда кулаклар коткы тараталар. Ул бу хакта көндәлегендә болай дип яза: «Төн уртасы. Без волость комитеты секретаре Фәйзуллин белән Иске Кормаш клубында кәгазьләр язып утырабыз. Кинәт: «Безгә сезнең колхозыгыз кирәкми!» – дигән тавышлар ишетелде. Мин өстәлдәге лампаны алып идәнгә бәрдем, аннан аяк белән тибеп, тәрәзәнең рамын җимердем. Башта Фәйзуллинны чыгардым. Аннан үзем сикердем. Яшелчә бакчасында качып ятарга туры килде…»

1930 нчы елларда республика территориясен районнарга бүләләр, кантоннар юкка чыга. Минзәлә шәһәре район үзәгенә әйләнә. 1930–1933 елларда Дәүләтьяров Минзәлә район комитетының мәдәният-мәгариф бүлеген җитәкли. Читтән торып Татар коммунистлар университетының аспирантурасында укый. 1933 елдан 1935 елга кадәр Минзәлә машина-трактор станциясендә сәяси бүлек начальнигы вазыйфаларын башкара. Аннан соң бер ел Кызыл Йолдыз район комитетында секретарь булып эшли.

Казанда

1936 елда өлкә комитеты карары белән аны Казанга, Таттосиздатта марксизм классиклары хезмәтләрен нәшер итү өчен чакырып алалар. Дәүләтьяров башта баш мөхәррир урынбасары, соңыннан баш мөхәррир булып эшли. Бер үк вакытта партком секретаре булып та сайлана.

Аннан соңгы хәлләр, әйткәнебезчә, яшен тизлегендә була: «Кызыл Татарстан» мөхәррире, Совнарком рәисе һәм… кара үлем. 32 яшьлек Дәүләтьяровны НКВД хезмәткәрләре эш кабинетында кулга алалар. Аның, бик соңга калып, хөкүмәтнең икенче көнне булачак чираттагы утырышына әзерләнгән чагы була. Шаһитлар әйтүенчә, рәисне бик каты кыйныйлар. ТАССР Югары Судының 1938 елның 9 маенда үткәрелгән утырышында Дәүләтьяров үлемгә хөкем ителә. Карар шул ук көнне тормышка ашырыла.

Тикшерү органнары соңрак, эзләрен югалтырга теләп, күрәсең, туганнарына Дәүләтьяровның 1942 елда кинәт кенә үлүе турында белешмә бирәләр. Әмма Әхмәтсафаның уллары әтиләренең, атып үтерелгәннән соң, Архангельск зиратындагы туганнар каберлегендә җирләнгәнен ачыклый алалар. Ун елдан соң Әхмәтсафаның хәләл җефете дә Мордва лагерьларында җан тәслим кыла. Ул иренә гаеп тагылган документларга кул куймый.

Әхмәтсафа Дәүләтьяров, җинаять составы булмау сәбәпле, 1956 елда СССР Югары Советы хәрби коллегиясе тарафыннан аклана.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

2023–2024 ЕЛЛАРГА СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ СӘЯСӘТ ҮТКӘРҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ПАРТНЕРЛЫКНЫ ҮСТЕРҮ ТУРЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҺӨНӘР БЕРЛЕКЛӘРЕ ФЕДЕРАЦИЯСЕ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭШ БИРҮЧЕЛӘР БЕРЛӘШМӘЛӘРЕНЕҢ КООРДИНАЦИЯ СОВЕТЫ ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АРАСЫНДА

РЕСПУБЛИКА КИЛЕШҮЕ

Казан шәһәре 2022 ел, 28декабрь, № 343

Татарстан Республикасы һөнәр берлекләре федерациясе, аның әгъза оешмалары булган һөнәр берлекләре оешмалары йөзендә (алга таба – һөнәр берлекләре), Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең координация советы, республика эш бирүчеләре йөзендә (алга таба – Эш бирүчеләр), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (алга таба – Хөкүмәт), алга таба – Яклар дип атала, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы һәм «Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнары турында» 2004 елның 26 июлендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, социаль-хезмәт һәм аларга бәйле икътисадый мөнәсәбәтләрне һәм аларны тормышка ашыру буенча уртак гамәлләрне җайга салуның төп принциплары буенча Якларның үзара килешенүле позицияләрен билгеләгән бу Килешүне имзалады.

Яклар шуны таный: Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең төп стратегик максаты булып лаеклы хезмәт, икътисадны тотрыклы төстә үстерү һәм көндәшлеккә сәләтен арттыру, демографик вазгыятьне яхшырту, эшләүче халыкның эш хакын, халыкның керемнәрен үстерү һәм аз керемлеләр санын киметү, керемнәр һәм эш хакы өлкәсендә дифференциацияне киметү, пенсия белән тәэмин итү дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт шартларын яхшырту, эш белән тәэмин ителешнең нәтиҗәлелеген тәэмин итү, Татарстан Республикасы бюджет чараларыннан нәтиҗәле файдалану нигезендә социаль өлкәне камилләштерү, дәүләт идарәсенең нәтиҗәлелеген, социаль гаделлекне, җаваплылыкны арттыру һәм социаль партнерлык принципларын гамәлгә кертү нигезендә халыкның яшәү дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү тора.

Яклар социаль партнерлык, социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен коллектив-килешүле җайга салу принциплары нигезендә, үзара мөнәсәбәтләрне үстерү, Килешүдә билгеләнгән йөкләмәләрне һәм килешенүле бурычларны үтәүне үз өстенә ала.

Бу Килешүнең йөкләмәләре һәм гарантияләре минималь булып тора һәм хезмәткәрләренең социаль һәм икътисадый яклануын киметү ягына үзгәртелә алмый.

Яклар, милек формаларына һәм кайсы ведомство карамагында булуларына бәйсез рәвештә, оешмаларда коллектив килешүләр, тармак (тармакара) һәм территориаль килешүләр төзү зарурлыгын таный һәм социаль партнерлык принципларын үстерүче оешмаларга төрле яклап ярдәм итү бурычын үз өстенә ала. Шул ук вакытта бу Килешү социаль партнерлык системасында коллектив-килешүле процессның бер өлеше булып тора һәм килешүләр, коллектив килешүләр эшләү һәм төзүгә нигез булып хезмәт итә.

Куелган максатларга ирешү өчен Яклар түбәндәге йөкләмәләрне үзенә кабул итә:

1. Икътисад һәм җитештерүне үстерү

Яклар фикеренчә, Килешү гамәлдә булган чорда Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәте түбәндәгеләргә йөз тотарга тиеш:

икътисад үсешенең төп факторы буларак кеше капиталын үстерү, гражданнарның үзмәшгульлеге өчен шартлар формалаштыру, хезмәткәрләрнең реаль керемнәре, пенсия белән тәэмин итү һәм халыкның тормыш дәрәҗәсе үсү, фәкыйрьлек сәбәпләрен бетерү;

икътисадны модернизацияләү, аның структурасын диверсификацияләү, үсүнең инновацион моделенә күчү, реиндустриализация һәм икътисад тармакларын үсешен тизләтү;

хезмәт ресурсларының икътисад ихтыяҗларына туры килүен тәэмин итү;

Татарстан Республикасы икътисады үсешендә эшмәкәрлекнең һәм һөнәр берлекләренең иҗтимагый статусын һәм әһәмиятен күтәрү;

нәтиҗәле һәм тигез бюджет сәясәте үткәрү;

икътисадның өстенлекле секторларына булышлык күрсәтү нигезендә Татарстан Республикасы икътисадының импортка бәйлелеген киметү;

чимал булмаган экспортны стимуллаштыруга булышлык күрсәтү.

Яклар, бу Килешүне тормышка ашыру максатыннан чыгып, үзенә йөкли:

1.1. Инновацион икътисадны, кече һәм урта бизнесны үстерү, урта сыйныфны формалаштыру, оешмаларның финанс-икътисадый хәлен ныгыту, аларның көндәшлеккә сәләтен һәм инвестицион яктан җәлеп итү дәрәҗәсен арттыру өчен уңай шартлар тудыруга ирешүне.

1.2. Дәүләт стратегик планлаштыру системасы, шул исәптән республиканы социаль-икътисадый үстерүнең өстенлекле юнәлешләрен билгели торган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе кысаларында, социаль-хезмәт һәм алар белән бәйле башка мөнәсәбәтләргә кагылышлы стратегик документларны әзерләү, экспертизалау, үтәү һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләүдә үз компетенциясе кысаларында, шулай ук Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең стратегик документларын тормышка ашыруның арадаш нәтиҗәләрен карау һәм тиешле документларны тәгәлләштерү буенча тәкъдимнәр бирү кысаларында үзара багланышларны гамәлгә ашыруны.

1.3. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына һәм 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеш фаразының төп күрсәткечләре һәм бюджеты проекты буенча консультацияләр үткәрүне, шулай ук хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм аларга туры бәйле башка мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив-хокукый актлар проектларын, социаль-икътисадый мәсьәләләр буенча максатчан программалар буенча башлангыч фикер алышуны һәм аларны социаль партнерлар белән килештерүне.

1.4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертканче Татарстан Республикасы бюджеты проектының социаль аспектларын Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе утырышында карап тикшерүне.

Татарстан Республикасы бюджеты проектын әзерләгәндә кеше капиталын, шул исәптән сәламәтлек саклауны, мәгарифне, фәнне, актив мәшгульлекне, транспорт һәм социаль инфраструктураны саклауга һәм үстерүгә йөз тоткан тармакларның өстенлекле яклауыннан чыгып эш итәргә, шулай ук тулы һәм тотрыклы эш белән тәэмин итүгә һәм яңа эш урыннары булдыруга юнәлдерелгән чыгымнарны арттыру мөмкинлеген карарга.

1.5. Бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген күтәрүгә һәм бюджет чаралары нәтиҗәсез һәм максатка ярашсыз тотуны бетерүгә булышлык күрсәтүне.

1.6. Җирле товар җитештерүчеләргә ярдәм итү шартларын тудыруга булышуны, аларның финанс хәлен тотрыклыландыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруны.

1.7. Авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәрту, республиканың азык-төлек иминлеген тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруны, агросәнәгать комплексында хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга ярдәм итүне.

1.8. Билгеләнгән тәртиптә Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе белән, шулай ук республиканың социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләрен буенча тиешле тармак һәм территориаль комиссияләр белән берлектә эшләүне.

1.9. Түбәндәгеләр буенча чаралар күрү:

Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен үстерүнең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы нигезендә эшләнгән илкүләм проектларны гамәлгә ашыру кысаларында төбәк проектларының максатчан күрсәткечләренә ирешү;

гражданнарның тормышта үз урынын табу, хезмәткәрләрнең керемнәрен үстерү һәм халыкның тормышын яхшырту, фәкыйрьлек сәбәпләрен юкка чыгару өчен шартлар булдыру;

икътисадый үсешнең төп факторы буларак, кеше потенциалын үстерү, социаль өлкәне һәм кеше капиталын үстерүдә катнашу ягыннан инициативаларны хуплау буенча;

заманча югары җитештерүчәнлекле куркынычсыз эш урыннары булдыру, җитештерелә торган продукциянең яңа югары технологияле үрнәкләрен булдыру;

оешмаларның бөлгенлеккә төшүен кисәтү һәм булдырмау, аларны финанс яктан савыктыру, эшсезлекне эшләүче оешмаларның санын киметү.

1.10. Эшләнү стадиясендә халыкның акча керемнәре динамикасы белән килештерелгән һәм инфляция дәрәҗәсен киметүгә юнәлтелгән дәүләт бәя һәм тариф сәясәтенең төп юнәлешләре буенча консультацияләр үткәрүне, тарифлар үсүнең халык өчен һәм икътисадый эшчәнлекнең аерым төрләре өчен нәтиҗәләрен бәяләп һәм бәяләрнең, җайга салынулы тарифларның артуының халыкның тормыш дәрәҗәсенә һәм оешмалар һәм икътисадның төрле секторлары эшләвенең нәтиҗәлелегенә тискәре йогынтысын минимальләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләп.

1.11. «Россия югары социаль нәтиҗәле оешма» бөтенроссия конкурсында һәм коммерциячел булмаган башка социаль юнәлешле конкурсларда катнашуга ярдәм итүне.

1.12. Хезмәт законнарын һәм хезмәткә хокук нормаларыннан торган башка норматив-хокукый актларны (алга таба – хезмәт турында законнар), һөнәр берлекләре турында законнарны, килешүләр һәм коллектив килешүләр шартларын үтәүне тәэмин итүне.

Һөнәр берлекләре түбәндәгеләргә бурычлы:

1.13. Лаеклы хезмәт хакына, нәтиҗәле эш белән тәэмин итүгә, имин шартларга һәм хезмәтне саклауга, сәламәтлеккә, өзлексез белем алуга һәм хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрүгә ирешү нигезендә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә ярдәм итәргә.

1.14. Эш бирүчеләр белән берлектә, югары җитештерүчәнлекле хезмәт өчен хезмәткәрләрне кызыксындыру чараларын эшләргә, хезмәткәрләр тарафыннан эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен үтәүгә, хезмәт коллективларында уңай климат булдыруга һәм саклауга ярдәм итәргә.

1.15. Оешмалар бетерелгәндә, үзгәртеп оештырылганда, хосусыйлаштырылганда яки милекчесе алышынганда, профиле үзгәртелгәндә яки бөлгенлеккә чыкканда; һөнәри стандартларны кертү белән бәйле чаралар үткәрелгәндә; һәлакәтләр, куркыныч табигать күренешләре, катастрофа, әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыручы авырулар, табигый һәм башка бәла-казалар нәтиҗәсендә килеп чыккан гадәттән тыш хәлләрдә, кешеләр сәламәтлегенә яисә әйләнә-тирә мохиткә зыян, шактый матди югалтулар булганда һәм халыкның тормыш эшчәнлеге шартлары бозылганда (алга таба – гадәттән тыш хәлләр) хезмәткәрләрнең мәнфәгатен яклауны тәэмин итәрдәй законнарның һәм бүтән норматив хокукый актларның, шул исәптән сәламәтлекне саклау өлешендә үтәлешенә һөнәр берлекләре контролен тотуны гамәлгә ашырырга.

Эш бирүчеләр түбәндәгеләр буенча бурычлы:

1.16. Социаль әһәмияте бурычларны хәл итүдә катнашуны һәм социаль җаваплылык принципларында эшмәкәрлек эшчәнлеген алып барырга.

1.17. Елына кимендә ике тапкыр хезмәткәрләргә, аларның һөнәр берлекләре оешмаларына коллектив килешүләрне, шартнамәләрне үтәү, оешманың финанс-икътисадый эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм үсеш перспективалары турында мәгълүмат тапшырырга. Якларга алга торган үзгәрешләр: оешмаларны үзгәртеп оештыру, хосусыйлаштыру, милекчесен алыштыру, профилен үзгәртү, бөлгенлеккә чыгару яки бетерү турында мәгълүмат бирергә.

1.18. Коллектив-килешү кампаниясе барышында сайланулы һөнәр берлеге оешмаларына финанс-хуҗалык эшчәнлеге, социаль-хезмәт мәсьәләләре буенча комачаулыксыз мәгълүмат (федераль законнар нигезендә коммерция сере булып торган мәгълүматтан тыш) алуны тәэмин итәргә.

1.19. Оешмаларын бөлгенлеккә төшүен кисәтү, аларны финанс ягын савыктыру буенча, судка кадәрге процедураларны тулы күләмендә кулланып, үз вакытында чаралар күрергә.

1.20. Башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органын предприятиенең финанс торышы начараю сәбәпле консультацияләргә, хәлне тотрыклыландыру буенча һәм хезмәткәрләрне яклау буенча уртак чаралар эшләүгә җәлеп итәргә.

1.21. Төп производство фондларын яңартуга, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруны, сыйфат менеджменты системасын кулланып, инновацион технологияләрне гамәлгә кертүне тәэмин итәргә.

1.22. Предприятиеләрнең икътисадый сәясәте, чимал, материаллар комплектлау әйберләре сатып алганда Татарстан Республикасы электрон товар-мәгълүмат системасы ресурсларыннан (ЭТИС, www.tattis.ru сайты) актив файдалану мәсьәләләре буенча нигезле карарлар кабул итәргә.

1.23. Эшмәкәрлек һәм кече бизнес өлкәсендә шәхси инвестицияләр, шул исәптән чит илләрдән инвестицияләр җәлеп итүгә ярдәм итәргә.

1.24. Республика эчендә һәм төбәкара производство кооперациясен үстерү буенча чаралар күрергә.

1.25. Россия Федерациясе күргәзмәләрендә һәм чит илләрдә фәнни-техник семинарлар, күргәзмәләр, реклама кампанияләре, республика оешмалары товарлары һәм хезмәтләр күрсәтүләрен тәкъдим итүләр, коллектив экспозицияләр оештырырга.

Хөкүмәт түбәндәгеләргә бурычлы:

1.26. Структур реформалар уздыруны һәм, шул исәптән социаль хезмәтләр күрсәтүче икътисад тармакларын модернизацияләүгә ярдәм итәргә.

1.27. «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон билгеләгән тәртиптә һәм таләпләрдән чыгып, сатып алуларны хәл итү буенча комиссияләр составында эшләү өчен эш бирүчеләр берләшмәләре вәкилләрен һәм һөнәр берлекләрен җәлеп итәргә (килешү буенча).

1.28. Гамәлдәге закон нигезендә, Татарстан Республикасында инвестицион эшчәнлек субъектларына дәүләт ярдәме чараларын күрсәтергә.

1.29. Оешмаларның икътисадый тотрыклылыгын арттыру максатыннан чыгып, республика эчендә һәм төбәкара производство кооперациясен үстерүгә ярдәм итәргә булышырга.

1.30. Билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә: социаль әһәмияткә ия инфраструктура, инвестиция һәм бүтән проектлар һәм программаларны, шул исәптән кече һәм урта эшмәкәрлек һәм һөнәри белем бирү өлкәсендә, тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы белән хосусый партнерлар арасында үзара файдалы хезмәттәшлекне үстерүне;

кеше потенциалын үстерүгә юнәлтелгән нәтиҗәле бюджет сәясәтен алып баруны, гражданнарны социаль яклауны көчәйтү, икътисадый һәм социаль тигезсезлекне киметү, тотрыклы үсешне тәэмин итә торган яңа икътисадый структураны формалаштыруны;

социаль гаделлек принципларын тормышка ашыруга юнәлтелгән һәм икътисадның өстенлекле өлкәләрен үстерүгә инвестицияләр җәлеп итүне стимуллаштыра торган нәтиҗәле салым сәясәтен алып баруны;

импортны алыштыру һәм икътисадның җитештерү өлкәләрен үстерү программаларын тормышка ашыруга ярдәм күрсәтүне.

1.31. Татарстан Республикасы бюджетында каралган акча чикләрендә иң нәтиҗәле һәм әһәмиятле инновацион проектларга дәүләт ярдәме буенча республика конкурслары һәм чаралар үткәрүне оештыруны.

2. Халыкның хезмәт хакы, керемнәре һәм тормыш дәрәҗәсе

Яклар:

2.1. Алдагы чорда социаль сәясәтнең төп максаты булып реаль эш хакының динамикалы төстә үсүен тәэмин итәрдәй лаеклы хезмәт өчен шартлар тудыру, хезмәт өчен түләүгә дәүләт гарантияләрен тормышка ашыру, керемнәр сәясәтен камилләштерү, халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, социаль тигезсезлек дәрәҗәсен киметү тора, дигән фикердә тора.

2.2. Эш хакының реаль булуын күтәрүне тәэмин итү буенча закон нормаларын тормышка ашыруда булышлык күрсәтәләр.

2.3. «Татарстан Республикасында минималь куллану бюджеты турында» 2008 елның 23 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыруны тәэмин итә, шуның нигезендә, социаль-икътисадый вазгыятьтән чыгып, тиешле чорга Татарстан Республикасында минималь эш хакы турында килешү эшли.

Үз вәкаләтләре кысаларында Татарстан Республикасында минималь эш хакы турында килешүне үтәүгә контрольне гамәлгә ашыралар.

2.4. Аз керемле халыкның керемнәрен яшәү минимумыннан ким булмаган дәрәҗәдә арттыру буенча чаралар күрә.

2.5. Чираттагы елга һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә куллану бәяләре үсү белән бәйле бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең эш хакын индексацияләү өчен финанслау күләмен билгелиләр.

2.6. Икътисадның бюджеттан тыш секторында төзелә торган килешүләрдә, хезмәткә түләүнең тармак системалары параметрларын күздә тотарга тәкъдим итәләр.

2.7. Эшкә сәләтле халыкка үз керемнәре хисабына сыйфатлы социаль хезмәтләрне куллануның югарырак дәрәҗәсен һәм лаеклы тормышны тәэмин итү мөмкинлеге бирердәй икътисадый шартлар тудыру сәясәтен алып бара.

2.8. Дәүләт һәм тариф сәясәтенең төп юнәлешләре буенча, халык өчен тарифлар арту нәтиҗәләрен һәм икътисадый эшчәнлекнең аерым төрләре өчен нәтиҗәләрен бәяләп, халыкның тормыш дәрәҗәсенә бәяләр һәм җайга салынулы тарифлар үсешенең тискәре йогынтысын минимальләштерү буенча Якларның тәкъдимнәрен исәпкә алып, дәүләт хакимияте органнары тарафыннан чаралар үткәрәләр.

2.9. Милек формаларына һәм нинди ведомство карамагында булуларына карамастан, оешмаларда хезмәткәрләр өчен реаль эш хакын арттыруны тәэмин итә торган чаралар эшли һәм аларны тормышка ашыра.

2.10. Килешүләр һәм күмәк шартнамәләр төзү юлы белән түләү системасын уңайлаштыруны һәм хезмәтне нормалаштыруны тәэмин итә.

2.11. Эш хакын түләү буенча бурычларны бетерү, милек формаларына һәм нинди ведомство карамагында булуларына карамастан оешмалар эшчәнлеге туктатылган очракта алар түли алмаганда хезмәткәрләрнең эш хакын алуын тәэмин итү чараларын эшли һәм тормышка ашыра.

2.12. Түбәндәгеләргә чаралар күрә:

эш вакыты нормасын тутырган һәм хезмәт нормаларын (хезмәт бурычларын) үтәгән бер разрядлы тарифны (окладны) федераль законда билгеләнгән хезмәткә түләүнең минималь күләменнән ким булмаган дәрәҗәгә җиткерү;

түләүне республика уртача айлык эш хакын әлеге Килешүгә теркәлгән кушымтада билгеләнгәннән ким булмаган дәрәҗәгә җиткерү.

Һөнәр берлекләре:

2.13. Күмәк-килешүне җайга салу кысаларында чаралар күрә:

икътисадның бюджеттан тыш секторында минималь хезмәт хакы турында Татарстан Республикасында гадәти гаиләнең бер әгъзасына минималь куллану бюджеты күләменә кадәр җиткерү буенча;

эш хакын түләү һәм аны индексацияләү срокларын үтәү буенча, шул исәптән бюджет өлкәсендә;

икътисадның бюджеттан тыш секторы хезмәткәрләренең хезмәт хакы структурасында хезмәт өчен түләүнең тариф өлешен (окладын) кимендә 60 процентка җиткерү буенча.

2.14. Оешмаларда хезмәткә түләүнең «күләгәле» схемаларыннан китүгә ирешә.

2.15. Хезмәт законнары мәсьәләләре буенча һөнәр берлекләре әгъзаларына бушлай консультация ярдәме күрсәтә, хезмәт бәхәсләрен (низагларын) хәл кылуда, шул исәптән судларда, аларның мәнфәгатьләреннән чыгып эш итә.

2.16. Хезмәткә түләү мәсьәләләре, шул исәптән эш хакын исәпләүнең тулылыгы һәм үз вакытында түләнүе, товарларга һәм хезмәтләргә куллану бәяләре үсү белән бәйле аны индексацияләү мәсьәләләре буенча законнары һәм бүтән норматив-хокукый актларны үтәүгә законнар нигезендә контрольне гамәлгә ашыра.

2.17. Хезмәткә түләү мәсьәләләре буенча законнарны һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешен тәэмин итү буенча, бозуларны юкка чыгару һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрү өчен, күзәтчелек һәм контроль буенча тиешле дәүләт органнарына мөрәҗәгать итә.

Эш бирүчеләр:

2.18. Икътисадның бюджеттан тыш секторында минималь эш хакын Татарстан Республикасында гадәти гаилә әгъзасына туры килә торган минималь куллану бюджеты күләменә җиткерү чараларын күрә. Финанс-икътисадый хәле минималь хезмәт хакын күрсәтелгән дәрәҗәгә җиткерү мөмкинлеге бирмәгән аерым оешмалар буенча коллектив килешүләрдә һәм (яки) шартнамәләрдә минималь хезмәт хакын Татарстан Республикасында гадәти гаилә әгъзасына туры килә торган минималь куллану бюджеты күләменә җиткерү буенча конкрет чаралар һәм сроклар билгеләнә.

2.19. Күмәк-килешүле җайга салу кысаларында, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә хезмәт хакын, шул исәптән тоткарланган хезмәт хакын индексацияләүне тәэмин итә.

2.20. Икътисадның бюджеттан тыш секторында хезмәткәрләренең хезмәт хакы составында тариф өлешен (окладын) кимендә 60 процент күләмендә билгели.

2.21. Хезмәткәрләргә бирелергә тиешле хезмәт хакын үз вакытында түләүне, түләнә торганяллар өчен түләүне, башка түләүләрне Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, шартнамәләр һәм күмәк килешүләр нигезендә, шул исәптән хезмәт функцияләрен вакытлыча дистанцион режимда башкару очракларында тәэмин итә, хезмәт өчен түләүнең «күләгәле» схемаларын куллануга юл куймыйлар.

2.22. Шартнамәләр, күмәк килешүләр, локаль норматив актлар белән, хезмәт турында законнар һәм хезмәткә хокук нормаларыннан торган башка норматив-хокукый актлар нигезендә, хезмәткәрләрнең вәкиллекле органы фикереннән чыгып, хезмәткә түләү системаларын, тариф ставкалары, окладлар (вазыйфаи окладлар) күләмнәрен, компенсация характерындагы өстәп түләүләр һәм өстәмәләрне кертеп, шул исәптән нормаль шартлардан үзгә шартларда эшләгән өчен, кызыксындыру характерындагы өстәп түләүләр һәм өстәмәләр системаларын һәм премия системаларын билгели.

2.23. Түбәндәгеләрне тәэмин итү буенча коллектив-килешүле җайга салу кысаларында чаралар күрә:

Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре, аларның урынбасарлары, баш хисапчыларының уртача айлык хезмәт хакы һәм мондый предприятиеләр хезмәткәрләренең уртача айлык хезмәт хакы чагыштырмасының Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чик дәрәҗәсен саклау;

икътисадның бюджеттан тыш секторы оешмаларында (Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләреннән тыш) иң күп хезмәт хакы алучы хезмәткәрләрнең 10 процентының һәм 10 процент иң аз хезмәт хакы алучы хезмәткәрләрнең уртача айлык хезмәт хакы чагыштырмасының 10нан артмавын билгеләү.

2.24. Хезмәткәрләрнең сайланулы органы фикерен исәпкә алып, хезмәткә түләү системаларын билгели торган локаль норматив актлар кабул итәләр.

2.25. Хезмәткәрләрнең язмача гаризасы нигезендә ай саен хезмәт хакыннан һөнәр берлекләренең әгъзалык кертемнәрен тотып кала һәм аларны, банклар тарафыннан хезмәт хакына акча бирү белән бер үк вакытта, һөнәр берлекләре органнары счетларына күчерә.

Хөкүмәт:

2.26. Бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакы күләме кимүне булдырмау буенча чаралар күрә, шулай ук эш хакын, законнарда каралган пособиеләр һәм социаль түләүләрне, инфляция дәрәҗәсеннән чыгып, индексацияләүне тәэмин итә.

2.27. Үз вәкаләтләре чикләрендә, шартнамәләрдә һәм коллектив килешүләрдә билгеләнгән хезмәткә түләү буенча гарантияләрнең эш бирүчеләр тарафыннан тәэмин ителүен, стипендияләрнең, пособиеләрнең һәм башка социаль түләүләрнең үз вакытында түләнүен, шулай ук бюджет акчасын максатчан файдалануын контрольдә тота.

2.28. Инфляция дәрәҗәсен киметүгә юнәлдерелгән икътисадый яктан нигезләнгән тариф һәм бәя сәясәтен үткәрә. Электр һәм җылылык энергиясенә, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә тарифларның үсүен чикләү буенча, халыкның керемнәре үсүдән һәм гражданнарга тиешле дәрәҗәдә социаль ярдәм күрсәтүгә ирешүдән чыгып, чаралар күрә.

3. Халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт базарын үстерү

Яклар, халыкны нәтиҗәле, ихтыяри сайлап алынган эш белән тәэмин итү дәүләтнең өстенлекле эш юнәлешләреннән берсе, дигән фикердә тора.

3.1. Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүнең актив сәясәтен тормышка ашыру, гражданнарның көндәшлек сәләте һәм хезмәт мобильлеге дәрәҗәсен арттыру максатларында, Яклар:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014–2025 елларга Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014–2025 елларга Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын (алга таба – «2014–2025 елларга Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы) тормышка ашыруда, шулай ук кирәк булганда хезмәт базарын тотрыклыландыру буенча өстәмә чаралар эшләүдә һәм аларны гамәлгә ашыруда катнаша;

«Демография» илкүләм проектының «Эш белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү» һәм «Өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм күрсәтү һәм аларның тормыш сыйфатын яхшырту программасын эшләү һәм тормышка ашыру» федераль проектларын гамәлгә ашыру буенча чаралар күрә;

хезмәт һәм мәшгульлек базарын хокукый җайга салуны камилләштерү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек итә, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү актив сәясәтенең яңа юнәлешләрен һәм аларны финанслар белән тәэмин итү буенча тәкъдимнәр эшли;

төбәк һәм һөнәри-квалификация күзлегеннән чыгып, озак вакытлы перспективага кадрлар әзерләүгә ихтыяҗны фаразлау системасын формалаштыра;

һөнәри стандартлар системасын һәм һөнәри квалификацияләр сертификациясен гамәлгә кертү ягыннан һөнәри квалификацияләрне үстерүнең төбәк системасын формалаштыру чараларын тормышка ашыра;

хезмәт хакы әйбәт булган һәм хезмәт шартлары имин булган югары технологияле һәм югары җитештерүчәнлекле яңа эш урыннары булдыруга булышлык күрсәтә;

оешмаларга, өзлексез һөнәри үсеш системасын булдыру нигезендә, һөнәри потенциалны саклауга һәм аннан нәтиҗәле файдалануга, хезмәткәрләрнең хезмәт базарында көндәшлеккә сәләтен арттыруга юнәлдерелгән социаль программалар һәм планнар эшләүгә ярдәм итә;

хезмәткәрләрнең квалификация дәрәҗәсен күтәрүгә бәйле эш урынына, хезмәткәрләрнең һөнәри әзерлек дәрәҗәсенә һәм эш хакы үсешенә таләпләр нигезендә Илкүләм квалификация системасын үстерә;

гражданнарны кирәкле һөнәрләр (белгечлекләр) буенча, шул исәптән пенсия алды яшендәге затларга, Татарстан Республикасы дәүләт халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте учреждениеләре аша һөнәри укытуны оештыра;

бюджет чаралары һәм оешмалар чаралары хисабына хезмәткәрләрнең квалификациясен даими күтәрүне тәэмин итә;

эштән җибәрелә торган хезмәткәрләргә өстәмә социаль ташламалар билгели, аларны алдан ук башка һөнәргә өйрәтүне тәэмин итә һәм эшкә урнашуларына ярдәм итә.

3.2. 2023–2024 елларда теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсенең Татарстан Республикасында эшче көчләр саныннан иң күбе 0,6 процентка кадәр артуын булдырмау буенча чаралар күрә.

3.3. Эшсезлек республика буенча уртача күрсәткечтән шактый артыграк булган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә халыкны эш белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар күрә.

3.4. Шәһәр төзүче оешмаларның хезмәткәрләрен эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтүгә һәм моношәһәрләрдә халыкны эш белән тәэмин итүне үстерүгә юнәлдерелгән шул исәптән превентив характердагы чараларны эшли һәм тормышка ашыра.

3.5. Министрлар Советы – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1993 ел, 5 февраль, 99 нчы карары белән расланган Массакүләм эштән җибәрү шартларында эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү эшен оештыру турында нигезләмәнең I бүлегендәге 1 пунктка ярашлы рәвештә тармак һәм территориаль шартнамәләрдә массакүләм эштән җибәрү критерийларын билгеләүне тәкъдим итә.

3.6. Хезмәткәрләрне массакүләм эштән чыгаруларга китерергә мөмкин хәлләрне фаразлый һәм кисәтә.

3.7. Хезмәткәрләрне массакүләм эштән чыгару көтелгән очракта эштән җибәрелә торган хезмәткәрләрне эшкә урнаштыру мәсьәләләре буенча социаль партнерлык яклары вәкилләренә үзара консультацияләр үткәрә. Консультацияләр йомгаклары буенча эштән чыгарыла торган хезмәткәрләрне эшкә урнаштыруга булышлык күрсәтүгә юнәлтелгән чаралар эшләнә.

3.8. Укучыларны һәм студентларны билгеләнгән тәртиптә түләүле иҗтимагый, вакытлыча һәм сезонлы эшләрдә катнашуга җәлеп итә.

3.9. Билгеләнгән тәртиптә укучыларны түләүле җәмәгать, вакытлыча һәм сезонлы эшләрдә катнашырга җәлеп итә.

3.10. Шул исәптән, хезмәт базарын һәм мәгариф системасын җайга салучы норматив-хокукый актларны камилләштерү, һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлап чыгучыларны тәүге эш урыннары белән тәэмин итү буенча тәкъдимнәр эшләү һәм кертү юлы нигезендә, чаралар күрә.

Һөнәр берлекләре:

3.11. Шартнамәләргә һәм коллектив килешүләргә нәтиҗәле эш урыннары санын арттыруга, персоналны производство эчендә укыту-өйрәтүне үстерүгә, квалификация күтәрү, квалификацияләр сертификациясе үтүгә, эштән җибәрелергә тиешле хезмәткәрләрне алдан ук башка һөнәргә өйрәтүгә юнәлдерелгән чаралар кертүгә ярдәм итә.

3.12. Һөнәр стандартлары системасын формалаштыруда һәм оешмаларга һөнәр стандартларын кертү буенча чаралар үткәрүдә катнаша.

3.13. Вазыйфалары һөнәри стандартлар таләпләренә туры китерелергә тиеш хезмәткәрләр хокукларын саклауга һөнәр берлекләре контролен гамәлгә ашыра.

3.14. Квалификация дәрәҗәләре һөнәри стандартлар таләпләренә туры килми торган хезмәткәрләрне эш бирүчеләр исәбеннән һөнәри укыту буенча йөкләмәләрне коллектив килешүләренә һәм шартнамәләренә кертүгә ирешә.

3.15. Шартнамәләр һәм коллектив килешүләре аша хәрби хезмәткә чакырылу яки аны алыштыра торган альтернатив граждан хезмәтенә җибәрелү белән бәйле хезмәт шартнамәләре туктатылган, хезмәттән азат ителгәннән соң өч ай эчендә элеккеге эш бирүчесенә мөрәҗәгать иткән гражданнарны, аларның һөнәри квалификациясе нигезендә эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтә.

3.16. Һөнәри квалификацияләр бәяләмәсе һәм сертификациясе процедурасын узып, компетентлык сертификаты алган яшь белгечләр һәм хезмәткәрләр өчен өстәмә компенсацияләр һәм ташламаларга ирешә.

3.17. Һөнәр берлеге оешмаларына, һөнәр берлеге әгъзаларына, шулай ук аз керемле һәм эшсез гражданнарга халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәт законнарын куллану мәсьәләләре буенча бушлай юридик ярдәм күрсәтә.

3.18. Үз вәкилләре аша халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү буенча координация комитетлары (советлар) эшендә катнаша.

3.19. Җенесе, яше буенча кимсетү, административ басым ясау (эштән кыскарту, эштән җибәрү, хезмәт хакы түләмичә чираттагы ял бирү) фактларына юл куймый.

Эш бирүчеләр:

3.20. Тулы һәм тотрыклы мәшгульлекне саклау, хезмәт хакы әйбәт булган һәм хезмәт шартлары имин булган нәтиҗәле яңа эш урыннарын, шул исәптән хатын-кызлар һәм яшьләр өчен, булдыру чараларын күрә.

3.21. Хезмәткәрләрнең санын яки штатын кыскарту чаралары үткәргәндә, хезмәткәрләргә тулы булмаган эш режимы керткәндә хезмәт законнары нормаларын үти, хезмәткәрләрне хезмәт хакы түләнми торганялларга, үз теләге буенча эштән китүгә мәҗбүриләүләргә юл куймый.

3.22. Һөнәр берлекләренә үз артыннан эш урыннары кыскару һәм хезмәткәрләрнең хезмәт шартлары начараюга китерә торган күздә тотылган структур үзгәрешләр, җитештерүне тулы яки өлешчә туктатып тору һәм башка гамәлләр турында хәбәр итә.

3.23. Россия Федерациясе гражданнарын эшкә урнаштыру өстенлеге принцибы нигезендә чит ил эшче көчләреннән файдалануны гамәлгә ашыра.

3.24. Персоналны фирма эчендә һөнәри яктан әзерләү, башка һөнәргә өйрәтү һәм квалификациясен күтәрү системасын булдыру чараларын хәл итә, хезмәткәрләрнең өзлексез һөнәри үсешен, шул исәптән эш урыннарында тәэмин итә. Коллектив килешү нигезендә, эштән азат ителә торган хезмәткәрләрне алдан башка һөнәргә өйрәтеп кую мөмкинлеге булдыра.

3.25. Һөнәр стандартларын гамәлгә кертү белән бәйле локаль норматив актлар кабул иткәндә беренче һөнәр берлекләре фикерен сорый.

3.26. Квалификация дәрәҗәләре һөнәр стандартлары таләпләренә туры килми торган хезмәткәрләрне оешма акчасы исәбеннән һөнәри укытуны оештыру буенча чаралар күрә.

3.27. Хезмәткәрләрне массакүләм төстә кыскартуны кисәтү чаралары күрә, ә кыскарту янау очрагында кимендә өч ай алдан Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренә һәм һөнәр берлекләре оешмаларына хәбәр итеп куя.

3.28. Вакансияләр турында мәгълүматлар бирү буенча Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре белән урыннарда үзара багланышларны гамәлгә ашыра.

3.29. Социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган һәм эш эзләүдә кыенлыклар кичергән гражданнарга, шул исәптән инвалидларга, сәламәтлекләре мөмкинлекләре чикләнгән гражданнарга эшкә урнашуга, шулай ук хәрби хезмәткә чакырылу яки аны алыштыра торган альтернатив граждан хезмәтенә җибәрелү белән бәйле хезмәт шартнамәләре туктатылган, хезмәттән азат ителгәннән соң өч ай эчендә элеккеге эш бирүчесенә мөрәҗәгать иткән гражданнарны, аларның һөнәри квалификациясе нигезендә эшкә алуга ярдәм итә.

3.30. Беренче тапкыр хезмәт базарына чыккан яшьләргә беренче эш урынын бирү һәм аларның иялләштерү буенча чаралар эшләү һәм тормышка ашыруны күздә тота.

3.31. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган гражданнарны эшкә урнаштыру, шулай ук гражданнарның әлеге категорияләре өчен эш урыннары резервлау буенча чаралар күрә.

3.32. Чит ил хезмәткәрләренең игълан ителгән һөнәри-квалификация таләпләренә туры килүгә аттестация узуларын, кирәк булган очракта – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 24 март, б-576 нчы боерыгы нигезендә 2023–2029 елларга Татарстан Республикасы икътисадының өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган, ихтыяҗ булган һөнәрләр һәм белгечләр исемлегенә кертелгән белгечлекләр (һөнәрләр) буенча чит ил хезмәткәрләренең квалификациясен арттыруны, укыту-өйрәтүне һәм (яки) яңа һөнәргә өйрәтүне тәэмин итә.

3.33. Һөнәри белем бирү оешмаларын һәм (яки) югары һөнәри белем бирү мәгариф оешмаларын тәмамлап чыгучыларны эшкә урнаштырганда остазлар сыйфатында югары квалификацияле эшчеләр һәм белгечләр җәлеп итә.

3.34. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны эшләүдә һәм тормышка ашыруда булышлык күрсәтә.

3.35. Алдан билгеле булган вакытлыча (тугыз айга кадәр) җитештерү яки күрсәтелә торган хезмәтләр күләме киңәю белән бәйле эшләр башкару өчен хезмәткәрләр (персонал) хезмәтен бирү турында хосусый агентлыгы белән кабул итүче якның уртача исемлектәге хезмәткәрләре санының 10 процентыннан артып киткән санда килешү төзү турында карар кабул ителгән очракта беренчел һөнәр берлеге оешмасының сайлаулы органының фикерен сорый.

Хөкүмәт:

3.36. Эш белән тәэмин итүнең һәм дәүләт хезмәте белән тәэмин итүнең актив формаларының өстенлеген саклап, хезмәт базарын модернизацияләүне тәэмин итә.

3.37. Эш белән тәэмин итү дәүләт сәясәтенең нәтиҗәлелеген, халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләренең сыйфатын һәм һәркем алырлык булуын арттыру буенча чаралар күрә.

3.38. Татарстан Республикасы икътисадында ихтыяҗ булган һөнәрләр буенча кадрлар әзерләү һәм башка һөнәргә өйрәтү буенча дәүләт программаларын эшләүне һәм тормышка ашыруны, һөнәри стандартлар системасын һәм һөнәри квалификацияләр сертификациясен гамәлгә кертү процессларын норматив тәэмин итү ягыннан, һөнәри квалификацияләрне үстерүнең төбәк системасын формалаштыруны хәл итә.

3.39. Уңайлы инвестицион климат булдыру буенча сәясәтне тормышка ашыра һәм Татарстан Республикасына инвестицияләр җәлеп итү буенча чараларны гамәлгә ашыра, Татарстан Республикасы икътисадының өстенлекле тармакларында инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда ярдәм итә, эш урыннарын булдыру һәм яңарту максатыннан чыгып кече эшмәкәрлекне үстерүгә булыша.

3.40. Үз компетенциясе чикләрендә чит илләрнең эшче көчләрен җәлеп итү һәм куллануны тәртипкә салу чараларын тормышка ашыра.

3.41. Хезмәт базарында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләренең һәм мәгариф оешмаларының берлектә эшләве нигезендә эшче көчләргә ихтыяҗ һәм тәкъдимне тиешле балансۀка китерү буенча чаралар күрә.

3.42. Инвалидларны эш белән тәэмин итү дәрәҗәсен һәм Россия Федерациясендә ратификацияләнгән «Инвалидлар хокуклары турында» БМО конвенциясе (Генераль Ассамблеяның 2006 елның 13 декабрендәге 61/106 резолюция) нормаларын тормышка ашыру максатында инвалидларны эш белән тәэмин итүдә эш бирүчеләрнең икътисадый кызыксынуын арттыру буенча чаралар күрә.

3.43. Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү чараларын тормышка ашыра, шул исәптән гражданнарның аерым категорияләрен эшкә урнаштыру өлешендә.

3.44. Рәсми булмаган эш белән тәэмин ителешне киметү чараларын эшли.

3.45. Татарстан Республикасының хезмәт базарында катлаулы хәл урнашкан муниципаль берәмлекләрендә хезмәткәрләрне эштән чыгаруның тискәре социаль нәтиҗәләрен йомшартуга юнәлтелгән чаралар күрә, хезмәткәрләрне эштән чыгарганда яңа эш урыннарын булдыруда катнаша.

3.46. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 ел, 29 июль, 1398-б номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләр) исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы моношәһәрләренең социаль-икътисадый хәлен яхшыртуга йөз тоткан чараларны гамәлгә ашыра.

4. Хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау, экологик иминлек

Имин хезмәт, җитештерүдә җәрәхәтләнү-имгәнү очракларын һәм һөнәри авыруларны киметү, хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәткәрләрнең хокукларын санга сукмау очракларын киметү, җитештерүдә җәрәхәтләнү-имгәнү, һөнәри авыруларны кисәтү чараларының нәтиҗәлелеген арттыру өчен шартлар тудыру максатыннан чыгып,

Яклар:

4.1. Оешмаларда Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Хезмәтне саклау белән идарә итү системасы турындагы үрнәк нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның

29 октябрендәге 776н номерлы боерыгы белән расланган Хезмәтне саклау белән идарә итү системасы турындагы үрнәк нигезләмәне (алга таба – Хезмәтне саклау белән идарә итү системасы турындагы үрнәк нигезләмә) исәпкә алып, хезмәтне саклауны идарә итү системаларын гамәлгә кертүне тәкъдим итә.

4.2. «2014–2025 елларга Татарстан Республикасында яшәүчеләрне эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» дәүләт программасының «2014–2025 елларга Татарстан Республикасында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту» ярдәмче программасын тормышка ашыру чараларын күрә.

4.3. Эш урыннарында хезмәтне саклау торышын һәм хезмәт шартларын яхшыртуга, җитештерүдә үлем-китем белән тәмамланган, авыр нәтиҗәләргә китергән бәхетсезлек очраклары санын һәм төркемләп бәхетсезлек очракларына юлыгучылар санын киметүгә ирешә.

4.4. Эш урыннарында хезмәт авырлыгын киметүгә һәм зарарлы факторларның хезмәткәрләренә йогынтысын киметүгә юнәлдерелгән техник чаралар комплексын эшләүне тәэмин итә.

4.5. Җитәкчеләргә, белгечләргә, профсоюз хезмәткәрләренә һәм профсоюз активына хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча белем бирү формаларын, ысулларын һәм аларның белемнәрен тикшерү формаларын, ысулларын камилләштерү буенча чаралар күрә.

4.6. Республика предприятиеләре һәм оешмаларының хезмәтне саклау белән идарә итү системаларының нульле травматизм концепциясе принципларын кертүгә һәм нәтиҗәле эшләвенә ярдәм итә.

4.7. Гамәлдәге закон нигезендә иминиятләштерү принципларында һәм коллектив килешүле җайга салу шартларында хезмәткәрнең сәламәтлегенә, хезмәт урынында имгәнү яки һөнәри авыру алу сәбәпле китерелгән зыянны үз вакытында каплауга ярдәм итә.

4.8. Хезмәтне саклау буенча дәүләт идарәсе системасын камилләштерә, хезмәтне, сәламәтлекне саклауда дәүләт, ведомство һәм һөнәр берлекләре контроле ролен күтәрүне тәэмин итә.

4.9. «Җитештерүдән бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү турында» 1998 елның 24 июлендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру чаралары, шул исәптән хроник йогышлы булмаган авыруларны һәм алар таралу куркынычы факторларын иртә ачыклау, җитештерүдә җәрәхәтләнү-имгәнү һәм һөнәри авыру алу очракларын киметү буенча кисәтү чараларын финанслауга акча куллану ягыннан, эш бирүчеләрнең эшчәнлеген активлаштыруга юнәлдерелгән чаралар күрә. Финанс мөмкинлеге булганда скрининг программаларын эшли һәм тормышка ашыра.

4.10. Җитештерү тирәлегенең торышы, эш урыннарында куркынычлар һәм һөнәри куркынычлар, шулай ук әйләнә-тирә табигать мохитенең торышы турында хезмәткәрләрнең хәбәрдарлык дәрәҗәсен күтәрү чараларын гамәлгә ашыралар.

4.11. Үз вәкилләренең Татарстан Республикасы муниципаль районнар һәм шәһәр округларында хезмәтне саклау буенча координация советлары эшендә катнашуын тәэмин итә.

Һөнәр берлекләре:

4.12. Хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәткәрләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүгә җәмәгать контроле нәтиҗәсен көчәйтә. Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясенең Техник хезмәт инспекциясе эшчәнлегенең нәтиҗәсен арттыру һәм оешмаларда хезмәтне саклау буенча профсоюзларның сайланган вәкаләтле затлары (ышанычлылар) санын арттыру чаралары күрә. Коллектив килешүләргә хезмәтне саклау буенча профсоюзларның вәкаләтле затларының (ышанычлылар) эшчәнлегенә гарантияләр, үзләренең производство участогында (структур бүлекчәдә) җәрәхәтләнү-имгәнүләрсез, аварияләрсез эшләүне тәэмин иткән өчен мораль һәм матди кызыксындыру турында бүлекләр кертүгә ирешә.

4.13. Паритетлы башлангычларда оешмаларда хезмәтне саклау буенча комитетлар (комиссияләр) оештыру мәсьәләсен күтәрә һәм хезмәтне саклауны идарә итү системасында аларның ролен көчәйтә.

4.14. Хезмәтне саклау буенча вәкаләтле (ышанычлы) затларны һәм комитетлар (комиссияләр) әгъзаларын укыту-өйрәтүне оештыруда катнаша.

4.15. Коллектив килешүләргә һәм шартнамәләргә производстволарның техник һәм экологик иминлеге дәрәҗәсен арттыруга, хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүгә, зарарлы һәм (яки) хәтәр хезмәт шартлары белән бәйле эш урыннарын киметүгә һәм хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча башка чаралар үткәрүгә юнәлдерелгән йөкләмәләр кертүгә ирешә.

4.16. Хезмәт шартлары торышын һәм хезмәтне саклауны, эш бирүчеләр тарафыннан кумәк килешүләрдә һәм шартнамәләрдә күздә тотылган йөкләмәләрнең үтәлүен тикшерә.

4.17. Җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән яки һөнәри авыру алган хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен (шул исәптән суд органнарында) яклый, аларны тикшерүдә катнаша.

4.18. Хезмәт коллективларында хезмәтне саклау турында гамәлдәге законнар буенча мәгълүмати-аңлату һәм консультация эше алып бара һәм массакүләм мәгълүмат чараларында хезмәтне саклау мәсьәләләрен пропагандалый (шул исәптән чит илләр тәҗрибәсен).

4.19. Хезмәт шартларын махсус бәяләү, һөнәри хәвеф-хәтәрләрне бәяләү буенча комиссияләрдә катнаша һәм аларга тиешле гарантияләр һәм компенсацияләр бирүдә хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый.

4.20. «Эш урынында ирекле һәм конфиденциаль тест» кампаниясе кысаларында хезмәт коллективларында ВИЧ-инфекцияне (СПИД) профилактикалау буенча мәгълүмати-аңлату эшен үткәрүне башлап җибәрә.

4.21. ВИЧ-инфекцияле хезмәткәрләргә карата стигма һәм дискриминациягә юл куймау турында аңлату эшләре алып баруда катнаша.

Эш бирүчеләр:

4.22. Хезмәт куркынычсызлыгы өлкәсендә хезмәткәрләрнең хокукларын үтәү, җитештерүдә җәрәхәтләнү-имгәнү очракларын киметү, зарарлы һәм хәтәр хезмәт шартлары белән бәйле булган эш урыннарын киметү буенча чараларны тормышка ашыруны тәэмин итә.

4.23. Хезмәтне саклау буенча дәүләт норматив таләпләрен үтәүне тәэмин итә; хезмәтне саклау хезмәтләренең эшен оештыра; оешмаларда, Хезмәтне саклау белән идарә итү системасы турындагы үрнәк нигезләмә таләпләрен исәпкә алып, хезмәтне саклау белән идарә итү системасын гамәлгә кертә һәм камилләштерә.

4.24. Коллектив килешүләрдә һәм шартнамәләрдә түбәндәгеләр карала:

хезмәткәрләрнең хезмәт шартларын һәм хезмәтен саклауны яхшырту, санитария-гигиена нормативларына һәм куркынычсызлык таләпләренә туры килми торган эш урыннары санын кыскарту буенча чаралар үткәрү һәм аларны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән срокларда акча бүлеп бирү;

зарарлы һәм (яки) хәтәр хезмәт шартлары белән бәйле булган эшләргә җәлеп ителгән хезмәткәрләргә хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү һәм гарантияләр һәм компенсацияләр бирү, тулы күләмдә;

оешманың барлык хезмәткәрләрен җитештерүдә җәрәхәтләнүне профилактикалауга җәлеп итеп, хезмәтне саклау белән идарә итү системасын эшләү һәм гамәлгә кертү;

законнарда каралган очракларда җирле үзидарә органнарына килеп чыккан аварияләр һәм җәрәхәтләнү-имгәнү очраклары турында оператив төстә мәгълүмат җиткерүне тәэмин итү, сәбәпләрен, производствоның янгынга каршы тотрыклылыгы һәм производство куркынычсызлыгы дәрәҗәсен арттыру буенча күрелгән чараларны бәян итеп;

хезмәткәрләрне җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерүне тәэмин итү;

эшкә кергәндә, үз акчалары хисабына, хезмәткәрләргә башлангыч һәм билгеле бер вакыт аралыкларыннан соң медицина тикшерүләре уздыру, шул исәптән техноген хәтәр куркынычлы производстволарда һәм транспорт оешмаларында эшләүчеләргә наркотик матдәләрне һәм психотроп матдәләрне медицинадан тыш максатта куллануны кисәтү тикшерүләре үткәрү;

наркотик матдәләрне һәм психотроп матдәләрне медицинадан тыш максатта куллануны кисәтү, алкогольле һәм спиртлы продукция, тәмәке белән артык мавыгуны кисәтү, сәламәт тормыш рәвеше алып баруга шартлар һәм кызыксыну тудыру чаралары үткәрү.

4.25. Хезмәтне саклау буенча вәкаләтле (ышанычлы) затларга, шулай ук комитетлар (комиссияләр) әгъзаларына үзләренең эшчәнлеген эш вакытыннан азат итү өчен шартлар тудыра, аларны өйрәтүне оештыра.

4.26. Эш урыннарында хезмәт шартлары торышына һәм хезмәтне саклауга административ-җәмәгать контроле, хезмәтне саклау буенча комитетлар (комиссияләр) катнашында Хезмәтне саклау көннәре үткәрә.

4.27. Матди һәм мораль кызыксындыру чараларын, шулай ук предприятие хезмәткәрләренең дисциплинар йогынты чараларын карганда, сәнәгать иминлеген, энергетика җайланмалары һәм челтәрләре иминлеген тәэмин итү, авария һәм җәрәхәтләнү-имгәнү очракларын кисәтү буенча эш нәтиҗәләрен исәпкә ала.

4.28. Җитәкче хезмәткәрләрне һәм белгечләрне, эшче кадрларны аттестацияләгәндә, хәтәр эш төрләрен оештыру һәм үткәрүнең торышы, авария хәлләре булу һәм кисәтүнең торышы, хезмәтне саклау мәсьәләләре, алар тарафыннан хезмәт куркынычсызлыгы таләпләрен, производство дисциплинасын үтәү торышы исәпкә алына.

4.29. Эш урыннарында ВИЧ-инфекциясе (СПИД) профилактикалау буенча мәгълүмати-аңлату чаралары үткәрү буенча кумәк шартнамәләргә һәм килешүләргә кертүгә комачауламыйлар, шулай ук «Эш урынында ирекле һәм конфиденциаль тестлау» кампаниясен үткәрүдә ярдәм итәләр.

Хөкүмәт:

4.30. Хезмәтне саклауда дәүләт идарәсе системасын камилләштерә.

4.31. «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» дәүләт программасының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту» ярдәмче программасын тормышка ашыруны һәм аны тиешле чорга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауны тәэмин итә.

4.32. Хезмәтне саклау буенча билгеләнгән тәртиптә хезмәткәрләрне, шул исәптән эш бирүчеләрне укытуны, аларның хезмәтне саклау таләпләрен белүен тикшерүне, шулай ук җитештерүдә имгәнүләрне беренче ярдәм күрсәтергә өйрәтү үткәрүне координацияли.

4.33. Хезмәт шартларын бәяләү максатында дәүләт экспертизасын үткәрүне тәэмин итә:

хезмәт шартларын махсус бәяләү үткәрү сыйфатын;

зарарлы һәм (яки) хәтәр эш шартлары белән бәйле эшчәнлек өчен хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүнең дөреслеген;

фактгагы хезмәт шартларын.

4.34. Законнарда билгеләнгән тәртиптә халыкның санитар-эпидемиологик һәм экологик иминлеге куркынычсызлыгы тудыра торган оешмалар эшчәнлеген контрольдә тоту эшен оештыра.

4.35. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, һөнәр берлекләре оешмалары, республика территориясендә урнашкан оешмалары җәлеп итеп, хезмәтне саклау буенча максатчан киңәшмәләр, семинарлар, күргәзмәләр, смотр-конкурслар һәм башка оештыру-агарту чаралары үткәрүне оештыра.

4.36. ВИЧ-инфекцияле хезмәткәрләргә карата стигматизацияне һәм дискриминацияне булдырмауны исәпкә алып, ВИЧ-инфекциянең таралуына каршы тору механизмнарын эшли.

5. Хезмәткәрләрне һәм халыкны социаль яклау, социаль иминиятләү

Яклар гражданнарның социаль яклауга хокукларын саклауны тәэмин итү зарури дип саный һәм түбәндәге бурычларны өстенлекле дип саный:

мәҗбүри социаль иминиятләштерүнең нәтиҗәле һәм тотрыклы системасын үстерү, эшләүче гражданнарны социаль яклау дәрәҗәсен көчәйтү, шул исәптән хезмәткәрләрне иминиятләштерү принципларын нигезендә социаль куркынычлардан саклауның тулы күләмендә системасын формалаштыру һәм мәҗбүри социаль иминиятләштерүнең бөтен системасының финанс тотрыклылыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар тормышка ашыру.

торак төзелешен тотрыклы финанслауны тәэмин итү, торак программалары, шул исәптән социаль ипотека кысаларында керемнәре төрле дәрәҗәдә булган гражданнарны бәясе кесәгә алырга мөмкин булган торак белән тәэмин итү нәтиҗәле системасын булдыру, законнар нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булган гражданнарга торак бирү;

хезмәткәрләрне һәм аларның гаилә әгъзаларын һәркем файдалана алырлык имин шифаханә-курорт дәвалавы белән, балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен тәэмин итү.

Хезмәткәрләрне һәм халыкны социаль яклауны тәэмин итү максатларында Яклар түбәндәгеләргә бурычлы:

5.1. Түбәндәгеләрне күздә тоткан законнар яки башка норматив хокукый актлар эшләү буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм аларны эшләүдә (аларга экспертиза үткәрү) булышлык күрсәтү:

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү системасын камилләштерү (реформалаштыру) һәм имин хезмәт шартларын булдыруда эш бирүчеләрнең икътисадый кызыксынуының нәтиҗәле механизмнарын тормышка ашыру;

хезмәт шартларын махсус бәяләүне оештыру процедурасында һәм барлык этапларда аны үткәрүгә контрольдә социаль партнерларның катнашуын.

5.2. Түбәндәге мәсьәләләр буенча консультацияләр үткәрә һәм тәкъдимнәр кертә:

түләүсез медицина ярдәменә һәм халыкны диспансеризацияләү буенча чараларга дәүләт гарантияләрен саклау максатында, хосусый сәламәтлек саклау секторын үстерүгә системалы контрольне исәпкә алып, тулаем сәламәтлек саклау системасын, шулай ук мәҗбүри медицина иминиятләштерүе системасын үстерү һәм камилләштерү;

социаль иминиятләштерүне һәм эшкә вакытлыча яраксыз булу сәбәпле пособиеләр исәпләүне камилләштерү;

пенсия иминиятләштерүен реформалаштыру нигезендә пенсионерларның тормыш сыйфатын яхшырту;

корпоратив пенсия системаларын формалаштыру;

дәүләткә карамаган ирекле пенсия иминиятләштерүе өлкәсендә җыелган пенсияләр булдыруда хезмәткәрләрнең һәм эш бирүчеләрнең катнашуын стимуллаштыру.

5.3. Өлкән яшьтәге халыкның билгеле төркемнәренә (21 яшьтән башлап 39 яшькә кадәр – өч елга бер тапкыр, 40 һәм аннан өлкәнрәк яшьтән – ел саен) диспансеризация үткәрүдә, хезмәткәрнең яшәү (беркетелгән) урыны буенча медицина оешмаларында хезмәткәрләргә тикшерену (консультация) үтү өчен мөмкинлек бирү өлешендә медицина оешмаларына булышлык күрсәтү.

5.4. Торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтүгә тарифларның инфляция дәрәҗәсеннән тизрәк үсүен чикләү буенча килештерелгән чаралар күрү.

5.5. Мәдәният, спорт, туризмны, хезмәткәрләрнең һәм аларның гаиләләре әгъзаларының сәламәтлеген шифаханә-курорт дәвалавын үстерү, спорт, социаль-мәдәни, шифаханә объектлары челтәрен саклау һәм ныгыту өлкәсендә килештерелгән сәясәт алып бару.

5.6. Балаларның һәм яшьләрнең ялына, аларны савыктыруга, эшләүче гражданнарны савыктыруга, шифаханә-профилакторийлар, шифаханә-курорт учреждениеләре челтәреннән файдалануга, шул исәптән дәвалап бетерү (тернәкләндерү) кысаларында, кагылышлы норматив-хокукый актлар проектларын эшләүдә һәм (яки) алар буенча фикер алышуда бергәләп катнашу, әлеге актларны Якларның фикерен исәпкә алып кабул итү.

5.7. Ел саен балаларны сәламәтләндерү кампанияләренә йомгаклар ясау һәм аларны Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе утырышында карап тикшерү.

5.8. Оешмалар балансындагы балалар савыктыру лагерьларының, мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының, мәдәният һәм спорт объектларының, торак фондының сакланылышын, коммуналь хезмәтләр күрсәтүне һәм билгеләнеше буенча файдалануны тәэмин итү.

5.9. Инвалидлар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән гражданнарның, индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, һөнәри белем бирү һәм өстәмә белем бирүдән файдалана алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру.

5.10. Мәҗбүри пенсия, медицина иминиятләштерүе һәм социаль иминиятләштерүгә иминият кертемнәре буенча бурычларны бетерү чараларын тормышка ашыру.

Һөнәр берлекләре:

5.11. Шартнамәләргә һәм коллектив килешүләргә сәламәт яшәү рәвешен алып баручы затларны, начар гадәтләргә ия булмаган хезмәткәрләрне, шул исәптән тәмәке тартудан баш тарткан хезмәткәрләрне, оешмаларда физик культура эшен үткәрү өчен җаваплы затларны бүләкләү, шулай ук физик культура белән шөгыльләнү өчен бүлмәләр бирү буенча йөкләмәләр кертүне күздә тота.

5.12. Оешмалар тарафыннан эшләүчеләргә, күпбалалы һәм тулы булмаган гаиләләргә, инвалидларга, пенсионерлар арасыннан элеккеге хезмәткәрләргә ярдәм күрсәтүгә, физик культура һәм спортны үстерүгә, хезмәткәрләрне һәм аларның балаларын савыктыруга кирәкле акча бүлеп бирүенә ирешә.

5.13. Эш бирүчеләр тарафыннан җитештерүдә бәхетсезлек очракларын һәм социаль иминият чаралары хисабына финанслана торган һөнәри авыруларны кисәтү буенча превентив чараларны, шулай ук наркотик һәм психотроп матдәләрне, алкоголь һәм спиртлы продукцияне чамадан тыш куллануны, тәмәке куллануны профилактикалау, сәламәт яшәү рәвешен алып бару өчен шартлар тудыру һәм мотивация формалаштыру буенча чараларны тормышка ашыруга булышлык итә.

5.14. Хезмәткәрләрне савыктыруга, хезмәт коллективларында физик культура һәм спортны үстерүгә, шул исәптән физкультура һәм спорт чараларын уздыруга, шулай ук «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексын гамәлгә кертү чараларын гамәлгә ашыруда катнаша.

5.15. Коллектив килешүләрдә хезмәткәрләрнең торак шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән эш бирүчеләр йөкләмәләрен билгеләүгә ирешә.

5.16. Республика, тармак, муниципаль һәм локаль дәрәҗәләрдә социаль юнәлештәге законнар, башка норматив хокукый актлар, программалар һ.б. эшләүдә, аларны килештерү һәм тормышка ашыруда катнаша.

5.17. Эш бирүчеләрнең бюджеттан тыш фондларга иминият кертемнәрен үз вакытында һәм тулы күләмендә бирүенә законнар нигезендә һөнәр берлекләре контролен тәэмин итә.

5.18. Хезмәт коллективларында пенсия законнары реформасының төп нигезләрен аңлату буенча мәгълүмати эш алып бара.

5.19. Халыкны, шул исәптән бюджет оешмалары хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итүне үстерүгә булышлык күрсәтә.

5.20. Пенсионерларны, инвалидларны, хатын-кызларны һәм балаларны социаль яклау мәсьәләләре буенча консультация ярдәме һәм хокукый ярдәм күрсәтә.

Һөнәр берлекләре, Эш бирүчеләр:

5.21. Шартнамәләрдә һәм коллектив килешүләрдә билгеләнгән шартларда, түбәндәгеләрне күздә тота:

хезмәткәрләрне өстәмә пенсия белән тәэмин итүне һәм ирекле медицина иминиятләштерүне үстерүне;

хезмәткәрләргә һәм аларның гаиләләре әгъзаларына шифаханә-курортта дәвалануга һәм савыктыруга юлламалар сатып алу өчен акча бүлеп бирүне, савыктыру, мәдәни-массакүләм һәм физкультура эшен алып баруны;

медицина хезмәте күрсәтүне, оешмаларның пенсиягә чыккан ветераннарына бәясен компенсацияләп, шифаханә-курортта дәвалануны;

адреслы матди ярдәм күрсәтүне:

хезмәт стажы 10 ел һәм аннан күбрәк булган хезмәткәрләргә юбилей даталары җиткәндә;

хезмәткәрләргә (пенсиягә чыгуга бәйле эштән киткән, оешмадагы эш стажы 10 ел һәм аннан күбрәк затларга) күмүләр оештырганда (шул исәптән транспорт белән тәэмин итү);

хезмәткәрләрнең сәламәтлеген саклау буенча чаралар эшләү һәм тормышка ашыру.

5.22. Шартнамәләргә һәм кумәк килешүләргә хезмәткәрләрне медицина каравын, сәламәтләндерү дәвалавын һәм туклануын оештыру буенча чаралар кертү мөмкинлеген карап тикшерә.

Эш бирүчеләр:

5.23. Социаль планнар һәм программалар эшли һәм тормышка ашыра, шул исәптән финанс мөмкинлеге булганда дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү, ирекле медицина иминиятләштерүе өлешендә.

5.24. Оешма балансында булган социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларны максималь дәрәҗәдә саклау һәм алардан файдалану буенча чаралар күрә.

5.25. Социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларны бер карамактан икенчесенә күчерү, арендага тапшыру, бюджет учреждениеләренең төрен үзгәртү турында карарлар кабул иткәндә сайланган һөнәр берлеге органы фикерен исәпкә ала.

5.26. Оешмаларның хезмәткәрләренә торак шартларын яхшыртуда булышлык күрсәтә. Мөмкинлек булганда, коллектив килешүдә билгеләнгән шартларда сатып алына торган торак урынга беренче кертемне түләү яки торак бәясенең бер өлешен түләүгә ташламалы заемнар бирә.

5.27. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Өлкән яшьтәге халыкның билгеле төркемнәренә профилактик медицина күзәтүе һәм диспансеризация үткәрү тәртибен раслау турында» 2021 елның 27 апрелендәге 404н номерлы боерыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 август, 1520-б номерлы боерыгы нигезендә хезмәткәрләргә диспансеризация үтү мөмкинлеген бирүне тәэмин итү буенча чаралар күрә.

5.28. Физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүне дә кертеп, сәламәт яшәү рәвешен алып бару өчен шартлар тудыру һәм мотивацияләр булдыру, шул исәптән «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексы таләпләрен әзерләү һәм үтәү буенча, эшчеләрнең акыллы һәм физик эшкә сәләтлелеген саклау өчен, эш вакыты режимына кертү буенча чаралар үткәрә.

Хөкүмәт:

5.29. Халыкның аз керемле категорияләренә социаль ярдәм чараларының адреслылыгын көчәйтә.

5.30. Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең һәм пенсионерларның шифаханә-курортта дәвалануын финанслауны һәм оештыруны тәэмин итә:

2023 елда – 170,8 млн сум;

2024 елда – 177,6 млн сум.

5.31. Татарстан Республикасы халкы өчен торак сатып алу мөмкинлеген һәм торак төзелеше күләмен арттыру максатында, социаль ипотека кредиты системасын үстерүгә ярдәм итә.

5.32. Халыкка, шул исәптән инвалидларга һәм гражданнарның башка категорияләренә законнар нигезендә медицина һәм дарулар белән ярдәм итүнең гарантияләнгән күләмен тәэмин итә.

5.33. Законнар нигезендә ВИЧ-инфекциясе һәм бөтен халыкның яки аның бер өлешенең тормыш-көнкүрешен куркыныч астына куя торган башка авырулар таралышына каршы тору чараларын финанслауны тәэмин итә.

5.34. Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга законнар нигезендә дәүләт тарафыннан гарантияләнгән социаль хезмәтләр күрсәтү чараларын тормышка ашыра.

5.35. Законнар нигезендә яшәү өчен иң кирәкле һәм иң мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дарулар бәяләрен, шулай ук гомуми файдаланудагы шәһәр пассажир транспорты һәм шәһәр яны тимер юл транспорты, коммуналь хезмәтләр күрсәтү тарифларын, реаль керемнәр һәм хезмәт хакы артуын исәпкә алып, дәүләт җайга салуында катнаша.

5.36. Халыкны, шул исәптән бюджет өлкәсе хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү системасын үстерүгә ярдәм итә.

5.37. Дәүләт ярдәме, шул исәптән балаларның сәламәтләндерү ялын оештыручы эш бирүчеләрне икътисадый стимуллаштыру чараларын камилләштерә, стационар балаларны сәламәтләндерү учреждениеләре эшчәнлегенә булышлык күрсәтү, җирдән файдалану һәм салым салу мәсьәләләрен хәл итүне дә кертеп.

5.38. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт учреждениесе (дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыру турында» 2011 ел, 28 март, 233 нче карары белән расланган авырулар исемлеге буенча стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт учреждениеләре һәм дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләре шартларында дәвалап бетерүгә (тернәкләндерүгә) җибәрелә торган эшләүче гражданнарны финанслауны һәм аларның санын арттыру буенча чаралар күрә.

6. Яшьләрне социаль һәм хокукый яклау, гаиләне ныгыту, аналар һәм балалар турында кайгырту

Яклар:

6.1. Яшь гражданнарга, хатын-кызларга, балаларга дәүләт һәм иҗтимагый ярдәм, хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау чаралары системасын эшли һәм тормышка ашыра. Яшьләрнең, аналар һәм балаларның проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән программаларны тормышка ашыруда катнаша.

6.2. Яшьләр, хатын-кызлар, гаилә һәм балалар проблемалары буенча иҗтимагый, яшьләр, хатын-кызлар оешмалары һәм берләшмәләре белән берлектә эшли.

6.3. Татарстан Республикасы хезмәт базарында хатын-кызларның һәм яшьләрнең хәлен яхшыртуга ярдәм итә. Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга һөнәри юнәлеш системасын камилләштерүгә булышлык күрсәтә. Яшьләрне социаль-хезмәткә җайлаштыру мәсьәләсе буенча килешенгән сәясәт алып бара.

6.4. Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм социаль-мәдәни, спорт-сәламәтләндерү һәм патриотизм чараларын (олимпиадалар, фестивальләр, смотр-конкурслар, конференцияләр, акцияләр һ. б.), яшьләр туризмын оештыру, шул исәптән хәрби-тарихи, экологик, гаилә юнәлешендәге чаралар үткәрү эшен башкара.

6.5. Яшьләрне бөтенроссия, төбәкара спорт ярышларында катнашуга җәлеп итүгә, шулай ук спортның массакүләм төрләре буенча яшьләр арасында төбәк спорт чараларын үткәрүгә ярдәм итә.

6.6. Яшь гаиләләргә социаль-икътисадый ярдәм күрсәтүне тормышка ашыра. Законнар һәм коллектив-килешүле җайга салу нигезендә яшьләрнең торак проблемаларын хәл итәргә булыша.

6.7. Барлык төр милек формасындагы оешмаларда остазлык институты формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтә.

6.8. Кече яшьтәге балаларны карауга бәйле хезмәт эшчәнлеген озак вакытка туктатып торганнан соң дәвам иттерергә омтылган хатын-кызларга хезмәт базарында социаль җайлашу өчен шартлар тудыра, аларның квалификациясен күтәрүне, хезмәт базарында ихтыяҗ булган һөнәрләр һәм белгечлекләр буенча белем бирү һәм яңадан укытуны тәэмин итә.

6.9. Хатын-кызлар эшне (укуны) һәм балалар тәрбияләүне бергә алып бара алсыннар өчен шартлар тудыруга йөз тоткан чаралар күрүгә булыша.

6.10. Социаль-хезмәт өлкәсендә гендерлык тигезлеге мәсьәләләре буенча иҗтимагый, хатын-кызлар, яшьләр оешмалары (комитетлар, советлар), аналар һәм балаларны яклау комиссияләрен оештыруга һәм аларның эшчәнлегенә ярдәм итә.

6.11. Гаилә һәм балалар ялы учреждениеләре инфраструктурасына ярдәм итүгә һәм аларны үстерүгә, шулай ук өстәмә белем алу мөмкинлеген арттыруга һәм аның сыйфатын яхшыртуга, балалар һәм яшьләр талантларына ярдәм итүнең һәм аларны үстерүнең нәтиҗәле системасын формалаштыруга булышлык күрсәтә.

6.12. Савыктыру оешмаларында балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыруны билгеләнгән тәртиптә контрольдә тотуны гамәлгә ашыра.

6.13. Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе утырышларында яшьләр белән эшләүгә һәм яшьләрне, хатын-кызларны хокукый һәм социаль яклау чараларына кагылышлы мәсьәләләрне карап тикшерә.

6.14. Кумәк килешүләрдә 16 яшькә кадәрге балалары булган хатын-кызларга тариф ставкасының (оклад) кимендә 50 проценты күләмендә түләү белән атна саен кимендә 2 сәгать буш вакыт яки айга бер буш көн бирү турында шартлар билгеләүгә ярдәм итә.

6.15. Яшьләрне, балигъ булмаган балалары булган хатын-кызларны эш белән тәэмин итү буенча иң яхшы практикалар таралуга ярдәм күрсәтә, шулай ук яшьләрне, балигъ булмаган балалары булган хатын-кызларны эш белән тәэмин итү өлкәсендә сәясәтне камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшли.

6.16. Түләүле иҗтимагый эшләр үткәрүне, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемле яки югары белемле һәм аларга белем алу турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан бер ел эчендә эш эзләүче 18 яшьтән 25 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны, 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны, матди ярдәм күрсәтеп, вакытлыча эшкә урнаштыруны тәэмин итә.

Һөнәр берлекләре:

6.17. Яшьләрнең, хатын-кызларның хезмәткә хокукларын һәм социаль-икътисадый мәнфәгатьләрен яклау буенча чаралар күрә.

6.18. Яшьләрне һөнәр берлекләре әгъзалары сафларына җәлеп итә, яшьләрнең һөнәри ихтыяҗларын тормышка ашыру өчен шартлар тудыруга ярдәм итә. Һөнәр берлеге әгъзалыгына карата кызыксындыру тудыру өчен агитбригадалар конкурслары үткәрә.

6.19. Һөнәр берлекләренең уку-укыту-тикшеренү үзәгендә һәм Яшь һөнәр берлеге лидеры мәктәбендә айлык семинарларда яшьләр һөнәр берлеге хәрәкәте лидерларын, яшь хезмәткәрләрне һәм студентларны хезмәт законнары, социаль партнерлык нигезләренә һәм башка социаль-икътисадый мәсьәләләр буенча укыту-өйрәтү үткәрә.

6.20. Барлык дәрәҗәләрдәге шартнамәләрне һәм коллектив килешүләрне төзү буенча сөйләшүләр алып барганда комиссияләрдә яшьләр вәкилләренең катнашуын тәэмин итә.

6.21. Шартнамәләр һәм коллектив килешүләр аша яшьләрнең һәм хатын-кызларның укуга, эш белән тәэмин ителүгә, лаеклы хезмәт хакына, производство белән идарә итүдә катнашуына хокукларын киңәйтүне һәм гарантияләрне тәэмин итү тәэмин итүгә булыша.

6.22. Яшьләр арасында хезмәт көндәшлеген оештыруга ярдәм итә. «Иң яхшы яшьләр һөнәр берлеге лидеры», «Иң яхшы агитбригада», «Балалар рәсеме һәм плакаты» конкурсларын, һөнәри осталык конкурслары һ.б үткәрә.

6.23. Оешмаларда яшьләр белән эшләү буенча советлар (комиссияләр, комитетлар) оештыра.

6.24. Яшьләр өчен массакүләм хезмәт, мәдәни, спорт чаралары оештыруга ярдәм итә.

6.25. Хезмәттә һәм укуда югары күрсәткечләргә ирешкән һөнәр берлекләре әгъзалары арасыннан яшьләрне кызыксындыру чараларын эшли һәм тормышка ашыра, һөнәри белем бирү оешмаларының һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларының иң яхшы студентларына стипендияләрне гамәлгә куя.

6.26. Россия Бәйсез Һөнәр берлекләре Федерациясенең Гендерлык сәясәте концепциясен тормышка ашыруда катнаша. Һөнәр берлеге кадрларын социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрендә гендерлык якын килү нигезләренә өйрәтә.

6.27. Хезмәткә түләү, эшкә алу, җитәкче вазыйфаларга билгеләү өлкәсендә гендерлык тигезлеген тормышка ашыруга ярдәм итә.

6.28. Һөнәр берлекләре шифаханәләре һәм савыктыру лагерьлары базасында балалар һәм яшьләрнең, шул исәптән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, опекуннар һәм бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларның ялын һәм сәламәтлеген ныгытуны, шулай ук кайбер авырулар буенча стационар шартларда дәваланганнан соң һәм операция ясатканнан соң эшләүче гражданнарны шифаханә-курортта дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыра.

Эш бирүчеләр:

6.29. Кирәк булган очракта, яшь эшчеләр һәм белгечләр әзерләү, укучылар һәм студентларга производство практикасы үткәрүне, педагог һәм мастерларга стажировка үтүне оештыру максатында, һөнәри белем бирү оешмалары белән, шул исәптән инженер-педагогик персоналны һәм профильле һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларны стимуллаштыруны, шулай ук һөнәри белем бирү оешмаларының матди-техник тәэмин ителешен үстерүне финанслашуда катнашуны күздә тоткан килешүләр төзи.

6.30. Укучыларны гамәли әзерләүне оештыруда, һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында укучылар өчен дуаль белем бирү рәвешләрен кертүдә, шулай ук аларның һөнәри квалификациясе нигезендә мөмкинлекләре булган очракта эшкә урнаштыруда ярдәм итә.

6.31. Коллектив килешүләрдә яшьләр белән эшләү чараларын, шул исәптән яшьләрне социаль яклауга юнәлдерелгән чаралар күздә тотыла. Финанс мөмкинлекләре булганда, тәүге тапкыр эшкә урнашучы һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлап чыгучыларга бер тапкыр түләнә торган акчалата түләүләр һәм башка кызыксындыру чараларын, квалификациясен күтәрү һәм алга таба белемнәрен үстерү, торак сатып алуга яки төзүгә ташламалы ссудалар, кредитлар, торакны наемга алуга һәм балаларны мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тотуга акчалата компенсацияләр алуны, балалар савыктыру лагерьларына юлламалар өчен түләү, өч яше тулганчы бала карау буенча ялда булган хатын-кызларга түләүләр мөмкинлеген күздә тота.

6.32. Яшь белгечләрне (эшчеләр) предприятиеләргә җәлеп итү, җайлаштыру һәм шунда төпләнеп калдыру максатында түбәндәге мөмкинлекләрне карый:

остазның тариф ставкасына (окладына) өстәмә түләү билгеләү мөмкинлеге белән остазлык институтын формалаштыру һәм үстерү;

«Яшьләрнең иң яхшы остазы» һөнәри осталык конкурсларын үткәрү.

6.33. Хезмәт базарында ихтыяҗ булган һөнәрләр белән таныштыру максатыннан чыгып, Ачык ишекләр көннәре, оешмаларга экскурсияләр уздыра.

6.34. Хезмәткә түләү, җитәкче вазыйфаларга билгеләү, эшкә алу мәсьәләләрендә гендерлык тигезлеген тәэмин итә.

6.35. Коллектив килешүләрдә түбәндәге чараларны күрә:

эшләүче хатын-кызларны һөнәри үстерү, шулай ук хезмәт эшчәнлеген туктатып торган, шул исәптән бала табу һәм карау белән бәйле рәвештә, хатын-кызларга һөнәри белем бирү һәм яңадан укыту;

имин хезмәт шартлары тудыру өлкәсендә, эшләп чыгару (хезмәт күрсәтү) нормаларны киметү яки башка эшкә күчерү, җитештерүнең зарарлы факторлары тәэсир итүне булдырмау, эшнең сыгылмалы графикларын, дистанцион (ерактан торып) эшләү режимын куллану, элеккеге эш урыны буенча эш хакын саклап, эш атнасын кыскарту, аларга уңайлы вакытта еллык ял бирү, сан яки штат кыскару буенча эштән чыгаруны булдырмау, өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ балаларны сәламәтләндерү өчен шәһәр яны балалар сәламәтләндерү лагерьларына юлламалар бирү, тулы эш сәгате өчен түләүне саклап, әмма Татарстан Республикасындагы эшкә яраклы халык өчен яшәү минимумы зурлыгыннан ким булмаган, тулы булмаган эш сәгате билгеләү һәм башкалар буенча хатын-кызларны (аналарыннан башка балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче аталар, шулай ук балигъ булмаган балаларның опекуннары, попечительләре), йөкле хатыннарны социаль яклау;

гаилә бурычлары булган затларга ярдәм итүнең өстәмә чараларын күрү (бала туу уңаеннан, беренче сыйныф укучыларының ата-аналары өчен «Белем көне»нә, гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның ата-аналары өчен «Соңгы кыңгырау көне»нә өстәмә түләүле көннәр бирү, матди ярдәм күрсәтү һ.б.)

Хөкүмәт:

6.36. Законнар нигезендә бюджет өлкәсендә яшь белгечләргә дәүләт финанс ярдәме күрсәтүгә ярдәм итә.

6.37. Торак программалары кысаларында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә социаль ярдәм чараларын күрсәтә.

6.38. Эшсез яшьләрне һәм хатын-кызларны нәтиҗәле төстә эшкә урнаштыруга ярдәм итә.

6.39. Яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен, сәламәтлек саклауны формалаштыру, социаль яктан тискәре күренешләрне профилактикалау өчен шартлар тудыруда ярдәм күрсәтә.

6.40. Өстенлекле юнәлешләр сыйфатында шәһәр янындагы савыктыру лагерьларында ялны һәм ел буе эшли торган шифаханә-курорт оешмаларында савыктыруны күздә тотып, балалар һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны оештыру программасын кабул итә.

6.41. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре белән берлектә мәктәпкәчә белем бирү оешмалары челтәрен саклау һәм киңәйтү, балалар бакчаларына чиратларны бетерү, балаларга мәктәпкәчә белем бирү өлкәсен киңәйтү буенча чаралар күрә.

6.42. Балаларга өстәмә белем бирүнең республика системасын үстерү буенча, шул исәптән аның инфраструктурасын модернизацияләү, төрле белем бирү ихтыяҗлары һәм мөмкинлекләре булган балалар өчен өстәмә белем алу мөмкинлеген арттыру һәм аның сыйфатын яхшырту буенча, шулай ук гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен матди-техник базаны яңарту буенча чаралар күрә.

7. Социаль партнерлыкны үстерү

Республика социаль һәм икътисадый үсешенең төп мәсьәләләре, хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу мәсьәләләре буенча карарлар кабул иткәндә, шулай ук Килешүдәге йөкләмәләрне һичшиксез үтәгәндә, хезмәт өлкәсендә социаль партнерлык мөмкинлекләрен максималь дәрәҗәдә кулланыуны тәэмин итү максатларында, Яклар:

7.1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында хезмәт өлкәсендә социаль партнерлыкны үстерү турында» 2015 елның 17 ноябрендәге ПУ-1105 номерлы Указын үтәү кысаларында дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, эш бирүчеләр һәм һөнәр берлекләренең үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру буенча булышлык күрсәтә.

7.2. Социаль-икътисадый юнәлештәге закон проектларын һәм башка норматив хокукый актларны эшләүдә һәм (яки) тикшерүдә бергәләп катнаша.

7.3. Милекнең барлык рәвешендәге оешмаларда социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен кумәк-шартнамәле җайга салу практикасын үстерүдә ярдәм күрсәтү.

7.4. Социаль партнерлык субъектларына һәм аларның вәкилләренә шартнамәләр һәм коллектив килешүләр төзүдә һәм аларны хәбәр итеп теркәүдә кирәкле оештыру һәм методик ярдәм күрсәтә.

7.5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре дәрәҗәсендә социаль партнерлыкны, социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы комиссияләр эшчәнлеген үстерүгә һәм территориаль, территориаль-тармак шартнамәләре төзүгә ярдәм күрсәтә.

7.6. Тармак (тармакара) һәм территориаль дәрәҗәләрдә килешүләр төзү тәҗрибәсен, шулай ук социаль партнерлык органнарының эш тәҗрибәсен мониторинглауны һәм анализлауны гамәлгә ашыра.

7.7. Барлык оештыру-хокук формасындагы һәм милек рәвешендәге оешмаларны социаль партнерлык системасына җәлеп итү эшен дәвам итә.

7.8. Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясенең тиешле тармак һәм территориаль комиссияләр белән берлектә эшләвен тәэмин итә.

7.9. Төбәк, тармак эш бирүчеләр берләшмәләре әгъзалары булып торучы эш бирүчеләр санын арттыруга, яңа территориаль эш бирүчеләр берләшмәләрен, беренчел һөнәр берлеге оешмаларын булдыруга һәм ныгытуга булышлык күрсәтә.

7.10. Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясенең 2010 елның 20 октябрендәге карары нигезендә хупланган «Социаль җаваплылык турында» Республика стандарты нормаларын шартнамәләрнең һәм коллектив килешүләрнең тиешле бүлекләренә кертү буенча чаралар күрә.

7.11. Өчьяклы хезмәттәшлек механизмын камилләштерү максатыннан чыгып, хезмәт өлкәсендә социаль партнерлыкның торышына һәм аны үстерүгә анализ ясый, киңәшмәләр, семинарлар, конференцияләр, «түгәрәк өстәл» утырышлары һәм башка чаралар үткәрә.

7.12. Кумәк хезмәт бәхәсләрен кисәтү һәм җайга салу буенча чаралар күрә, оешмаларда хезмәт бәхәсләре буенча комиссияләр төзүгә һәм аларның эшчәнлегенә булышлык күрсәтә.

7.13. Килешү нигезендә һөнәр берлекләре оештырган Яклар вәкилләрен укытуда катнашуда һәм аны финанслауда булышлык күрсәтә.

7.14. Хезмәткәрләр вәкилләренең оешма идарәсенең коллегиаль органы утырышларында киңәшү тавышы белән катнашуга федераль законнарда, оешманы гамәлгә кую документларында, эчке регламентта, оешманың бүтән эчке документлары, кумәк килешүләр, шартнамәләрдә билгеләнгән хокукын тормышка ашыра.

Һөнәр берлекләре:

7.15. Республика, тармак (тармакара), территориаль шартнамәләр һәм коллектив килешүләр төзү мәсьәләсен күтәрә; кумәк-килешү кампаниясен әзерләү һәм үткәрүгә ярдәм итә; шартнамәләр һәм коллектив килешүләр проектларын законнарга һәм шартнамәләргә туры килүгә экспертиза үткәрүне тәэмин итә.

7.16. Тармак (тармакара), территориаль шартнамәләр һәм коллектив килешүләр төзү һәм аларның үтәлешен контрольдә тоту буенча һөнәр берлекләренең шәһәр һәм район тармак комитетлары (советлары), һөнәр берлеге оешмаларының координация советлары, беренчел һөнәр берлеге оешмалары эшен оештыра.

7.17. Хезмәт хокукларын һәм социаль гарантияләрне яклау буенча һөнәр берлеге әгъзаларына түләүсез юридик ярдәм күрсәтә .

7.18. Оешмаларда хезмәт бәхәсләре буенча комиссияләр оештыруга һәм аларның нәтиҗәле эшчәнлегенә ярдәм итә.

7.19. Республика тармак һөнәр берлеге органнары, һөнәр берлеге оешмаларының координация советлары һәм беренчел һөнәр берлеге оешмалары дәрәҗәсендә хокук хезмәтләрен ныгытуны тәэмин итә.

7.20. Хезмәт бәхәсләре буенча комиссияләргә, Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясенә, суд органнарына һәм прокуратура органнарына мөрәҗәгатьләр аша хезмәткәрләрнең бозылган хезмәт хокукларын торгызуда хокукый ярдәм күрсәтә.

7.21. Һөнәр берлеге әгъзаларын социаль партнерлык мәсьәләләре буенча укытуны оештыра, шул исәптән Һөнәр бер-

лекләренең уку-укыту-тикшерену үзәге һәм һөнәр берлеге активы мәктәпләре базасында.

7.22. Социаль партнерлык өлкәсендә Россия Федерациясе төбәкләренең һөнәр берлеге оешмалары тәҗрибәсен өйрәнә һәм куллана.

7.23. «Иң яхшы коллектив килешү» республика конкурсын үткәрә.

7.24. Яңа кабул ителгән хезмәткәрләрне оешмада эшли торган коллектив килешү, тармак тариф шартнамәсе белән таныштыруны тәэмин итә.

Эш бирүчеләр:

7.25. Бу Килешүгә кушылган эш бирүчеләрнең санын арттыру буенча чаралар күрә, эш бирүчеләр берләшмәләре әгъзалары тарафыннан кабул ителгән йөкләмәләрне үтәүнең барышын даими рәвештә тикшереп тора.

7.26. Республиканың муниципаль районнарында эш бирүчеләр берләшмәләрен булдыру буенча эшне оештыруда булышлык күрсәтә, тиешле оештыру-методик ярдәм күрсәтә; кабул ителә торган карарлар турында Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясенә хәбәр итеп тора.

7.27. Законнар кысаларында барлык милек формасындагы оешмаларда шартнамәләр һәм коллектив килешүләр төзүгә ярдәм итә.

7.28. Оешмаларда һөнәр берлекләренең һәм аларның сайланган органнарының устав эшчәнлеге тәэмин итү өчен шартлар тудыра; һөнәр берлекләренең Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән хокукларын бозу очракларына һөнәр берлекләре оешмалары чыгуга юл куймый.

7.29. Хезмәткәрләренең вәкилләре соратуы буенча килешүләр һәм коллектив шартнамәләр төзү һәм аларны үтәүгә йомгак ясау өчен кирәкле мәгълүматны бирә, законнар нигезендә коммерциячел серне тәшкил иткән мәгълүматтан тыш.

7.30. Хезмәт турындагы законнарның үтәлешенә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген, шулай ук һөнәр берлеге контролен гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итә; хезмәткәрләрнең, социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре коллектив-килешүле җайга салуны үстерү максатларында, башлангыч һөнәр берлеге оешмаларын төзү (торгызу) инициативасына каршы чыкмый.

7.31. Шартнамәләргә һәм коллектив килешүләргә түбәндәге йөкләмәләрне кертү мөмкинлеген карап тикшерә:

һөнәр берлеге органнарының чыккан хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләүгә акча бүлеп бирү;

уртача айлык хезмәт хакын саклап, барлык дәрәҗәләрдәге һөнәр берлеге органнарының чыкмаган әгъзаларына иҗтимагый бурычларын үтәүгә вакыт бирү.

7.32. Корпоратив социаль җаваплылык, бизнесның этик стандартлары өлкәсендә Россия һәм чит илләр компанияләренең иң яхшы тәҗрибәсен таныту һәм булешүдә катнаша.

Хөкүмәт:

7.33. Түбәндәгеләрне тәэмин итә:

билгеләнгән тәртиптә Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе эшчәнлеген;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан эшләнгән, хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм аның белән турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрне җайга сала торган законнар проектларын һәм бүтән норматив хокукый актлар проектларын, аларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертүгә кадәр яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карар кабул иткәнгә кадәр Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе утырышында карап тикшерүне;

Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе карарларын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертүне һәм аларны Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары карап тикшерүне, э җайга салынмый торган каршылыклар булганда – Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясенә җибәрелгән хезмәт өлкәсендә законнар һәм бүтән норматив хокукый актлар проектларына карата Якларның фикерләрен;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан эшләнгән, хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм аның белән турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрне җайга сала торган законнар проектларын һәм бүтән норматив хокукый актлар проектларын Якларның килештерүен;

республика һәм тармак дәрәҗәләрендә социаль-хезмәт мәсьәләләре буенча комиссияләр һәм эшче төркемнәр эшендә Якларның вәкилләре катнашуын;

Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясенең эшче төркеме утырышларында ярты ел һәм ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасы халкы тормышының сыйфаты һәм дәрәҗәсе индикаторларын карап тикшерүне, әлеге Килешүгә кушымтада каралган индикаторларны үтәмәү сәбәпләренә анализ үткәрүне;

законнарда билгеләнгән тәртиптә оешмаларның тармак (тармакара) һәм территориаль шартнамәләрен, коллектив килешүләрен хәбәр итеп теркәүне, аларның үтәлешен контрольдә тотуны.

7.34. Якларга социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсенә кагылышлы мәсьәләләр буенча билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат бирә.

7.35. Тармак һәм территориаль дәрәҗәләрдә хезмәт өлкәсендә социаль партнерлыкны үстерү мәсьәләләрен яраштыра, Татарстан Республикасы территориясендә һөнәр берлекләре (һөнәр берлекләре берләшмәләре) эшчәнлеге өчен кирәкле шартлар булдыруда булышлык күрсәтә.

7.36. Оешмаларга финанс ярдәме һәм башка ярдәм күрсәтү критерийлары буларак үз вакытында һәм тулы күләмдә хезмәт хакы түләүне тәэмин итү буенча хәлне, социаль партнерлык системасында катнашуны, хезмәт турында законнарны үтәүне, шартнамәләр һәм коллектив килешүләр йөкләмәләрен үтәүне исәпкә ала.

7.37. Якларны кызыксындырган мәсьәләләр буенча консультацияләр һәм мәгълүмат бирү өчен, Татарстан Республикасының һөнәр берлеге активы һәм эш бирүчеләре белән очрашулар үткәрә.

8. Әлеге Килешүне үтәүне оештыру һәм аның үтәлешен контрольдә тоту тәртибе

Яклар:

8.1. Ел саен Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе, аның эш төркемнәре утырышларында бу Килешүнең йөкләмәләрен үтәү нәтиҗәләрен, республика икътисадындагы вәзгыятьнең үзгәрүенә, әлеге Килешүгә кушымтада китерелгән индикаторларга нигезләнеп, Яклар тәкъдим иткән мәгълүматны карап тикшерәләр. Әлеге Килешүгә кушымтада тәкъдим ителгән индикаторлар нигезендә үз йөкләмәләренең үтәлешен һәм социаль партнерлыкның нәтиҗәлелеген бәялиләр.

8.2. Социаль партнерлык мәсьәләләрен, бу Килешүне үтәүнең барышын, Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе эшен республика һәм муниципаль массакүләм мәгълүмат чараларында, Якларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында яктыртуны оештыра.

8.3. Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясенең эш тематикасы һәм бу Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган кушымтада китерелгән 2023–2024 елларга Татарстан Республикасы халкының тормыш дәрәҗәсенең төп социаль-икътисадый индикаторлары нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Якларны тиешле мәгълүмат-статистика материаллары белән тәэмин итә.

9. Йомгаклау нигезләмәләре

9.1. Әлеге Килешү 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

9.2. Килешүнең тексты «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында бастырып чыгарыла, Якларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларына урнаштырыла.

9.3. Әлеге Килешүгә өстәмәләр һәм үзгәрешләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексында билгеләнгән тәртиптә Якларның үзара килешүе буенча кертелә.

9.4. Әлеге Килешүнең йогынтысы түбәндәгеләргә кагыла:

әлеге Килешүне төзегән, эш бирүчеләр берләшмәсе әгъзалары булган барлык эш бирүчеләргә – юридик затларга, юридик зат булып оешмаган индивидуаль эшмәкәрләргә. Эш бирүчеләр берләшмәсендә әгъзалыктан чыгу эш бирүчене аның әгъзалыгы чорында төзелгән әлеге Килешүне үтәүдән азат итми. Эш бирүчеләр берләшмәсенә әлеге Килешү гамәлдә булган чорда кергән эш бирүче бу Килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәргә бурычлы;

эш бирүчеләр берләшмәсенә үз исеменнән күмәк сөйләшүләрдә катнашуны һәм бу Килешүне төзүне йөкләгән яисә әлеге Килешүгә аны төзегәннән соң кушылган, әлеге Килешүне төзегән эш бирүчеләр берләшмәсе әгъзалары булмаган, шулай ук Килешү рәсми басылып чыккан көннән соң 30 календарь көне эчендә яисә аларны дәүләт теркәвенә алган көннән 30 календарь көне эчендә аңа кушылудан баш тарту турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына язма рәвештә белдермәгән, әлеге Килешүгә кушылу турында тәкъдим рәсми басылып чыккан көннән соң төзелгән һәм үз эшчәнлеген башлап җибәргән эш бирүчеләргә – юридик затларга, юридик зат булып оешмаган индивидуаль эшмәкәрләргә;

үзләренә йөкләнгән бурычлар чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына;

әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән эш бирүчеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торган барлык хезмәткәрләргә;

Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясенең әгъза оешмалары булган һөнәр берлекләренә.

9.5. Якларны үзгәртеп оештырган яки бетергән очракта, әлеге Килешү төзелгән бөтен чорга үз көчендә кала һәм аны үтәү өчен җаваплылык хокуклы дәвамчыларына йөкләнә.

9.6. Әлеге Килешүгә аңлатма бирү һәм аннан файдалануга бәйле Яклар арасында килеп чыккан бәхәсләр үзара консультацияләр һәм сөйләшүләр юлы белән хәл ителә.

9.7. Әлеге Килешүнең шартларын үтәүне контрольдә тоту турыдан-туры Яклар һәм Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе тарафыннан тормышка ашырыла.

9.8. Яклар законнар һәм (яки) үз уставлары нигезендә сөйләшүләрдә катнашудан читләшкән, әлеге Килешүдәге йөкләмәләрне бозган яки үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән), күмәк сөйләшүләр үткәрү һәм әлеге Килешүне үтәүне контрольдә тоту өчен кирәкле мәгълүмат тапшырмаган өчен җавап бирә.

9.9. Яклар тарафыннан нигезле дип танылган сәбәпләр буенча әлеге Килешүдәге йөкләмәләр үтәлмәгәндә әлеге йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү буенча килештерелгән өстәмә чаралар күрелә.

9.10. Яклар 2024 елның III кварталында киләсе чорга килешү төзү буенча яки әлеге Килешүнең гамәлдә булу вакытын озайту мөмкинлеге турында сөйләшүләр үткәрү буенча килеште.

9.11. Әлеге Килешү тигез юридик көчкә ия булган дүрт нөсхәдә, һәр Якка һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына берәр нөсхәдә имзаланды.

Һөнәр берлекләреннән:	Эш бирүчеләрдән:	Хөкүмәттән:
Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе рәисе	Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең Координация советы рәисе	Татарстан Республикасы Премьер-министры
_____Е.И. Кузьмичева	_____А.П. Лаврентьев	______ А.В. Песошин

2023–2024 елларга социаль-икътисадый сәясәт үткәрү һәм социаль партнерлыкны үстерү турында Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең координация советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында Республика килешүенә кушымта

2023–2024 елларга Татарстан Республикасы халкы яшәү сыйфатының һәм тормыш дәрәҗәсенең төп социаль-икътисадый индикаторлары[1]

Т/с	Индикатор исеме	Индикаторлар мәгънәләре	
		2023 елга (фараз)	2024 елга (фараз)
1	2	3	4
1.	Тулай төбәк продукты күләме, млн сум	3 869 637,4	4 150 300,4
2.	Кулланучылар бәяләре индексы, узган елның декабренә карата проценттан артмаган	106,1	104,0
3.	Сәнәгать җитештерүе индексы, узган елга карата проценттан артмаган	100,7	103,5
4.	Пенсионерларны һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалауны оештыру чыгымнары, млн сумнан да ким түгел.	170,8	177,6
5.	Теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе, проценттан артмаган	0,6%	0,6%
6.	Акчалата кереме яшәү минимумыннан түбәнрәк халык өлеше, проценттан артмаган	5,7%	5,5%
7.	Оешмаларның тулы даирәсе буенча айлык уртача хезмәт хакы, кече эшмәкәрлекне дә кертеп (уртача елга), кимендә сум	53 728,4	57 425,4
8.	Оешмаларның тулы даирәсе буенча реаль хезмәт хакы, кече эшмәкәрлекне дә кертеп, алдагы елга карата кимендә %	102,0	102,8
9.	Оешмаларның тулы даирәсендә эшләүчеләрнең уртача исемлек санында оешмаларда эшләүчеләр өлеше, беренчел һөнәр берлекләре оешмалары тарафыннан төзелгән күмәк шартнамәләр белән колачланган кече эшмәкәрлек субъектларын да кертеп, кимендә %	46,8	46,8
10.	Производствода бер эш көненә һәм аннан да күбрәккә хезмәт сәләтен югалткан һәм үлем белән тәмамланган зыян күрүчеләр саны (1000 эшләүчегә), проценттан артмаган	0,87	0,86
11.	Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештырылган формалар белән тәэмин итү, кимендә мең кеше	218,7	218,7
	шул исәптән шәһәр яны лагерьларында	100,6	100,6

[1] Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе карары белән 2023–2024 елларга Татарстан Республикасы халкының яшәү сыйфатының һәм тормыш дәрәҗәсенең төп социаль-икътисадый индикаторлары, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан эшләнә торган Россия икътисадын үстерүнең сценар шартларын һәм Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш нәтиҗәләрен исәпкә алып, төгәлләштерелергә мөмкин.

ЭШ БИРҮЧЕЛӘРГӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҺӨНӘРИ БЕРЛЕКЛӘР ФЕДЕРАЦИЯСЕ БЕЛӘН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭШ БИРҮЧЕЛӘР БЕРЛӘШМӘЛӘРЕНЕҢ КООРДИНАЦИЯ СОВЕТЫ ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АРАСЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА МИНИМАЛЬ ХЕЗМӘТ ХАКЫ ТУРЫНДА 2022 ЕЛНЫҢ 28 ДЕКАБРЕНДӘГЕ КИЛЕШҮГӘ КУШЫЛУ ХАКЫНДА ТӘКЪДИМ

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы, әлеге Килешүне төзүдә катнашмаган эш бирүчеләргә, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 133.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең Координация советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында 2022 елның 28 декабрендәге Татарстан Республикасында минималь хезмәт хакы турындагы килешүгә кушылырга тәкъдим итә.

Килешү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында 2022 елның 28 декабрендә 342 номер белән теркәлгән.

Әгәр Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы эш бирүчеләр әлеге тәкъдим рәсми басылып чыккан көннән 30 (утыз) календарь көне эчендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына язма рәвештә югарыда күрсәтелгән Килешүгә кушылудан нигезле баш тарту тапшырмасалар, әлеге Килешү бу тәкъдим рәсми басылып чыккан көннән соң әлеге эш бирүчеләргә таратылган дип санала һәм алар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш.

Күрсәтелгән баш тартуга түбәндәгеләр теркәлергә тиеш:

әлеге эш бирүче хезмәткәрләрен берләштерүче беренчел һөнәр оешмасының сайланган органы белән эш бирүченең консультацияләре беркетмәсе;

югарыда күрсәтелгән Килешүнең 1 статьясындагы 1 пунктында каралган күләмгә кадәр хезмәткәрләрнең минималь хезмәт хакын арттыру сроклары буенча тәкъдимнәр. Шул ук вакытта Килешүнең 1 статьясындагы 6 пункты белән минималь хезмәт хакы күләмен арттыруның киләсе срогы 2023 елның 1 гыйнварыннан билгеләнә, дип каралган.

Эш бирүче хезмәткәрләре нинди дә булса беренчел һөнәр оешмаларына яки беренчел һөнәр оешмаларының берсе дә әлеге эш бирүченең яртысыннан артыгын берләштермәгән һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексы белән билгеләнгән тәртиптә әлеге эш бирүченең барлык хезмәткәрләренең мәнфәгатьләрен якларга вәкаләтле булмаган очракларда, күрсәтелгән баш тартуга эш бирүченең Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 31 статьясында билгеләнгән тәртиптә сайланган башка вәкиллекле орган (вәкил) белән консультацияләр беркетмәсе һәм югарыда күрсәтелгән Килешүнең 1 статьясындагы 1 пунктында каралган күләмгә кадәр хезмәткәрләрнең минималь хезмәт хакын арттыру сроклары буенча тәкъдимнәр беркетелергә тиеш.

Эш бирүче югарыда күрсәтелгән Килешүгә кушылудан баш тарткан очракта, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы әлеге эш бирүче вәкилләрен, әлеге эш бирүчене берләштерә торган беренчел һөнәр оешмасының сайланулы органы вәкилләрен яисә әлеге эш бирүче хезмәткәрләренең бүтән вәкиллекле органы вәкилләрен Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе яклар катнашында консультацияләр үткәрү өчен чакырырга хокуклы.

Эш бирүче вәкилләре, беренчел һөнәр оешмасының сайланган органы вәкилләре яки эш бирүче хезмәткәрләренең башка вәкиллекле органы вәкилләре һәм Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе вәкилләре әлеге консультацияләрдә катнашырга бурычлы.

Эш бирүчеләрнең әлеге Килешүгә кушылудан язмача баш тартулары күчермәләре Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәт инспекциясенә җибәрелә.

Татарстан Республикасы
хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министры,
Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен
җайга салу буенча
республика өчьяклы комиссиясенең
Хөкүмәт ягыннан координаторы Э.Ә. Зарипова

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА МИНИМАЛЬ ХЕЗМӘТ ХАКЫ ТУРЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҺӨНӘР БЕРЛЕКЛӘРЕ ФЕДЕРАЦИЯСЕ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭШ БИРҮЧЕЛӘР БЕРЛӘШМӘЛӘРЕНЕҢ КООРДИНАЦИЯ СОВЕТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АРАСЫНДА

КИЛЕШҮ

Казан шәһәре 2022 ел, 28 декабрь, № 342

«Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе» берлеге (алга таба – Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе) – Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе Уставы нигезендә эш итүче рәисе Кузьмичева Елена Ивановна йөзендә, Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең координация советы – Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләре координация советы турындагы нигезләмәгә таянып эш итүче рәисе Лаврентьев Александр Петрович йөзендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Конституциясе, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры Песошин Алексей Валерьевич йөзендә, алга таба Яклар дип атала, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 133[1] статьясы, «Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнары турында» 2004 елның 26 июлендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеде:

1 статья

1. Татарстан Республикасы территориясендә эшләүче хезмәткәрләр өчен (федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан финанслана торган оешмаларның хезмәткәрләреннән тыш) 2023 елның 1 гыйнварыннан минималь хезмәт хакы аена 19 565 сум күләмендә билгеләнә.

2. Минималь хезмәт хакы 2022 елның III кварталына Татарстан Республикасы буенча тулаем минималь куллану бюджетының кыйммәти зурлыгыннан 93,0 процент күләмендә билгеләнде һәм ул Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән эш вакытының айлык нормасын эшләгән һәм тариф ставкасын (окладын) яисә тарифсыз система буенча хезмәт хакын, шулай ук өстәп түләүләрне, өстәмәләрне, премияләрне һәм башка түләүләрне (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 147, 151–154 статьялары нигезендә башкарыла торган түләүләрдән тыш) үз эченә алган хезмәт нормасын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәүче хезмәткәргә түләнә торган түләүләрнең минималь суммасыннан гыйбарәт.

Татарстан Республикасында әлеге Килешү белән билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләме икътисадның бюджеттан тыш секторы оешмалары һәм, юридик зат оештырмыйча, үз акчасы исәбеннән эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыручы индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан тәэмин ителә.

3. Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре өчен минималь хезмәт хакы «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы территориясендә эшләүче һәм үзенә карата әлеге Килешү гамәлдә булган яки Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 133[1] статьясында билгеләнгән тәртиптә әлеге Килешүнең гамәле кагылган эш бирүче белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы хезмәткәрнең айлык хезмәт хакы, әлеге хезмәткәр тарафыннан шушы чорда эш вакыты нормасы тулысынча эшләнү һәм хезмәт нормалары (хезмәт йөкләмәләре) үтәлү шарты белән, әлеге Килешүдә билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләменнән түбән була алмый.

5. Әлеге Килешүдә билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләме хезмәт өчен түләү буенча югарырак минималь гарантияләр билгеләүгә чикләү булып тормый.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында каралган хезмәткәрләр өчен билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләмен Татарстан Республикасында минималь куллану бюджетының кыйммәти зурлыгына кадәр этаплап күтәрү («Татарстан Республикасында минималь куллану бюджеты турында» 2008 елның 23 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясын гамәлгә ашыру кысаларында) максатларында минималь хезмәт хакы күләмен арттыруның киләсе срогы 2024 елның 1 гыйнварыннан, 2023 елның II кварталына Татарстан Республикасы буенча тулаем минималь куллану бюджетының кыйммәти күләменнән процентлы нисбәттә билгеләнә.

2 статья

Әлеге Килешүне гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен Яклар:

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 133[1] статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашырган һәм әлеге Килешүне төзүдә катнашмаган эш бирүчеләрнең әлеге Килешүгә кушылуын тәэмин итү буенча чаралар күрә, шул исәптән әлеге Килешүгә кушылудан баш тарткан эш бирүче вәкилләре һәм бу эш бирүче хезмәткәрләрен берләштергән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы вәкилләре белән консультацияләрдә катнаша;

шушы чорда эш вакыты нормасын тулысынча эшләгән һәм хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) башкарган хезмәткәрнең айлык хезмәт хакы күләмен әлеге Килешүдә билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләменнән түбән булмаган дәрәҗәдә хезмәт өчен түләү күләмнәрен билгеләү буенча чаралар күрә;

әлеге Килешүнең үтәлешен мониторинглауны гамәлгә ашыра һәм аның нәтиҗәләрен Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе һәм аның эшче төркеме утырышларында елга кимендә бер тапкыр карап тикшерә.

3 статья

1. Әлеге Килешү төзелгәннән соң, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы буларак, Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашырган һәм әлеге Килешүне төзүдә катнашмаган эш бирүчеләргә аңа кушылырга тәкъдим итә. Әлеге тәкъдим бу Килешүнең тексты белән бергә «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында рәсми басылып чыгарга тиеш.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы әлеге Килешүне һәм аңа кушылу турындагы тәкъдимне бастырып чыгару турында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына хәбәр итә.

2. Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашырган эш бирүчеләр тарафыннан эш бирүчеләргә әлеге Килешүгә кушылу турында тәкъдим рәсми басылып чыккан көннән 30 календарь көне эчендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына әлеге пункт белән билгеләнгән тәртиптә аңа кушылудан дәлилләнгән язма баш тарту кәгазе җибәрелмәгән булса, бу Килешү әлеге тәкъдим рәсми басылып чыккан көннән югарыда күрсәтеп үтелгән эш бирүчеләргә кагыла дип санала һәм алар тарафыннан мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиеш. Баш тарту кәгазенә бу эш бирүченең хезмәткәрләрен берләштерә торган башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән консультацияләр беркетмәсе һәм хезмәткәрләрнең минималь хезмәт хакын әлеге Килешүнең 1 статьясындагы 1 пунктында каралган күләмгә кадәр арттыру сроклары турында тәкъдимнәр теркәлергә тиеш.

Әлеге эш бирүченең хезмәткәрләре нинди дә булса башлангыч һөнәр берлеге оешмаларына берләштерелмәгән яисә башлангыч һөнәр берлеге оешмаларының берсе дә әлеге эш бирүче хезмәткәрләренең яртысыннан күбрәген берләштермәгән һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексында билгеләнгән тәртиптә әлеге эш бирүченең барлык хезмәткәрләренең мәнфәгатьләрен тәкъдим итәргә вәкаләтле булмаган очракларда, баш тарту кәгазенә эш бирүченең Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 31 статьясында билгеләнгән тәртиптә сайланган башка вәкиллекле орган (вәкиле) белән консультацияләр беркетмәсе һәм хезмәткәрләрнең минималь хезмәт хакын әлеге Килешүнең 1 статьясындагы 1 пунктында каралган күләмгә кадәр арттыру сроклары турындагы тәкъдимнәр теркәлергә тиеш.

3. Эш бирүчеләр – Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашырган, әлеге Килешүгә кушылу турындагы тәкъдим рәсми басылып чыккан көннән соң төзелгән һәм үз эшчәнлеген башлап җибәргән юридик затлар, юридик зат булып оешмаган индивидуаль эшмәкәрләр, әлеге Килешүгә кушылу мөмкинлеге булмаган очракта, дәүләт теркәвенә алынган көннән алып 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына әлеге статьяның 2 пунктында каралган документлар белән бергә дәлилләнгән язма баш тарту кәгазе җибәрергә хокуклы.

Әлеге дәлилләнгән язма баш тарту кәгазе тапшырылмаган очракта, әлеге Килешү бу эш бирүчеләргә кагыла дип санала һәм алар тарафыннан мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиеш.

4. Эш бирүче әлеге Килешүгә кушылудан баш тарткан очракта, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясенең Яклар вәкилләре катнашында консультацияләр үткәрү өчен бу эш бирүченең вәкилләрен чакырырга хокуклы.

Эш бирүче һәм Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе вәкилләре бу консультацияләрдә катнашырга тиеш.

5. Эш бирүчеләрнең әлеге Килешүгә кушылудан язма баш тарту кәгазьләренең күчермәләре Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясенә җибәрелә.

4 статья

1. Әлеге Килешү шартларының үтәлешен контрольдә тоту Яклар тарафыннан үзләре билгели торган тәртиптә турыдан-туры гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге Килешүнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашырганда, Яклар тиешле рәсми сорау алынган көннән алып 30 календарь көне эчендә моның өчен кирәкле барлык мәгълүматны бер-берсенә тапшырырга бурычлы.

5 статья

Әлеге Килешү Татарстан Республикасы икътисадының бюджеттан тыш секторы оешмаларына – Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашырган, әлеге Килешүне төзегән яки әлеге Килешүнең 3 статьясында билгеләнгән тәртиптә әлеге Килешүгә кушылган юридик затлар, юридик зат булып оешмаган шәхси эшмәкәрләргә кагыла.

6 статья

Әлеге Килешүнең шартларына Якларның үзара ризалыгы белән теләсә кайсы вакытта үзгәреш кертелергә мөмкин. Үзгәрешләр Килешү төзү өчен каралган тәртиптә кертелә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләмен киметә алмый.

7 статья

Әлеге Килешүне аңлатуга һәм куллануга бәйле рәвештә, Яклар арасында барлыкка килә торган бәхәсләр үзара консультацияләр һәм сөйләшүләр юлы белән хәл ителә.

8 статья

1. Әлеге Килешү тексты түбәндәгеләргә җибәрелә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына, шулай ук билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырып чыгаруга;

Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең координация советы тарафыннан – әлеге берләшмәләр составына керә торган оешмаларга;

Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе тарафыннан – республика тармак һөнәр берлекләре оешмаларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең һөнәр берлекләре оешмалары координация советларына, Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы һөнәр берлекләре тармак комитетларына (советларына), Татарстан Республикасы предприятиеләренең, оешмаларының һәм учреждениеләренең башлангыч һөнәр берлекләре оешмаларына.

2. Әлеге Килешү тексты Якларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларына урнаштырыла.

9 статья

Әлеге Килешүгә бер үк юридик көчкә ия булган өч, һәр Як өчен берәр нөсхәдә кул куелды.

10 статья

Әлеге Килешү 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм Татарстан Республикасында минималь хезмәт хакы турында яңа килешү үз көченә кергәнгә кадәр гамәлдә була.

Якларның имзалары:

Татарстан Республикасы Премьер-министры	Татарстан Республикасының Һөнәр берлекләре федерациясе рәисе	Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең координация советы рәисе
____А.В. Песошин	____Е.И. Кузьмичева	____А.П. Лаврентьев

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасының Спорт көрәше федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы башкарма комитеты әгъзасы **Бозин** Анатолий Алексеевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе аеруча мөһим эшләрне тикшерү буенча беренче бүлеге җитәкчесе, юстиция полковнигы **Билалов** Рамил Кашафетдин улы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының җинаятьчеләрне эзләү идарәсе урлау һәм талау очракларын ачу бүлеге башлыгы, полиция полковнигы **Катипов** Рефат Нариман улы, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының Су ресурслары өлкәсендә дәүләт сәясәте һәм җайга салуы департаменты директоры **Минухин** Роман Борисович, «Юристъ» хокук агентлыгы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Ихсанов** Илсур Фәнил улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Әлмәт-Водоканал» акционер җәмгыятенең суүткәргеч челтәрләр участогы аварияләрдән соң торгызу эшләре слесаре **Вәлиев** Раушан Илгиз улына, Казан шәһәре «Шәһәр күперләре» муниципаль унитар предприятиесенең юл эшчесе **Хәлилов** Исхак Шаһит улына **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге башлап сорау алу бүлекчәсе башлыгы, полиция майоры **Бикколова** Светлана Фәрит кызына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының эш башкару һәм режим идарәсе башлыгы, эчке хезмәт полковнигы **Гомәров** Ленар Әсхәбетдин улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе тикшерү идарәсенең 17 номерлы «Ямашев» полиция бүлеге тарафыннан хезмәт күрсәтелә торган территориядәге җинаятьләрне тикшерү бүлеге башлыгы, юстиция подполковнигы **Закиров** Динар Дамир улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

УКУЧЫ СҮЗЕ

Лилия Гыймазова

Гомер

Артта кала кышның бураннары,
Җанга тигән ачы еллар кала;
Юлда кала яшьлек, яулык болгап,
Гомер дигән пар ат алга чаба.

Бар да кала, бар да артка күчә,
Юл буенда өметләрең кала,
Күпме язлар, күпме назлар…
Гомер дигән пар ат һаман чаба.

Гомер дигән пар ат алга чаба,
Үткән кайтмый, яңа таңнар алда.
Еллар чаба, йөрәк түзми яна,
Әйди һаман киләчәккә таба.

Гәрәй РӘХИМ

ЯКТАШЛАР СӨЕНДЕРӘ

Апас районының Коштаулы авылында яшәүчеләр читтәге якташларының игътибарын, ярдәмен тоеп яши. Аларның да максаты безнеке кебек: авыл гына яшәсен.

Быелгы елыбыз да Казандагы Апас якташлык җәмгыяте бүләгеннән башланып китте. Авыл мәдәният йортында «Солнышко» курчак театры тамаша күрсәтте. Кыш бабай белән Кар кызы тамашадан соң да балаларны сөендерүен дәвам иттерде әле. Сабыйлар өйләренә бүләкләр белән кайтып китте.

Кышкы каникулны бәйрәм итеп кенә түгел, укып та уздырдык без. Авыл балалары инде моңа кадәр дә дин дәресләрен укый иде. Быел укытучылары Гөлназ Латыйпова ел башыннан сабыйларга гарәп теле дәресләре укыта башлады. Алар анда дини кагыйдәләрне дә өйрәнәләр, догалар да ятлыйлар. Дәресләргә 17 бала йөри. Әти-әниләр сабыйлары өчен сөенеп тора. Дөрес сүзләр ишеткән, Аллаһы Тәгаләгә якын булган балаларга ышаныч зур. Аларның әдәпле, иманлы, тәртипле буласына шикләре юк.

Без, авылдашлар, сабыйларга булган хөрмәт, аларның күңелләрен күреп, төрле чаралар уздырган, ислам дине дәресләрен укытырга мөмкинлек биргән өчен Казандагы Апас якташлык җәмгыятенә һәм авылдашыбыз Наил Галиуллинга чиксез рәхмәтлебез!

Тәскирә ХАФИЗОВА.
Апас районы Коштаулы авылы

Акыл теше

Рус халкында «Век живи – век учись» дигән гыйбарә бар. Ахырында «дураком помрешь» дип тә өстиләр әле. Картаймыш көнемдә акыл тешенең ни-нәрсә икәнен һәм ООО хәрефләренең нәрсәне аңлатуын белмәвем шуны искә төшерергә мәҗбүр итте.

Авыз куышлыгында мондый тешнең барлыгын беләм анысы, әмма калган 32сеннән аерылмый дип уйлый идем. Баксаң, акыл теше 10–12 яшьләрдә генә чыгып, тамыры тештән зуррак була икән. Гадәти тешне хирург, өшеткәч, 5–10 минут эчендә суырса, акыл тешен операция өстәленә яткырып алу очраклары да юк түгел. Ә мин, карт җүләр, гомерем буе моны белмичә йөргәнмен. Тешем сызлый башлауга, йортыбызда ук урнашкан түләүле стоматологиягә артыма ут капкандай йөгерүем шул белмәү аркасында килеп чыкты да инде.

Җитез хирург үземне берсүзсез кабул итеп, ниндидер кәгазьләр тутыргач, аңкауны өшетеп, «бернинди дә кыенлыгы юк, бик тиз генә» дигән булып, аласы тешем тирәсендә боравы белән безелдәтә башлады. Шәфкать туташы белән нәрсә турындадыр сөйләшә-сөйләшә, 10 минутлап бораулады. Авырту сизмим әле. Ләкин бераздан көйгән ит-сөяк исе тамакка килеп терәлде. Укшытуга түзә алмыйча, туктавын сорап, авыз эченнән мыгырданам. Әмма шәфкать туташы башымны тагын да ныграк тотып, мине тынычландырыпмы-тынычландыра. Ниһаять, хирург боравын читкә куеп, тешне чүкече белән вата башлады. Ләкин тешнең бирешәсе килми! Уртны кисеп, тешне алырга туры килде. Аннан бик озак текте. Гадәти түгел, ә ниндидер нык җеп белән.

ОООда 40 минутлап утыргач, 4 мең ярым сум акчамны калдырып, «бозлы кул»ны (шуннан ук сатып алдым – катлаулы операция кичерүчеләргә кирәк икән) яңагыма куеп, өйгә титакладым.

Әмма, алдырып, ярасы төзәлгәннән соң да теш һаман сызлый. Булмады бу, дип, инде дәүләт поликлиникасына барасы иттем. Менә сиңа мә: ОООда сызламаган акыл тешемне суырганнар икән бит. Сызлый торганы коронка астында калган.

ООО хирургының чыраен күрергә һич теләгем булмаса да, теге нык җепне алдырырга кирәк. Бардым. Каты гына итеп сүгендем. Ул да сүзсез калмады: өч О хәрефенең дә ни икәнен аңламаган Митрофанушка түгелсеңдер бит, дип, мәзәккә борган булды. «Кая барганыңны белгәнсеңдер бит», – дип тә өстәде.

Чыннан да, ул хаклы. Атамасы ук җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять булгач, аннан нәрсә көтәсе?! Базар икътисады гөрләгән цивилизацияле илләрдә ОООларның бармы-юкмы икәнен белмим, әмма безнең Россиядә алар буа буарлык.

Локман ЗАКИРОВ

Туган туфрак тарта ул

Кешене язмыш йөртә. Кайчандыр туган ягыннан бәхет эзләп чыгып киткәннәрнең күбесе, еллар узгач, барыбер кире кайта. Мамадыш районының Кече Кирмән авылы егете Миннекави Мингулов та шулай. 1950 елда, Миннекавига 4 яшь чагында аның әти-әнисе Амур өлкәсенең Тамбов районына күчеп китә. Туган туфрак тарта малайны: 15 яшен тутыргач, ул кендек каны тамган җиргә әйләнеп кайта.

– Монда кайткач, тракторчы булырга укыды. Аннары берничә ел авылда эшләде дә әле. Тик, нишләптер, монда каласы килмәде аның. Яңадан, бәхет эзләп, Чиләбе өлкәсенә чыгып китте, – дип искә ала авылдашлары.

Миннекави Чиләбедә күмер шахтасына йөкче булып урнаша. Кечке мәктәпкә укырга керә һәм татарча көрәш белән шөгыльләнә башлый. 1965 елда аны армиягә алалар. Анда спорт ротасына эләгә. Шул вакытта сәләтен күрсәтә дә инде егет. Көрәш буенча әллә ничә тапкыр җиңү яулый. Хәтта чемпион исеме дә ала.

Миннекави армиядән Чиләбегә кайта. Заводка эшкә урнаша, кичке мәктәпне тәмамлап, физкультура укытучысы белгечлегенә укырга керә. Шул елларда көрәш белән беррәттән дзюдо, самбо белән дә шөгыльләнә. Бик тырыш, үҗәт, әйткән сүзендә торучы, максатына ирешә торган кеше була ул.

Чит җирдә булса да, үз юлын таба егет. Чиләбе өлкәсенең Выкса шәһәрендә спорт базасы төзетү бәхетенә дә ирешә. Читтәге милләттәшләребезне бергә җыеп, көрәш, самбо, дзюдо серләренә өйрәтә. Бик зур уңышларга ирешә. Ул укыткан балалар ил күләмендә генә түгел, дөнья күләмендә таныла. Бик күп тренерлар, спорт мастерлары әзерли. Бу шәһәрдә илкүләм спорт чаралары уздырыла башлый. Тырышлыгы аркасында Миннекави үзе яшәгән җирне данлый. Эшләгән эшләре эзсез

югалмый. Бик күп мактаулы исемнәргә лаек була. «Россиянең атказанган спорт һәм физик культура хезмәткәре» дигән исем ала. Выкса шәһәренең мактаулы гражданины исеменә дә лаек була.

Миннекави абый үзе исән түгел инде. Узган ел, 76 яшендә арабыздан китеп барды. Урыны оҗмахта булсын! Хәзер аның истәлекләре Кече Кирмән авылы музеенда саклана. Миннекави абый тормышын сыйдырган ике стенд ясадык. Анда аның тормыш юлы хакында мәгълүмат, мактау кәгазьләре урын алган. Авылның бер урамына аның исемен дә кушарга ниятлиләр. Шунысы сөендерә: ул үзе дә картайган көнендә туган ягына кайтты, гаиләсендә кадерле кеше булды. Мондый авылдашларыбызны без онытырга тиеш түгел.

Гөлгенә ГЫЙЛЬМАНОВА

ХӘБӘРЧЕ ПОЧЕРКЫ

Хәбәрче почеркы бер селтәнүдә генә салына торган түгел, талантка, уку-гыйлемлеккә дә нык бәйле. Хезмәтен, яшәү рәвешен хәбәрче буларак журналистикага багышлаган кешенең генә үз язу алымы була ала. Хезмәт юлымда андыйлар белән шактый эшләргә, аралашырга туры килде. Элегрәк бит район матбугатында хәбәрчеләр белән эшләүгә нык әһәмият бирелә иде: даими очрашулар, эшче, авыл хәбәрчеләре слет-конференцияләре дисеңме – барысы да көтеп алынган бер бик эчтәлекле матур бәйрәмгә әверелә иде. Әле дә истә: иртә белән редакциягә эшкә килгәндә шәһәребез янәшәсендәге Туйкә авылыннан Мөдәррис абыебыз Усманов велосипедында көтеп тора. Бөек Җиңүне Берлинда каршылаган ветеран. Мәктәп елларыннан бирле газетабыз белән даими элемтәдә. Атнага ике-өч тапкыр безнең янга килеп, язмаларын һәрчак алдыбызга салып торыр иде. Урсай авылыннан мәгариф ветераны Тәкыя апа Шәрипова да шундыйлардан булды, юкка гына аның шушы көннәрдә 100 еллык юбилеен матур билгеләп үтмәгәннәрдер. Алар инде мәрхүмнәр, авыр туфраклары җиңел булсын. Әмма шунысы кызганыч: аларның никадәр матур иҗатлары тик ята. Мөдәррис абыйның повестьларга тиң хикәяләре, Язучылар берлегенең секцияләрендә тикшерелеп, уңай бәя алган драма әсәрләре үзләре генә ни тора! Әгәр бергә тупланып китапка кермәсәләр, онытылачаклар, билгеле. Мин кайчакларда аларның язмаларын кабат укыйм да камил, үзгә почеркларына карап сокланам.

Бу җәһәттән гомере буе мөгаллим булып хезмәт куйган һәм журналистлар берлеге әгъзасы булып, эчтәлекле, гыйбрәтле язмалары белән сокландырган Хәким Гыйлаҗев та – районыбызда бик хөрмәтле кеше.

Озак еллар бергә эшләгән күренекле язучыбыз Мәхмүт абый Хәсәнов үзе хәбәрчеләрне янына җыя, аларның язма-хәбәрләре, иҗат җимешләренә шулкадәр дә күз карасыдай кадерле итеп карый иде. Ул Әлмәт Язучылар берлеге белән даими элемтәдә булып, заманында Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллин, Гамил Афзал, Рафаил Төхфәтуллин кебек язучыларны чакырып, хәбәрчеләр белән очрашулар оештыра, бер үк вакытта үзе төзегән «Гөлстан» әдәби берләшмәсенә яшь талантларны туплый, иҗатларын шул язучылар карамагына куя иде.

Ә хәзерге көндә эшче һәм «авыл хәбәрчесе» дигән сүз тезмәсе дә юк инде. Без, редакциядәгеләр, алар язганнарга бик сак карый идек. Хатлар бүлекләре (алар хәзер бармы икән) һәр хәбәр-язманы бик кадерле документ кебек аерым теркәп, кайчан кергән, кайчан газетада басылган яки башкача ни эшләнгәнен аерым билгеләпязып бара иде. Бүген исә редакцияләрдә берән-сәрән хәбәрчеләр язган хәбәр-язмаларны теркәп мәшәкатьләнмиләр дә дип беләм. Менә шуннан күренә инде эшче, авыл хәбәрчесенә ихтирам, аларга булган язу осталыгына өйрәнү-өйрәтү мөнәсәбәтләре. Кая инде ул аларның язу почеркларын саклау! Заманында без шул Тәкыя апа, Мөдәррис абый кебекләрнең сәйләндәй тезеп язган инша-язмаларын үзгәртү түгел, үз почеркларын сакларга, нокта-өтерләренә кагылырга кыенсына идек. Хәбәрче почеркы ул – йөрәк түреннән чыккан күпме фикерләр тезмәсе, биниһая олы хезмәте, аны сакларга, кадерләргә өйрәнү зарур дип саныйм.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай шәһәре

ҖАЕККА БАРЫП КАЙТТЫК

Күптән түгел без, Арча педагогия көллиятенең бер төркем вәкилләре, сөекле шагыйребез Габдулла Тукайны үз иткән төбәктә – Казахстанның Уральск (Җаек) шәһәрендә булып кайттык. Безнең көллиятләр арасында 2018 елда хезмәттәшлек турында килешү төзелгән иде. Шуның нигезендә ике арада шактый тыгыз элемтә урнашты.

Тукай музее

Җаек шәһәрендәге татар мәдәни үзәгендә безне каршы алдылар. Оя корган урыннары да бик матур. Рәссам һәм фотограф Камил Муллашев аны бизәүгә бик зур өлеш керткән, ул, чыннан да, милли, аһәңле һәм зәвыклы. Шулай да безне иң нык әсәрләндергәне Габдулла Тукай музее булды. Шәһәрнең милли җанлы кешеләре булдырган бу байлыкны: бөртекләп экспонат җыйганнар, аны кадерләп саклыйлар. Музей 2006 елның 12 декабрендә ачыла һәм татар мәдәни үзәгенә тапшырыла. Директоры – милләттәшебез, математика укытучысы Марат Баһаветдинов. Бу йортны ачу иң югары дәрәҗәдәге сөйләшүләрдән соң гына мөмкин була. 2005 елда беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев һәм Казахстан Президенты Нурсолтан Назарбаев бу хакта килешү төзиләр.

Габдулла Тукай Җаек шәһәрендә 1894 елдан 1907 елга кадәр яши. Димәк, 8 яшендә килә, 21 яшьтә Казанга китә. Кырлай авылыннан аны Газизә апасы алдырта. Җизнәсе Галиәсгар Усманов аягында нык басып торучы сәүдәгәр була. Монда яшәгәндә Тукай мохтаҗлыкны белми. Шул вакыт өчен алдынгы саналган белем ала. Укытучысы Мотыйгулла Төхвәтуллин була. Мөгаллименнән бик уңа Апуш: гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнә. Әхмәтша учительгә йөреп, рус телен дә үзләштерә.

Менә шушы Мотыйгулла Төхвәтуллинның йортын музей итеп сайлыйлар да инде. Анда яшәүчеләрне күчерү өчен өлкә хакимияте 6 фатир бирә. Йортка реконструкция ясала. Музей дүрт залдан тора, монда 400дән артык экспонат бар. Подвалда элек типография булган. Анда «Урал көндәлеге», «Фикер», «Уклар», «Әл-гасрел җәдит» газета-журналлары басыла. Хәзер бу типография шулай ук музей залы итеп торгызыла.

Татар бистәсе

Без Тукай эзләре буенча сәяхәт иттек. Бу урыннар Татар бистәсе дип атала. Бик күп милләттәшләребез яшәгән биредә. Аларның өйләре рус һәм казахларныкыннан аерылып тора: тәрәзәләренең өске өлешләре түгәрәкләнеп эшләнгән. Мондый өйләр байтак. Менә истәлек тактасы куелган Галиәсгар Усманов йорты. «Бу йортта 1895–1900 елларда бөек татар шагыйре Габдулла Тукай яшәгән» дип язылган. Заманында Мотыйгулла Төхвәтуллин имам булган Кызыл мәчеттә дә булдык. Тукай анда намаз укырга йөргән. Мәчет бик әйбәтләп ремонтланган, яңартылган. Марат Баһаветдинов безгә һәр йортның тарихы турында сөйләп бара. Җаек шәһәре татар артисткасы Галия Кайбицкая, композитор Нәҗип Җиһанов, тарихчы-галим Рәфыйк Нәфыйгов исемнәренә дә бәйле. Тагын бер күркәм урын – Тукай паркы һәм Тукайга куелган һәйкәл.

Казах батыры

Икенче көнне Җаһанша Досмухаммедов исемендәге Уральск педагогия көллияте оештырган халыкара фәнни-гамәли конференция булды. Ул казах азатлык хәрәкәте җитәкчесе Җаһанша Досмухаммедовның тууына 135 ел тулуга багышланган иде. Бу шәхес 1937 елда атып үтерелә. Ул казахларның бәйсезлеге өчен көрәшә, Ленин, Сталин белән очраша, «Алаш» партиясе лидеры була. Бүген казах халкы үзенең батыр улын нык хөрмәтли. Халыкара конференциягә дә Бохара, Ташкент шәһәрләреннән фән докторлары, Россия һәм Төркия галимнәре килгән иде. Онлайн чыгышлар да булды. Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте директоры Гөлнара Гарипованың чыгышы да бик эчтәлекле булды.

Казах халкы белән татар халкының уртаклыгы бик зур. Безнең телләребез якын, динебез бер, гореф-гадәтләребез, бәйрәмнәребез шул ук диярлек. Кичен, ял иткәндә, уртак җырларыбызны да җырлап утырдык.

Дамир ТАҖИЕВ,
«Әлифба» музее җитәкчесе

Белдерү

Кадастровым инженером Ирбулатовым Маратом Рафиковичем (почтовый адрес: 420100, г. Казань, ул. 2-я Азинская, д. 1, контактный тел.: 89600488084, электронная почта marat_327@mail.ru, № квалификационного аттестата 16-15-841), в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:090308:7, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Кировский район, ул. Кожевенная, дом 15, выполняются кадастровые работы по уточнению границ земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является: Байтимерова Эльмира Фаритовна (почтовый адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Казахская, д. 4).

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться в будние дни с 10.00 до 18.00 ч. по адресу: 420100, г. Казань, 2-я Азинская, д. 1.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ земельного участка состоится по адресу: 420100, г. Казань, 2-я Азинская, д. 1, 27 февраля 2023 года в 10 часов 00 минут.

Возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются со дня опубликования в печатном издании в течение месяца по адресу: 420100, г. Казань, 2-я Азинская, д. 1.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы земельного участка: 16:50:090308:5; 16:50:090308:8; 16:50:090308:12; 16:50:090308:6; 16:50:090308 (земли общего пользования).

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок.

Авылдан хатлар

Марат КӘБИРОВ

Кесә

«Авыл халкы милләт турында уйлап та карамый», – дип язгансың бер мәлне. И, саруымны кайнаттың инде шул сүзең белән. Уйламый, ди менә!

Әллә нәрсәләргә кереп китәм кайчагында, энем. Милли киемнәр турында уйланып яттым бүген төн буена. Яшь чакта мин биеп тә йөрдем бит. Төрле тамашаларда катнашып, күрше-тирә авылларның сәхнәләрен бер иттем. Менә шул чакларда татарның милли киемнәрендә кесә юклыгына эчем поша торган иде. Без бит инде бөтен нәрсәне дә кесәдә йөртергә гадәтләндек, ә гадәт ул чирдән яманрак: бер эләктерсәң, мәңге котыла алмыйсың.

Хәзер артык пошынмыйм да инде. Кесәгә салырлык нәрсәләр сирәгәя, тәмәкене ташладым, пенсияне картага күчерәләр. Шулай да хәзер мин яшь чакларны искә төшерәм дә уйланып йөрим. Татарның бию киеменә ни өчен кесә текмәделәр икән, дим. Бүтән халыкларныкында бар иде бит ул. Ә безнекендә юк. Менә син бер мәлне: «Бүтән халыкларда булган нәрсә бездә дә булырга тиеш», – дигән кебегрәк язып чыктың да ул. Белмим инде, энем, тиеш микән?

Яшәгән саен дөнья күрәсең, күргән саен акыл керә, дигән булалар инде ул. Тик менә миңа акыл керәме икән, әллә чыгамы? Тик бу фикеремә шушы икенең берсе сәбәпче. Мин бик нык уйладым да, татарның милли киемнәренә кесә текмичә дөрес эшләгәннәр икән, дигән нәтиҗә ясадым. Нык дөрес булган ул.

Элекке кешенең киемендә кесәсе булмагандыр, дип уйлыйм. Акчасын ул, алтын-көмеш тәңкәләрне инде, кесәсенә салып йөртмәгән бит, янчыгына тыгып, билбавына тагып йөрткән. Хәнҗәре дә билбавында булган. Тарихта юк кесә дигән нәрсә. Менә син китап укый торган кеше бит инде, берәр романда: «Фәлән-фәлән хан, түш кесәсеннән алып, көмеш тәңкә бирде», – дигәнрәк җөмлә укыганың бармы? Юк. Үзең генә язмасаң, башкалар андый сантыйлыкка бармас. Хәер, син тарихи нәрсә язмыйсың бугай, дөрес эшлисең, наданнар эше түгел ул.

Элек татарның киемендә бернинди дә кесә булмаган. Аның белән генә бөлгенлеккә төшмәгән ул, җир тетрәтеп яшәгән. Бөтен дөньяны исәпләштерерлек итеп дәүләт төзегән, үз көнен үзе күреп гомер иткән. Кыз-кыркыны бозыклыктан ерак булып үскән, кияүгә чыкканчы кул тидертү түгел, чебен дә кундырмаган. Хатыннары итәк тутырып бала тапкан, тупырдап торган уллар-кызлар үстергән. Ир-егетләре дөньяны бөтен иткән, мал кирәксә, малын тапкан, яулар килсә, яуга чапкан. Әйтәсе сүзен беркемнән дә курыкмыйча кистереп әйтә белгән алар, үз намусын аклау өчен көрәш мәйданына чыгарга да, кылыч-хәнҗәргә үрелергә дә курыкмаганнар. Протест белдерәбез дип, җыйнаулашып җырлап утырмаганнар инде хәзерге шикелле. Адәм ыстырамы, аның күбесе җырларга да шүрли бит әле… Элек ирләр чын ир булган инде.

Ә киемнәрендә кесә булмаган. Ныклап уйлап карасаң, кесәсез кием – зур нәрсә ул, энем. Татарның олпатлыгын саклый белүенә шул да сәбәпчедер дип уйлыйм мин. Һәм югарыда күрсәтмә биреп утыручылар колагына да, алар әмерен үтәүчеләрнекенә дә әйтәсе сүзем бар. Татар киемнәренә кесә текмәсеннәр. Хатын-кызныкына, бәлки, кирәктер дә инде ул. Бәлки, кирәкмидер… Алар болай да сумочка асып йөриләр бит. Ә менә ирләр киемендә кесә булмаска тиеш. Ирләре кесәле кием киеп йөри икән, милләтнең киләчәге юк.

И, зарланырга ярата бит инде кайберәүләр… «Милләт бетә, телебез бетә, ирегебезне кысалар», – дип сайрап кына торалар. Андыйларны Ходай сандугач итеп яралтырга теләгәндер инде ул, планын үтәр өчен генә татар итеп тудыргандыр. Татарны яшәтү өчен тегене эшләргә кирәк, моны эшләргә кирәк, диләр. Эшләргә дә итеп карыйлар. Тик күп вакытта кайбер нәрсәләр, ә кайчагында берни дә килеп чыкмый. Тукталырга, үзгәрергә, үзгәртергә мәҗбүр булалар. Ә сәбәбе нәрсәдә? Юк, энем, өлкән агайда гына да, хакимият күрсәткән мәсләктә дә түгел. Гомумән, гаепне читтән эзләргә кирәкми, сиңа файда эшләмәскә тырышу – чит-ятларның бурычы ул: әгәр яхшылык кылып кына торса, чит булмый бит инде, үзеңнеке була, әгәр чит икән – үз мәслихәтен карый ул, синең хакта уйламый. Гаеп чит-ятларда түгел, энем. Гаеп – үзебездә. Бөтен гаеп – безнең кесәдә.

Менә, энем, сиңа васыять кебек итеп әйтәм. Әгәр татарны сакларга, якларга, үстерергә телисез икән, киемнәренә кесә текмәгез. Хаҗәте дә юк аның хәзер: блокнот – телефонда, акча – картада… Хәзер кесәне татар бары тик бер максаттан гына файдалана: йодрык күрсәтү өчен генә. Кесәсе булмаса, аның йодрыгы зур икәнне бөтен дөнья күрәчәк. Ә кесәсе булгач, ул үз йодрыгын үзе дә күрә алмыйча яши.

Таңсылу Галимова

ЯШЬЛЕК БӘЙРӘМЕ

СТУДЕНТ ЕЛЛАРЫ НӘРСӘ БЕЛӘН КАДЕРЛЕ?

25 гыйнвар – Россиядә Студентлар көне. Студент еллары – һәркем өчен истә калырлык, елмаеп искә алырлык мизгелләрдер. Шул ук вакытта кешене олы тормышка әзерләүче бер этап та. Ә сезгә кеше гомеренең иң күңелле чоры нәрсәсе белән кадерле?

Илсөя БӘДРЕТДИНОВА,
Татарстанның атказанган артисты:

– Безнең заманда телефон да, юньләп кияргә кием дә, 300 километр ераклыктагы авылдан килгән балага зарланырга туганнар да, дуслар да юк иде. Мин Казан дәүләт технология университетына кием һәм аяк киеме дизайнеры факультетына укырга кердем. Безнең төркемдә барысы да шәһәр балалары, руслар иде, авылдан килгән татар кызы – берүзем. Телне камил белергә, аралашырга да кирәк. Шушы еллар бөтен нәрсәне тиз һәм төгәл эшләргә өйрәтте. Ялкауланып ятсаң, дөнья бармаячагын, эшләсәң генә уңыш киләчәген төшендерде. Гомумән, студент еллары мөстәкыйль булырга һәм бернәрсәдән дә зарланмаска, кешегә яраклашырга, һәрберсе белән уртак тел табарга өйрәтте. Хәзер минем улым – икенче курс студенты. Мин һәрвакыт әйтәм: балаларны җәлләргә ярамый. Ир-ат баланы бигрәк тә. Мөстәкыйльлеккә өйрәнеп үссеннәр. Канат астында түгел, үзләре тормышны белеп үсәргә тиешләр. Алар яшендә без инде җир җимертеп, үзебез тормышны алып бара торган кешеләр идек. Студент елларына нәкъ менә шуның өчен рәхмәтлемен.

Илфак ХАФИЗОВ,
Тинчурин театры артисты:

– Студент еллары бер идея белән янган кешеләр янында булу, дуслар белән кадерле инде ул. Артем Пискунов, Резедә Сәлахова, Зөлфәт Закиров белән бергә укыдык, хәзер бергә эшлибез. Башка курсташлар белән дә аралашып яшибез. Студент елларыннан бер вакыйга истә калган: театр училищесын тәмамлагач, Артем, Резедә белән КДУның читтән торып уку бүлегенә кердек. Беренче сессия вакыты бу. Укытучылар белән танышабыз, безгә «болар театрдан, инде белергә тиешләр» дип, шундук тамга сuктылар. Беренче курста фольклор дәресеннән безне Марсель абый Бакиров укытты. Беренче дәрестә таныша башладык, Марсель абый: «Кайсыгыз кайсы яктан?» – дип, рәттән сорап бара. Артем белән икәү утырабыз, иң соңгы булып безгә туры килде. Безгә чират җитте, без Мөслимнән, дибез инде. «Үзегезнең районнан чыккан кешеләрне беләсезме?» – дип сорады, без инде горурланып, беләбез, дидек. Шуннан бу: «Марсель Бакировны беләсезме?» – дип сорый. Без бит инде җаваплы кешеләр, белмим дип әйтеп булмый. Мин, акыллы кыяфәт чыгарып, беләбез, дим. «Кайда, нәрсә эшли ул?» – дип сорый. «Хәзер искә төшерәм», – дип, озак кына баш катырып торгач, безнең янга килде дә: «Менә мин инде ул Марсель Бакиров», – ди. Шул вакытта оятыбыздан җир тишегенә кереп китәрдәй булган идек. Ул аны үпкәләп түгел, көлеп әйтте инде, билгеле. Студент булгач, шундый кызыклы вакыйгалар да була.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Энҗе ГАБДУЛЛИНА,
«Татар кызы – 2022» бәйгесе җиңүчесе:

– Студент тормышы бик тә тулай торак белән истә калды. Бер елын – Универсиада авылында, өч елын Студентлар шәһәрчегендә яшәдем. Студентлар шәһәрчегендә яшәгән еллар турында мемуарлар язарга була. Без бер бүлмәдә татар кызлары яшәдек. Ашарга да бергә пешердек, бүлмәне дә бергәләп җыештыра, юа идек. Төннәр буе серләшеп, сөйләшеп чыга торган идек. Таң атканда гына йоклап китеп, иртәнге сигезгә укырга барган чаклар да булды. Шунысы белән дә кызык инде. Аннары студент елларына мин дуслар өчен рәхмәтле. Шуның белән кадерле дә. Бергә укыган төркемдәшем җан дустыма әйләнде. Дүрт ел буенча бер-беребезгә терәк булып яшәдек, укыдык. Хәзер дә шулай ук. Укып бетердек дип кенә аерылышмадык. Журналистика бүлегендә укып, бөтенебез дә үз һөнәребез буенча эшләгәч, төркемдәшләр белән эш буенча еш күрешәбез. Бер-беребездән башкалар турында сорашабыз, искә төшереп көлешәбез. Барыбер дә студент еллары яшьлек чорының иң кадерле, рәхәт, күңелле чагы булган икән. Бер мизгеле дә, кызык та, күңелсез чаклары да онытылмый. Студентлар яшьлекләренең кадерен белеп, рәхәтен тоеп калсыннар!

Василий ИВАНОВ,
блогер-тракторчы:

– Янил техник училищесында тракторчы-машинист белгечлеге буенча укыдым. Студент еллары барыбер күңелле, рәхәт чак инде ул. Эшлисе юк, әти-әни җилкәсендә, гаилә кору турында да уйламыйсың әле ул вакытта. Тормышны бик җиңел кабул итәсең, бер нәрсә турында кайгырмыйсың. Бергә укыган кайбер малайлар белән сөйләшкәләп торабыз. Тик әле укып чыкканнан бирле бер мәртәбә дә очрашкан юк. Йә вакыт булмый, йә башка сәбәпләр аркасында. Бер очрашып, шул чакларны искә алып, сөйләшеп утырсак, әйбәт булыр иде. Студент тормышы барысына да өйрәтә. Шәһәр ул авыл түгел, кешеләр белән сөйләшергә, мөнәсәбәт корырга өйрәнәсең. Армиягә китәр алдыннан да бер тәҗрибә булды ул еллар.

Ләйсән САФИНА

ЙӨРӘК ҖЫЛЫСЫ

Мәрхәмәт

Үзеңнеке итеп яратырга кирәк! Балтач районының Зур Лызи авылында гомер итүче Маргарита Васильева әнә шулай ди. Ул 20 елдан артык социаль хезмәткәр булып эшли. Шушы вакыт аралыгында ул 19 әбине тәрбияләгән. Бүген исә ике карчык янына барып йөри, өченчесен тәрбиягә алган. Олы йөрәкле ханым белән тәрбиягә алган өлкән буын кешеләре хакында сөйләштек.

– Мин – сәүдә кешесе. 1990 нчы елларда кибетче булып эшләдем. Бик авыр чаклар. Халык авыр яши, ә кибетчегә зур планнар куялар, бурычка да бирергә ярамый. Уйладым да эшемнән китәргә булдым, – дип искә ала Маргарита. – Бераздан «социаль хезмәткәрләр кирәк» дигән хәбәр ишеттем дә тәвәккәлләп барып карарга булдым. Әкренләп башта бер әбине, аннан икенчесен алдым. Берьюлы алты әби тәрбияләгән чаклар да булды.

Маргарита – удмурт хатыны, татарчаны су урынына эчә. Русча да чиста сөйләшә. Телне белү әбиләр белән дуслаштыра инде. Яшерми, олы кешенең төрле чагы була. Кайчак авыр сүз дә әйтеп ташлыйлар, кайчак көтмәгәндә мактап та куялар. Маргарита аларны аңлый, холыкларын өйрәнә. Бөтен эшләрен башкара.

Өлкәннәр янына билгеле бер сәгатьләрдә барып йөриләр. Әмма, Маргарита әйтмешли, авылда махсус минутлар санап йөреп булмый. Олыларны гел күз уңында тотарга, хәлләрен белеп торырга кирәк. Иң авыры – өлкәннәрнең вафат булуы, ди Маргарита. Якын кешеңне югалту бик авыр, ди. Авырып киткәннәре дә бар. Әле менә шушы араларда бер әбигә инсульт булган. Аны читтә яшәүче кызы үз янына алачак. Үз кешесенә әйләнгән әбисе дә бар бит әле! Анысы аеруча игътибар көтә.

Маргарита 85 яшьлек Идея Жилинаны үз гаиләсенә моннан 3 ел элек ала. Ире дә каршы килми. Киресенчә, олы йөрәкле булуына сокланалар гына.

– Идея ханымның беркеме дә юк. Ул бик белемле, укымышлы. Үзенә булган тәрбия өчен бик рәхмәтле. Мине шушы кеше рәхмәтләре яшәтә дә инде, – ди Маргарита. – Бервакыт Идея ханымның гаиләдә яшисе килүен ишеттек. Кызгандык без аны. Тормышыбыз җитеш. Улым белән кызым Казанда яши. Улымның үз гаиләсе, кызым кияүдә түгел әле. Алар читтә булгач, икәү генә нишләп ятар идек? Идея ханым – безгә зур иптәш тә әле ул. Мин аны бик якын итәм. Бар тәрбиямне бирергә тырышам. Эшемә барып кайтам да тизрәк әбием янына ашыгам. Кадер-хөрмәттә яшәтергә тырышабыз. Бөтен гаиләбез белән ияләндек үзенә. Балалар белән оныклар кайта да иң элек, әби дип, янына кереп китәләр. Үз әнием дә олы яшьтә. Авылыбызда яши. Аны да ташламыйм. Гел хәлен белеп, ярдәм итеп торам.

Маргаритага – 56 яшь. Тормышның кадерен, яшәүнең ямен белеп яши. Ирен җир йөзендәге иң яхшы кеше дип атый. Шулай булмаса, катлаулы операция кичергәннән соң Идея ханымны күтәреп йөрмәс иде.

– Картлыгымда мондый кадер-хөрмәт күрермен дип уйламаган идем. Кан басымымны үлчи, юындыра, киендерә, ашата-эчертә. Вакытында даруларымны биреп тора. Җылы сүзен кызганмый. Мин аларга бик рәхмәтле, – ди Идея ханым.

Идея ханым мунча керергә бик ярата. Юындырып чыгаргач, Маргаританы бик озак җибәрмичә кочаклап тора икән. Шул чакта битләремне үбә, дип сөенә Маргарита.

– Игелекләр эшләү кирәк. Гөнаһларыбыз да аз түгелдер. Ходай каршысына барасы бар бит әле. Анда буш кул белән генә булмас, – ди Маргарита. – Һәр эшнең үз авырлыгы. Әмма йөрәк кушканны тыңларга кирәк. Кешеләргә булышыр өчен иң элек аларны ярату кирәк. Үзеңнеке итеп кабул итсәң, якын итсәң, ул да сине чит итми. Без исә Идея ханымны рәхәттә яшәтә алганыбызга сөенәбез генә. Үзебезне дә картлык көтә бит!

Сүз уңаеннан, Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова киңәйтелгән еллык коллегиядә Татарстанда 36 өлкән кешенең чит гаиләләрдә үз кеше булып яшәве хакында сөйләде. «Бер кечкенә картлар йорты кадәр бит бу. Мәрхәмәтле кешеләр әнә шулкадәр олыларны гаиләле итте», – диде ул.

Шушындый мәрхәмәтле гаиләләр турында белсәгез, безгә дә хәбәр итегез. Сездән хатлар көтеп калабыз.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5302 данә
Гомуми тираж – 15536 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 211

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+